
PRESSA.RU

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН



2017 ИЮЛЬ № 7

# Сөембикә

ISSN 0869-1398

## АВЫЛНЫҢ ЯҢА ШӨГЫЛЕ
*һәркем кушыла ала*

## ӘНИЛӘР «КУРЧАК УЙНЫЙ»
*үзеңнеке матуррак*

## МАСТЕР-КЛАСС:
*чәй янына – каймак бәлеше*


## Мәдинә ГЫЙЛЕМХАНОВА:
# «НИЯТЛӘР ТОРМЫШКА АШСЫН!»







# *И-и ямьле туган ягым!*



Фоат САДРИЕВ
(«Таң җиле»
романыннан өзек)

*Сәнәк сабы юанлыгы гына төп-төз каеннар, шомырт, балан, өлгереп җиткән карлыган куаклары арасыннан үтеп, Ыкның иң куркыныч, иң текә, иң тирән Кара яр дигән урынына килеп туктады. Су өсте тып-тын, ара-тирә шопырдап балыклар чума, камыш сабаклары, төнбоеклар су өстендә тын гына йоклыйлар. Кошлар, берсеннән-берсе уздырырга теләп, ашыга-ашыга сайрый. Алар шулкадәр шатланалар, шулкадәр бәхетлеләр, җирнең, бу каеннарның, куакларның, елганың, таң нурлары белән алланган күк йөзенең матурлыгы турында үз телләре белән сөйлиләр иде. Аларның һәр авазы аңлаешлы, йөрәккә үтеп керә, билгеле дә, билгесез дә, таныш та, яңа да, һәммәсе дә бер нәрсә – яшәү шатлыгы турында сөйлиләр, шуны көйлиләр, шуны җырлыйлар, шул тоташ җылы моң булып һавадан, җирдән, күктән, су өстеннән, агач яфраклары, үләннәр арасыннан агып сиңа керә, каның белән бөтен барлыгыңны сугара, кайнарлата, хәят нуры өсти иде. Ул үз гомерендә беренче мәртәбә күргәндәй күккә, җиргә, суга карады. Яшел ябалдашлар арасыннан агылучы кошлар җыры колакларына тулды, алсу таң нурлары белән өртелгән ак каен кәүсәләре мәңгегә күзләренә сеңде...*

ЗӨЛФӘТ

## Туфрак тарта

*Ыклы Мөслим, таңда чыклы Мөслим!*
*Тере утлы ныклы Ватаным!*
*Кайсы якка гына юл тотсам да,*
*Мин бит һаман сиңа атладым.*

*Туфрак тарта, диләр... Шулайдыр шул...*
*Үземнән дә моны мин беләм –*
*Күкрәгемә йөрәк булып кергән*
*Кайнар чабышкы син, ил генәм!*

*Ык агымы шулай исән чакта*
*Каян табыйм икән тынгылык?*
*Күкрәгемдә йөрәк түгел лә бит! –*
*Сайрап тора Мөслим былбылы!*

*Ташламасын сине берүк Тәңре:*
*Җир сораса – яңгыр сибелсен,*
*Җир сораса – Кояш балкып торсын...*
*Бәхеткә син лаек бит, Мөслим...*

Материалны әзерләргә ярдәм иткәне өчен Мөслим мәгълүмат-мөхәрририят үзәге җитәкчесе Римма АФЗАЛОВАга рәхмәтебезне белдерәбез.

PRESSA.RU

# Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2017

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электронное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.




**Җитәкче-баш мөхәррир**
Ләйсән Рәфикъ кызы ЮНЫСОВА

**Редколлегия:**
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

| | |
|---|---|
| **Редакциянең гомуми телефоны** | 222-09-77 |
| **Җитәкче урынбасары** | |
| Рәмзия Кашапова | 222-09-78 |
| **Баш мөхәррир урынбасары** | |
| Гөлнур Хәсәншина | 222-09-78 |
| **Җаваплы сәркатип** | |
| Лариса Маликова | |

**Сайт мөхәррирләре:**
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

**Дизайн-макет:**
«ASAFIN GROUP»
**Верстка:**
Лариса Маликова

**Тышлыкта:**
Мәдинә Гыйлемханова
Фото: Анна Арахамия

**Бүлек мөхәррирләре:**
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Асия Юнысова
Фәнзилә Мостафина
**Фотокорреспондент**
Ксения Богданова
**Корректор**
Фирдәвес Исмәгыйлева
**Гамәли хезмәткәрләр:**
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Формат: 225x290 мм.
Күләме 64 бит.

Басарга кул куелды:
6.06.2017 ел.
Заказ А-1595.
Тираж 5237.

Учредитель:
Акционерное общество «Татмедиа»




ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002



PRESSA.RU



# Баш мөхәррир сүзе



Авыл бетә, дип ут йотабыз. Юк, яши әле безнең авыллар. Таң белән җиң сызганып куя да ул... әллә ниләр майтарырга өлгерә – безгә, шәһәр «кызларына», көнләшеп кенә карыйсы кала аларның инстаграмнарыннан агылган дәртле-матур тормыш мизгелләренә. Җыр кушып басылган камырлардан бәлешләр пешә, чиләкләрдән ташып торган җиләктән каклар коела. Авыл хатынының мал-туары да каралган, ире дә көйле, баласы да тәрбияле – җылы канат астына үзенеке белән беррәттән, әле берничә ятим бала да сыйган!

Авыл балаларына көнләшерлек – шәһәрнекеләр күрмәгән табигать, хозурлык, хөррият өстенә, инде кала мөмкинлекләре дә килеп өстәлде бит – һәр район үзәгендә диярлек үсеп чыккан спорт үзәкләрен генә алыйк... Йөри аламы безнең балалар көн дә бассейнга йә шугалакка? Ай-һай... Хәзер инде авыл хатыннары да, безне уздырып, һәр яңалыкны тормышка ашыра бара. Скандинав таяклары турында без интернеттан гына укыйбыз, ә алар инде әллә кайчан һәр кич саен авыл урамнарын урый... Шулай хәзер!

Сокланам, хөрмәт итәм, горурланам безнең кавем белән!

*Ләйсән ЮНЫСОВА*

«Мәтрүшкә исе». Р. Сәлахов эше.

PRESSA.RU




## БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА



16

БЕЗ ИКЕБЕЗ БЕРТӨСЛЕ...
М. Авзалова

## ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ



8

АКБАШЕВЛАР ТӘРБИЯСЕ
М. Авзалова

20



ӘНИЛӘР «КУРЧАК УЙНЫЙ»
Л. Әбүдәрова



12

ИНТЕРНЕТТА – «МӘРЬЯМ БИТЕ»
Л. Гәрәева

## ТАТАР ДӨНЬЯСЫ

22

«БУЛМАСТАЙНЫ ХЫЯЛЛАНМАДЫМ...»
Г. Сафиуллина




# ЭЧТӘЛЕК


МӘДӘНИ ТОРМЫШ 



26

ТИК СИН ДИЕП...
А. Юнысова

ЯШӘЕШ 



42

ҮЗЕҢНЕ ҮЗЕҢ ҖИНЕП...
Г. Сафиуллина



50

БОХАРАНЫ КҮРЕРГӘ ҺӘМ...
Р. Кашапова

ШУЛАЙ УК: 

32

ҖИРӘНЧӘЧ
(хикәя)
В. Мәҗитова

46

КАЙТУ
Э. Закирова

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 

62



ТАШЛАРНЫ БИЗӘР ЧАК


КИЛӘСЕ САННАРЫБЫЗДА:

ХАТЫН-КЫЗДА ИКЕЙӨЗЛЕЛЕКНЕ КИЧЕРМИМ... БЕЗ ҺӘМ АЛАР

БЕРӘҮГӘ БЕРӘҮ КИРӘК. КӘРИМ КАРА. ХИКӘЯ.

ТАҖИКСТАН. МОНДА ТОРМЫШНЫҢ ҮЗ КАГЫЙДӘЛӘРЕ. СӘЯХӘТ.

ЗӨЛФИЯ БЕЛӘН ҖӘВИТ ШАКИРОВЛАРДАН МАСТЕР-КЛАСС.



PRESSA.RU

# Кадерле «Сөембикә» редакциясе!



*Бервакыт миңа Киләче авылында яшәүче Нәсимә абыстай белән очрашу һәм аның белән гәпләшү насыйп булды. Туган көне иде аның.*

Нәсимә абыстайдан ничек шулай моңлы, матур итеп Коръән укырга өйрәнүен сораштым. «Бисмилләәһирахмәни-рахиим, – дип башлады ул сүзен. – Мин 29 яшемнән әтиемнән догалар язып ала башладым. Дәфтәремә язып куям да, вакытым булганда алып укый идем. Әтиемдә иске гарәп хәрефләре белән язылган китаплар бар иде. Мин ул хәрефләрне өйрәнергә дигән шарт куйдым. Әтием өйрәтеп калдырды мине шул гарәп хәрефләрен танырга. Аннары үзем мөстәкыйль рәвештә өйрәнергә керештем. 1993 елга Коръәнне тирәнтен өйрәндем һәм 1995 елдан башлап биш вакыт намазымны калдырмыйм».

Мин Нәсимә абыстайның әтисе Насыйр бабайны бик яхшы хәтерлим. Авылда мөхтәрәм кеше иде – безгә никах укыды, олы улыбызга исем дә кушты. Урыны җәннәттә булсын! Ике кызы – Дилә һәм Сания гомерләрен балалар укытуга багышлаган кешеләр. Нәсимә абыстай да хәзерге вакытта күпләргә остаз, Киләче авылында динебезне үстерүгә, дөресрәге, кешеләребезне исламга кайтаруга зур өлеш кертә.

«1939 елгы мин, – дип, балачак, яшьлек хатирәләрен күңеленнән барлый Нәсимә абыстай. – Быел 28 февральдә 78 яшь тулды. Сугыш дәверендә үскән баламын. Әтием 1907 елгы иде, Бөек Ватан сугышына киткәч, әнием өч бала үстергән. Әтиебез сугыштан исән-сау кайтты. Хәер-догалар саклагандыр инде үзен. Аннан тагын ике бала туды. Әтием һәм әнием ягыннан нәселебездә укымышлы, динле кешеләребез булган. Әнием ягыннан Сәйфулла исемле туганыбыз Киләченең бер мәчетендә имам булып хезмәт иткән (1917 елга кадәр Киләчедә өч мәчет эшләгән). Мин яшьтән үк, ягъни ислам диненә керешкәннән бирле, динне күбрәк өйрәнергә һәм аны башкаларга да өйрәтергә дигән максат куйдым. Шул юнәлештә эшлим инде. 1995 елда Зарипова Сара апа өенә унҗиделәп хатынны җыеп, намаз укырга өйрәттем. Мулламинов Җәүдәткә бик зур рәхмәт, 1996 елда совхоз ашханәсен картларга намаз уку бинасы итеп тапшырды. 2010 елда авылда яңа мәчет ачылгач та бик күп милләттәшләребез намазга басты. Бисенгазиева Рәмзия һәм Бирдиева Рәшидә – минем укучыларым. Яшьләр арасында да күңелләрен иман белән баетып, тирә-юньгә нур чәчеп яшәүчеләр бар. Киләчәктә үзләренә саулык-сәламәтлек юлдаш булсын да, мул тормышларның рәхәтен тоеп, һәр туар таңга шатланып яшәргә язсын.

Бездә авыл халкы бик яхшы. Мәчет салганда күп ярдәм иттеләр. Башка дини бәйрәмнәрдә дә бик актив катнашалар. Авылдашларыбыз белән бергәләп өч ел Хәтем Коръәне укыттык. Авыл кибетләре хуҗаларына да рәхмәтләребезне җиткерәбез. Үз юмартлыклары үзләренә кире кайтсын».

Бүгенге тормышыннан бик канәгать Нәсимә абыстай. Акча юк дип зарланучыларга аның әйтер сүзе бар. «Аллаһка мең-мең шөкер, илдә туклык, муллык. Ашавыбыз – элек авыл кешесенең төшенә дә кермәгән – тәм-томнан өстәл сыгылырлык. Шушы муллыкларны «Аллаһым, дәвамлы кыл!» дип шөкрана әйтергә кирәк. Раббыбызның олуг бер бүләге «бисмилләһ». «Бисмилләһи-рахмәни-рахиим», – дип башланган эш хәерле була, бәрәкәт бирә», – ди ул.

*Наилә ЕСЕНБАЕВА.*
*Әстерхан шәһәре.*

*5 яшемдә мине өермә алып китте. Өермәнең нәрсә икәнен белмәгән кеше юктыр, юлында нәрсә очраса да үзе белән ияртеп алып китә ул.*

Сабый чактагы күп нәрсәне онытсам да, ул көнне бик яхшы хәтерлим. Урамда, үзебезнең тәрәзә каршысында уйнап утыра идем. Кинәт көчле җил купты, җил ягына борылып карасам, миңа таба кара багана якынлаша. Аның эчендә казлар, тавыклар, тагын әллә нәрсәләр бөтерелә. Куркудан кычкырырга да өлгермәдем, «кара багана» мине дә бөтереп алды. Авыл тирәсендәге бөтен нәрсәне берьюлы күрдем сыман. Шуннан башкасын хәтерләмим. Әти-әни мине башка урамнан табып алып кайтканнар. Шул көнне әйттеләр микән, әллә мин аны башка көнне ишеттемме: «Балабыз тома сукырайган...» – диләр. Берни дә күрмәгән ул көннәр хәтеремдә калмаган. Табибларга да алып барып караганнар, әмма алар да ярдәм итә алмаган: «Соң инде», – дигәннәр. Ләкин... Кинәт күзем

ачылып китте. Минә ул көнне бик яхшы хәтерлим: кояш нурына күзем чагылганын, ямь-яшел үләннәрне күреп гаҗәпләнгәнем әле дә исемдә...

Теге вакыйгадан соң холкым да үзгәрде. Агач башларына малайлардан да уздырып үрмәли идем мин. Боларның барысын да өермә зәхмәте кагылуга сылтадылар. Укырга кереп, яхшы укый, өстәвенә, матур итеп җырлый, гармунда уйный башлагач, «пәри алмаштырган» дигәннәре «фәрештә канаты сыйпаган» дигәнгә алмашынды.

Өч-дүрт елдан апам белән урманга кура җиләгенә бардык. Җиләкнең берсен – чиләгемә, берсен авызыма сала торгач, мавыгып киткәнмен. Бер мәлне күземә чем-кара каз муены күренде. Текәлебрәк карасам, кара елан! Миңа таба сузылып ысылдавы булды, артка авып киттем. Торып, чапмакчы булдым, ләкин соң иде инде... бөтен тәнемне ярып, ниндидер авырту йөгерде. Минем чырыйлап кычкырганга җиләк җыючы апалар килеп җитте. «Зәһәр елан чаккан, исән калыр микән?» – дип пышылдашканнарын ишеттем. Бу юлы да исән калырга насыйп булды.

Урта мәктәпне тәмамлап, Казан педагогика институтына укырга кердем. Шул елларда шигырьләр, хикәяләр язу белән дә мавыгып киттем. Язучылар арасында дуслар, танышлар барлыкка килде. Берсендә бер язучыга кунакка бардым. Өстәлендә касә белән урман чикләвекләре тора. Мин боларны бармак бите белән генә ватып, берәм-берәм авызга итә башладым. Язучы агайның күзе маңгаена менде. Күп булды инде ул кеше куркыткан вакытлар.

Мәктәптә укыганда кушаматым да «Грозный» иде минем. Кыз башы белән аргамакка атланып чапсын, машина, трактор, комбайн, хәтта «КАМАЗ» кадәр «КАМАЗ» йөртсен дә, «Грозный» булмый кем булсын инде ул? Юлыма аркылы төшкән мактанчык егетләрне тотып кына селки идем. Күп бәлаләрдән әнә шулай селкеп салып кына котылып калдым, әмма көннәрдән бер көнне егет сурәтендәге ике аяклы «пәри»дән (шаярып шулай дим) кача алмадым. Кара төндә урлап китеп, үзенә кәләш итте ул мине. Кияүгә чыгу түгел, танышырга да теләмәгән кеше белән яшәве бик авыр икән. Никах та укытмыйча, ата-ананың хәер-фатихасыннан башка гына корылган гаилә, җимерелми, нишләсен? Әле ярый, үземә охшаган, йомшак күңелле, белем, хезмәт яраткан кызларым – Зөһрә белән Илзирәм бар.

Булгач булсын, дигәндерме, Аллаһы Тәгалә миңа күк капусын да ачып күрсәтте. Кап-кара төндә уянып, сихри нур белән өртелгән бүлмәмдә бервакыт һушыма килә алмыйча, шаклар катып утырдым. Өй тулы нурлар әйлән-бәйлән уйнадылар да тәрәзәдән юк булдылар.

Ә теге вакытта елан чагуның файдасы булды миңа: төрле агуларга каршы торырлык көчле иммунитет барлыкка килде. Мәсәлән, миннән көнләшеп, эченә агу җыйган кемсәләр, кәефемне кырырга теләп, зәһәр сүзләр әйтсәләр, йөзләренә карап елмаям. Кайчак хәтта көлеп тә җибәрәм. Кайберләре, миңа кушылып, үзләре дә көлә башлый, агудан арына. Ә инде кайберләре тагын да карала, эчләрендәге агулары артып, үзләрен дә яндыра башлый. Аларны бик кызганам.

*Алсу НӘҖМИ.*

## *Эрудицияле булу, кыю карарлар кабул итү, гомумән, тормышта үз урыныңны табу өчен белемле булу кирәк.*

*Ә минә шул белемне арттыру өчен үзендә никадәр китап, мәгълүмат хәзинәсен туплаучы һәм күз карасыдай саклаучы китапханәләр бар.*

1953 елда өч авылны берләштергән Калмия авыл җирлегендә беренче китапханә ачыла. Дөрес, аңа кадәр клуб бинасындагы «ызбач» дигән бер бүлмәдә күпмедер китап була, ләкин алар кулга бирелми, бары тик шунда килеп укырга гына рөхсәт ителә.

Беренче китапханә ачылганнан соң, аның мөдире итеп Күзкәй авылы кызы Салиха Гыйльметдинова билгеләнә. Ул эшли башлагач, китапханә яңа китаплар белән баетыла, газета-журналларга язылу оештырыла. Биш ел эшләү дәверендә китап фонды 2-3 меңгә җитә. Китапханәдә төрле кичәләр, конференцияләр үтә. Иң актив китап укучылардан ул елларда Фатих Мөхәммәдинов санала.

1958 елда китапханәне Минзәлә районының Тулбай авылы кызы Салисә Гәрәева (шагыйрә) кабул итеп ала. Ике елдан соң китапханәче итеп Альбина Шакирова билгеләнә. Аннан соң китапханәчеләр булып Сәифә Якиева, Сания Каһирова, Гөлбостан Кашбеловалар эшли. Ул чорда китап фонды 6 меңгә җитә, китап укучылар да арта.

1982 елда китап йортын яңа бинага күчерәләр. Аның каршында «Киңәш» ветераннар клубы эшли башлый. Кызыклы очрашулар, гаилә бәйрәмнәре, алтын туйлар, балага исем кушулар, төрле бәйгеләр даими үткәрелеп тора. 35 ел эшләү дәверендә Гөлбостан апа бик күп чаралар уздырды, китап фонды да 10 мең данәгә җитте. Ул елларда китап укучы саны 595 кеше булган.

2007 елдан авыл китапханәсенә Фәйрүзә Гыйльфанова алына. 2009 елдан 2013 елга кадәр – мин, 2013–2016 елларда Гыйльфанова Альмира эшләде. 2017 елның гыйнварыннан яңадан мин эшли башладым. Бүген безнең китапханә яңа китапларга бик бай. Ветераннарның «Киңәш» һәм балаларның «Өмет» клубы даими эшләп килә. Якташ шагыйрьләрне искә алу кичәләре, яшь язучылар белән очрашулар, «китапханә төне», төрле мавыктыргыч чаралар үткәрелә. Күңелле чаралары белән дә, кызыклы китаплары, газета-журналлары белән дә китапханә һәрчак халыкны үзенә тартып тора. Без, китапханәчеләр, халкыбызның рухи чишмәсе саекмасын өчен бар тырышлыгыбызны куябыз.

*Энҗе ГАЛИӘХМӘТОВА,*
*Калмия китапханәсе мөдире.*

**Хөрмәтле укучыларыбыз!**
**Сездән хатлар көтеп калабыз.**
**Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2.**
**e-mail: ssuum@yandex.ru**

PRESSA.RU

ТӨП ТЕМА












# АКБАШЕВЛАР ТӘРБИЯСЕ



Мәдинә
АВЗАЛОВА

ТӘРБИЯГӘ БАЛА АЛУЧЫ ГАИЛӘЛӘР ДИНАСТИЯСЕ – ЙӨРӘК КУШУЫ БУЕНЧА ЭШЛӘНӘ ТОРГАН ИЗГЕ КҮРЕНЕШ УЛ.

Татарстан Дәүләт Советының кече залында Халыкара гаилә көненә багышланган зур тантана бара. Парламент башлыгы Фәрит Мөхәммәтшин тәрбиягә бала алучы гаилә династияләре турында сөйли һәм Рәхмәт хаты тапшыра башлый. Әгерҗе шәһәреннән унике ятимнең бишесен инде мөстәкыйль тормыш юлына бастырган Рушания һәм Шамил Акбашевлар исеме яңгырагач, трибуна янына чандыр гына гәүдәле яшь ханым чыга. «Син үзең дә бала гына бит әле», – ди Дәүләт Советы Рәисе, гаҗәпләнүен яшерә алмыйча. Бүләк алырга Акбашевларның киленнәре – үзе дә 13 бала анасы (10 сы тәрбиягә алынган) Ирина килгән икән.

Ирина белән танышлыгыбыз шулай башланып китте. Ни өчендер, ул үзе турында түгел, ә кайнатасы белән кайнанасы турында сөйләде. Сәбәбен соңыннан – Әгерҗегә барып, өлкән Акбашевлар йортына аяк басуга аңладык.

Капка төбенә үк чыгып каршы алган йорт хуҗасы Шамил, өйгә кереп җиткәнче, безгә әллә никадәрле яңалык әйтергә өлгерә. Ишегалдындагы кечкенә йөк машинасын ул гараждагы өр-яңа чит ил машинасына беркайчан да алыштырмый. «Рәхәт аның белән, кирәк әйберем чыкты исә утырам да китәм...» Ул шулай ди. Балаларын җыеп, урманга да бара. Су буена да алып төшә. Шәһәргә дә барып кайталар. «Җаның ни тели», – дип куя ул. Ә бакчалары, ә атынчык тирәли үсеп утырган виноградлары, беседкалары... Өй артында сузылып киткән ике зур теплица да безнең игътибардан читтә калмый. Аның берсендә – кавын-карбыз, икенчесендә помидор-кыяр үсеп утыра. Кая карама, түтәл, ә анда сугандыр, чөгендер белән кишердер... Кыскасы, букча күтәреп кибеткә чыгып чабасы түгел, ике-өч адымдагы бакчаңа чыгасы да кирәк әйбереңне җыеп алып керәсе генә. «Бездә гел кызлар, яме...» – ди ул, безне алдан ук кисәтеп куйгандай. Кызлар булса ни?! Әйбәт бит инде. Әнигә ярдәмчеләр, булышчылар. Шулай дип уйлап та өлгермибез, ишек ачылып китә дә, без бер көтү бәләкәй кызчыклар уртасында калабыз. Ни өчендер, алар башта безгә шикләнеп-сагаеп карый. Безне алырга килделәр дип уйлыйлар микән?! Елмаеп, һәркайсын аркаларыннан сөеп, исемнәрен сораштыра башлагач кына тынычланып киткәндәй булалар. Ләкин, барыбер, әниләренә сырпалануларын дәвам итәләр. Бала ул бала инде. Аз да үтми, онытылып китеп, берсен-берсе бүлдерәбүлдерә, уенчыкларын, әти-әниләре алып биргән яңа киемнәрен күрсәтеп, мактанышырга керешәләр. «Кызлар бит, нишләтәсең?!» – ди әниләре, канәгать елмаеп. Өйдә – җидәү. Калганнары – кайсы укуда, кайсы эштә, кайсының инде үз тормышы, үз балалары... Без менә шул җиде кыз тирәсендә кайнашабыз. Күп булсалар да, тавышлары ишетелми. Шулай дигәч, әтиләре: «Өйдә мин шыпырт кына, әкрен генә сөйләшәм. Әмма миннән дә катырак итеп берәү дә сөйләшми», – дип, безне уйга калдыра. Әйткән сүзләренең мәгънәсенә шундук төшенәбез анысы. Кем белән гәп куертачагыбызны да чамалыйбыз...

17 бала ата-анасы белән сәгатьләр буена барган әңгәмә барышында ул безгә сөйләшү ятим баланы тәрбияләү мәсьәләсендә генә түгел, гомумән, бала тәрбияләүгә карата мөнәсәбәтебезне тамырдан үзгәртте шикелле. Дөресен әйткәндә, без инде мондый гаиләләр турында күп яздык. Шуңа бу юлы әллә ни яңалык әйтмәбез дә төсле тоелган иде. Ләкин Акбашевлар күңелебезне бимазалап торган уйларыбызны бер җөмләдән чәлпәрәмә китерде дә куйды. Фикер сөрешләренең үзенчәлеген, башка бертөрле булуын күрсәтү өчен алар сөйләгәнне түкмичәчми, сүзгә-сүз җиткерәбез.

*Республикада 2907 ятимне үз кочагына алган 1513 гаилә исәпләнә.*

## *Әтиләре: «Булышабыз түгел, эшлибез»*

– Бу йорт бабам нигезендә утыра. Янәшәдә генә – күршедә минем әти белән әни яши. Әти туксаннан узды, әни сиксән яшен тутырды. Ике йорт арасында киртә булмауга, алар бүген дә үз көннәрен үзләре күргәнгә мин сөенеп бетә алмыйм. Хәтерем бик яхшы минем: әйтик, хәтта дүрт яшемдә ни булганын әйтеп бирә алам. Тормышта төрлесе булды, мин аларның яхшысын да, яманын да онытмыйм. Бик теләсәм дә, оныта алмыйм. Утыз ел күзгә-күз карашып гомер кичергән, 7 нче сыйныфтан бер-беребезне белешеп, яратышып йөргән хатынымның, авырлык килгәндә, миңа хыянәт итүен дә кичерә алмыйм. Хыянәт дигәнемне туры мәгънәдә аңламагыз. Аның төрлесе була. Ул чагында хатын миңа ышанмады. Ә мин аңа әйттем: «Исән-сау барысы да рәтләнә калса, аерылам, китәм», – дидем. Һәм киттем дә. Ә бит мин аңа: «Безне бары Аллаһы Тәгалә генә аера ала», – дигән идем. Менә ничек килеп чыкты. Моңа мин әле дә ышанып җитә алмыйм. Ике улым – Рөстәм белән Маратым да мине бу уемнан кире кайтара алмады.

Рушания белән кушылуыбыз һич уйламаганда килеп чыкты. Ялгыз озак йөрмәдем. Ул вакытта Рушания кибеттә сатучы булып эшли иде. Аерылганын, ике баласы барлыгын да беләм. Кибетенә бардым да әйттем: «Әйдә кушылабыз. Бүген сине сорарга барам». Шулай дидем дә чыгып киттем. Кичен булачак әби белән бабай янына бардым. Ниятемне әйттем. Алар сүз кушарга да өлгерми калдылар, олы яктан җитәкләшеп ике бала килеп чыкмасынмы... «Китәбез», – диләр. Җыендык та безгә кайтып киттек. Ул чагында Резедәгә – 8 яшь, Динарга – 6 яшь.

Мин хатынымның кыз бала табуыннан курка идем. Кыз бала булса, нишләрбез, дип борчыла идем. Нигә шулай булгандыр, әйтә алмыйм. Һәм менә өйгә көтелгән беренче уртак бала кайтты. Кем дип беләсез?! Әйе, әйе, кыз бала! Ул нәни бөтерчек минем бөтен тормышымның астын-өскә китерде. Дөньяга карашымны үзгәртте дип әйтимме. Аннары миңа 44 яшь бит инде. Дианабызга 4-5 яшьләр тирәсе булгандыр, берүзе курчак белән уйнап утыра, әйтеп куймасынмы шул чагын-

ЗАМАН һәм БЕЗ

PRESSA.RU



да: «Сеңлем булса, икәү уйнар идек», – ди. Мин хатынга карап куйдым. «Әйдә, мин әйтәм, Флера (туганнан туган сеңлесе – *авт.*) Балалар йортыннан бер кыз алып кайтты. Без дә барып алабыз». Рушания каршы килмәде. Берәр ел узды микән – бу 2007 елның 6 марты иде – Казанга Балалар йортына киттек. Бер кыз бала алып кайтабыз, дидек. Безгә 7 яшьлек кызны күрсәттеләр. Виктория Андреевна була, диделәр. Без аны бүгенгәчә шулай дип йөртәбез. Шуннан китте инде, бер кызга барабыз дүртне алып кайтабыз. Бер барганда: «Балаларны аермыйбыз, өчесен бергә алсагыз гына, – диделәр. – Менә Катя, менә Миһрибан, менә энеләре Бәйрәм...» Михриша (хәзер аны яратып шулай дип атыйлар – *авт.*) машинага утырмый гына бит: «Туда-сюда йөртергә, мин сезгә кәләш түгел. Юк, беркая да бармыйм». Тәки ул чагында аннан башка гына кайтып киттек. Бер елдан соң Михришаны алырга дип тагын балалар йортына киттек. Бер кызга дип барган идек, өч кыз алып кайттык. Бүген Миһрибан янына кереп чыктым әле. «Кич белән хәлегезне белергә киләм», – диде. «Сездән аерыласым, Алабугага китәсем килми, монда каласым килә», – дигәч, фатир турында үзем кереп сөйләштем. Хәзер аның – үз фатиры. Бик мәгънәле бала булып чыкты ул. Бервакыт мәктәптән кайткан, йөзе ачулы, кәефе кырылган. «Нәрсә булды, кызым?» – дим. Психолог: «Әтиең бәйләнмиме?» – дип сораган да, Михриша аңа: «Ә сезнең әтиегез сезгә бәйләнмиме?» – дип җавап биргән. «Кызым, дөрес әйткәнсең», – дидем. Мондый мәгънәсезлеккә каршы ни дип әйтәсең тагы?

*«Алар инде минем балалар, башка килеп йөрмә, рәнҗетергә ирек бирмәм», – ди ул, кызларын күрергә дип килгән ата-күкегә.*

Бервакыт безгә дүрт бертуган кызны алырга тәкъдим иттеләр. Кечесе йөри дә алмый, йомгак кадәрле генә. Шул бала өчен кәҗә сатып алдык. Җәй ае, балалар – бакчада, тәгәрәшеп чирәмдә уйныйлар. Берзаман яныма килделәр дә: «Бер абый сөт сорый», – диләр. Рушания сөт савып биргән арада, икесенең берсе каядыр юкка чыкты. Ә берсе – өлкәнрәге: «Минем оныклар бит болар, күрергә килдек», – ди. Тегесе әтисе булып чыкты. Төрмәгә утырткан булганнар. Кайткан икән. Ә әниләре – трассада, балалар аңа әллә бар, әллә юк. Бабайны читкә алып киттем дә: «Синең улың не родитель, а производитель, дидем». – Мин кызларымны рәнҗеттермәм. Башка монда килеп йөрмәгез. Берәүнең дә ике тәлинкәдән ашаганы юк әле». Чыннан да, башка килмәделәр. Кызларның олырагына әйттем аннары: «Әти бер генә була ул. Теләсә кемгә ышанмагыз», – дидем. «Курыкмагыз, без сезнең белән», – дидем.

Кайчак балалар миңа: «Әти, булышыйммы?» – диләр. Ә мин аларга: «Бергәләшеп эшләсәк кенә инде, дим. Булышкан кешегә акча түләргә, йә башкача итеп рәхмәт белдерергә кирәк бит», – дим. Алар бу сүзләрнең мәгънәсен аңлады шикелле. Хәзер безнең өйдә «булышыйм» сүзе кулланылмый. Чит илләрдә, мәсәлән, балаларны 16 яшендә өйдән чыгарып җибәрәләр дә шуның белән үзләренең бурычлары тәмам дип саныйлар. Үсеп җитте, хәзер инде үзен үзе карасын. Мин дә шундый фикердә. Гомер буе ата-ана җилкәсендә утыручы соры кортлар күбәеп китте. Әти-әни пенсиясенә яшәүче хөрәсәннәр дә байтак. Үзебез өйрәтәбез ич. Эш түгел бу. Олы улым Рөстәм йорт салып керде. Миңа нибары бер мәртәбә мөрәҗәгать итте. Анда да түбә ябышырга кешесе килмәгән чак туры килде. Шулай эшләп ятабыз, күрше керде. Әйтә бу: «Шамил, ник түбә япканда гына килдең, иртәрәк килмәдең?» – ди. «Иртә килдем әле, – дим. – Мин монда өй туена, тасма кисkәндә генә килергә тиешле кеше». Шулай дигәч, аптырап китте күршем. «Бу нәрсә дигән сүз инде тагын?» – ди. Мине 91 яшьлек әтием шулай өйрәтте. Ул шул яшенә җитеп, миннән беркайчан да ярдәм сорамый. Шуны эшлә, моны эшлә дими. Әкрен генә, үз җаена барысын да үзе рәтләп йөри. Мин чыгып эшли башлыйм икән, ул авыруга сабышып, өйгә кереп ята да инде башка чыкмый. Хәрәкәттә – бәрәкәт дип, тикмәгә генә әйтмиләр. Тормышның бөтен рәхәте шунда бит... хәрәкәттә. Бервакыт Анябыз Анапага барды. «Диңгез күрәсем килә», – дигәч, җибәрдек. Кайтты, авызы-борыны салынган. «Диңгездә йөзә дә алмадым. Суы салкын иде», – дип зарлана кызыбыз. «Бәхет андамы? – дим. – Ул синең яныңда. Әнә, бакчага чык, андагы матурлыкны күрсәң! Диңгезең бер якта торсын...»

Бервакыт районның опека һәм иганәчелек бүлеге хезмәткәрләре: «Балаларыгызны эшләтәсез, дип ишеттек», – диләр. Ә мин аларга әйттем: «Эшләтәм шул. Мин моны түбәгә менеп, бөтен кеше алдында кычкыра алам. Эшләп үсмәгән бала – өметсез бала бит ул». Килештеләр аннары.

Минем чыгымнар һәм керемнәр журналы бар. Шунда барысын да теркәп барам: балаларга күп китә, дип зарланмыйм. Хөкүмәт аларга акчаны җитәрлек бирә. Әйтәсе килгәнем: без кызларны мохтаҗлыкта үстермибез. Бөтен кирәк-яракны әниләре, кызлар белән бергәләшеп кибеткә барып алып кайта. Төрле кеше бар. Акча өчен генә ятим бала карыйлар, дигән фикердә торучылар да җитәрлек бит. Андыйларга: «Сезгә ни комачаулый соң? Тәрбияләп карагыз...» – дим.

### *Әниләре: «Инвалид бала аласы килә»*

– Шамил белми әле бу хакта. Казанга барган саен инвалид бала карыйм. Алар бит ярдәмгә-карауга күбрәк мохтаҗ. Безнең Виктория дә, Ирина да – инвалидлар. Виктория Андреевнага 18 тулды. Аның тулай торакта үз бүлмәсе бар хәзер. Ә Ирина – минем ярдәмчем. Кечерәкләр аның сүзен мине тыңлагандай тыңлый. Ул бөтен нәрсәдә миңа охшарга тырыша. Минем белән бергә ураза тота, намаз укый, ашарга пешерергә дә бик оста ул. Миннән өйрәнә, кухнядан чыкмый. Аны без

өйдә укытабыз. Намазга басканыма – биш ел. Бик тели идем. Мәдрәсәдә укыганда абыстай миңа: «Кызларыңны да укытмыйсыңмы соң?» – диде. Рәхмәт аның бу сүзләренә. Карина, Ирина, Вика, Валерия мәдрәсәгә йөрделәр. Хәзер алар әз-әзләп Коръән укырга өйрәнеп киләләр. Бигрәк тә Валериясе оста булып чыкты. Мәктәптә дә яхшы укый, кул эшләрен дә белә. Без кызлар белән бәйлибез. Кофталар, оекбашлар, бияләйләр... Бәйләмәгән әйбер юк. Келәмгә кадәр эшләп куйдылар әнә. Михриша килеп өйрәтә аларны. Компьютер каршында бик сирәк утыралар. Һәр эштән тәм табалар.

Гаиләдә Шамил – баш, мин – муен. Барын табып, кайтарып торучы – ул. Кулымнан җитәкләп балалар йортына алып баручы да Шамил булды. Балалар йортыннан беренче мәртәбә күргән бер баланы алып кайта тордык. Сайлап торырга тауар түгел ич алар. Виканы алырга барганда, аңа нибары 7 яшь иде. Мине күрүгә, шундук кочагыма ташланды, шундук «әнием!» диде. Әйтерсең, мин озак килми торганмын да хәзер менә килгәнмен. Әле дә хәтердә, икәүләп электричкага йөгерәбез. Ул минем кулыма чатырдап ябышкан. Ычкынып китмәсен, янәсе. Аның әнисе үлгән. Күпмедер вакыт әбисе тәрбиясендә булганнан соң, шул ятимнәр йортына китергәннәр. Ә әтисен әбисе сүзләреннән генә белә.

Иринаның инвалид булуын белгәч, үзем сорап алдым. Психиатрлар кушкан даруларны эчертмим. Балага чиста һава, җылы мөнәсәбәт, чиксез ярату... шулар – дәва. Катяны алырга баргач, без директор кабинетында утырабыз, шул вакыт 15 яшьләр тирәсе булыр, бер кыз бала килеп керде. «Мине гаиләгә тәрбиягә алуларын телим», – дигәч, чактан гына елап җибәрүдән тыелып калдым. Ничек алмыйсың инде менә? Настя исемле кыз бала. Ул чагында документлары әзер түгел иде. Кайтып киттек тә бераздан кире килдек. Качып йөрергә ярата торган бала булып чыкты. Ул чираттагы качкынлыкта иде. Шамил: «Көтәбез!» – диде. Тагын бардык. Бу юлы Настя белән бергә Миһрибанны, Виканы, Диананы да алып кайттык.

2012 елның 13 ноябрендә дүрт бертуган кызны – Валерияне, Каринаны, Арина белән Дашаны алып кайттык. Соңгылары хастаханәдә иде. Бәләкәйләр, чөнки. Шамил белән барып кердек хастаханәгә. Коридорда бөдрә чәчле бер кыз бала йөри. Безнекедер инде, дим. Дашага ул чагында 1 яшьләр чамасы. Бигрәк бәләкәй инде, күкрәгемә алдым да, сискәнеп киттем. Курку да, кызгану хисе дә бар иде. «Нәрсә эшләрбез?» – дим. Өйгә кайтышлый аптекага кереп, бөтен кирәк-яракны алып чыктык. Беренче көннәрдә бала елады да елады. Безгә көн дә юк, төн дә юк. Ул – гел кулда. Шамил белән чиратлашып күтәрәбез. Ә балаларның калганнары су эчә дә ипи ашый. Чөнки алар башка нәрсә күрмәгән. Әкренләп-әкренләп ризык ашарга өйрәттек. Фахишә әнигә, төрмәдә утырган әтигә балалар кирәк булмаган. Дашаны хәтта киендереп тә тормаганнар, караватта шәрә яткан. Сөйли башласаңмы? Ул сабыйларның күргәннәре... Минем өч хыялым бар: Коръәнне белү, машинага утыру, яңа өй салу. Безгә хөкүмәт ун сутый җир бирде. Бик әйбәт урында. Саласы гына калды. Алга таба анысы да булыр, дип уйлыйм. Шамил бик төпле, акыллы кеше булып чыкты ул. Балаларның һәркайсын кеше итәсе, тормышта үз урыннарын табарлык итәсе килә. Аларның берсе дә, үз тормышлары белән яши башлагач, безнең белән араны өзмиләр. Көненә ике-өч мәртәбә шалтыратмасалар, күңелләре булмый. «Нинди ярдәм кирәк?» – дип кенә торалар. Әле менә ураза вакытында, кояш баемыйча, мунча керергә ярамагач, балаларның кечерәкләрен Михришабыз килеп юындыра. Шулай менә. Үземнеке дип тәрбияләсәң, үзеңнеке була. Ятим карауны эшкә санаган әниләр исә соңыннан лаеклы рәвештә үз әҗерен ала.

*Карап, сайланып йөрергә бала тауар түгел. Килеп күргәнсең икән, аласы. Чөнки ул сине: «Әнием килде!» – дип каршылый.*

...37 ел тимер юлда эшләгән тәҗрибәле машинист Шамил Акбашев Рушаниягә өйләнгәч, аны бер көн дә эшләтмәгән. «Машинист хатыны эшләми, ул өйдә ире кайтканын көтеп утыра». Шулай дигән ире. Рушания ханым аның бу сүзләренә кайчак үпкәләп тә куя. Аның да күңелендә генә йөрткән теләге бар лабаса: укытучы буласы килә. Укыйсы, эшлисе... Хәер, ул теләген тормышка ашырган булса кирәк, өй тулы балачага. Һәркайсы өчен әни дә, бөтен нәрсәне белә торган абруйлы укытучы да ул балалары өчен. Яныннан азга гына да китмәгән ул сабыйлар назга, яратуга беркайчан да туймас сыман. «Көненә ун мәртәбә килеп кочакламасалар, күңелләре булмый». – ди Рушания ханым. Чыннан да шулай. Ә ничек матур итеп аңа «әни!» дип дәшәләр. Тыңлап туймассың. Сагынган, бик сагынган, күрәсең, алар бу кадерле сүзне. Әниләрен сагынган, төннәрен карават янына килеп, өсләренә юрган ябуны, битләреннән чуп итеп бер үбеп куюны, иркә сүзләрне ишетүне сагынган. Ә тагын... тагын әниләре бертуктаусыз кабатлый торган: «Курыкма, без синең белән», дигән иң-иң кирәкле сүзләрне тансыклаган алар.


Бүген аларның балалары да, әти-әниләреннән күреп, тәрбиягә балалар алганнар. Рөстәм белән Ирина – 10 бала, кызлары Резедә 2 бала алган. Шундый була инде тәрбиягә бала алучылар династиясе – шәфкатьлеләр династиясе.

Җыелышып, ашыкмый гына җәйгә атлаган табигать кочагына чыгабыз. Балалар шундук урамга сибелә. Йөгерешә, шаярыша башлый. Уйнап арыган нәни Даша әнисен килеп кочаклый, аңа калганнары да кушыла. Бәхетле әни үзен чиксез яратучы сабыйлар арасында калып, ике кулын җәеп җибәрә. Ни диясең инде моңа?! Әтиләре әйтмешли, бәхетне аны читтән эзләргә кирәкми. Ул, чыннан да, синең бетмәс-төкәнмәс нур бөркелгән күңелеңдә, җитмешкә телгәләнгән җаныңда бит.

PRESSA.RU



**Аның группасында 15 меңнән артык кеше, 2 меңгә якын фото, 60 лап видеоязма... «ВКонтакте» битендәге дуслары гына да 1000 ләп. Аның исемен җыйсаң, Яндекс 5 мең биткә сылтама бирә. Югыйсә танылган җырчы да, сәхнә йолдызы да түгел. Гап-гади авыл хатыны. Хәер, бигүк гади дә түгел бугай...**





Лилия ГӘРӘЕВА

# ИНТЕРНЕТТА – «МӘРЬЯМ БИТЕ»







Азнакай районының Мәндәй авылына Мәрьям Миңнеголованы юллап барыш. Кайсы йорт аларныкы икән? Ике кулына ике чаңгы таягы тотып, тиз-тиз атлап килүче апа бермәл кем турында сораганыбызны аңышмый тора. Аннары, йөзе белән балкып: «Ә-ә! Сезгә тортлар пешерә торган Мәрьям кирәктер. Мәчет каршында гына алар», – дип, юлны өйрәтеп җибәрә.

...Капканы яшь кенә бер ханым ача. Шәһәр кешесенә охшаган. Туганыдыр, мөгаен. «Мин – Мәрьям», – дип танышырга кулын сузган бу ханымга ышаныргамы, ышанмаскамы? Ышанып идек, без бит егерме биш елдан артык сыер сауган авыл хатынын күрергә килдек. Ышанмый да булмый, бит очындагы мәхәббәт уймаклары тач Мәрьямнеке.

### Тормышка имтихан

Өстәлдәге күәс чиләгенә буе да җитмәгән Мәрьям, урындыкка менеп басып, ипи баса. Бер салганда мичтә алты ипи пешә. Биш абыйга бер сеңел бит ул, аларны ул кайгыртмый, тагын кем кайгыртсын?! Әниләре яшьли китеп бармаган булса, бу балага нинди ипи басу әле югыйсә. Тормыш имтиханын әнә шулай бик иртә тапшырырга туры килә аңа. Ярый әле әбиләре бар. Дөнья көтәргә өйрәтүчесе ул Мәрьямнең. Әбисе күрмәгәндә итәк очын бармак бите белән генә чеметеп, зырылдап бер бөтерелеп ала кызчык. Бик тә артист буласы килә аның. И хыялый! Анда авыл кызларын алмыйлардыр шул. Хыялларына богау салып, Мәрьям документларын университетка тапшыра.

Ай, ул көннәр! Керүчеләр исемлегендә үзенең дә булуын күреп куанулары, олы шәһәр тормышын уйлап хыяллanulары! Әмма... ак колонналар арасыннан йөгереп кенә аудиторияләргә узу насыйп булмый. Уңышсыз ясалган бер операциягә икенчесе ялгана, өченчесе... Белемне барыбер ала ул – Чаллының сәүдә техникумын тәмамлый. Кем белә, теге чакта Казанда укып калган булса, Фәритен очратыр иде микән? Бәлки, ул сынауларны язмыш аңа нәкъ менә бәхетен очратсын өчен әзерләгән булгандыр...

### Бәхетебез авылда булган

1992 елдан, Чаллыдан Мәндәйгә күченгәннән бирле, 25 ел сыер сава Мәрьям. Ап-ак халат, крахмалланган биек ак калфактан шалт та шолт счет төймәләре тартырга күнеккән кибетче кызга фермадагы авыр эшкә күнегүе кыен булганмы, дисәм... Мәрьям аның кыенлыгын оныткан инде. «Авылда кибеттән эш булыр, дигәннәр иде, булмады, фермага барырга туры килде. Яңа бозаулаган таналардан группа тупларсың, диделәр. Авыл бит ул, сайланып тора алмыйсың. Кайнанам иртәнге өчтә уятып, капка төбеннән озатып калган иде. Бергә эшләгән апалар, болай итәрсең, савым аппаратын болайрак каптырырсың, дип, бер-ике күрсәттеләр дә, үз сыерлары янына киттеләр. Таналарымны савым станына куып кертеп кенә булмый бит. Утар буйлап йөрибез чабышып. Мең җәфа белән берсен тотып, аппаратны каптырдым гына, кытыгы килдеме, типте очырды. Үҗәтләнеп, тагын барып ябыштым. Озак еллар буе эшләп, остарып беткән апалар: «Ай, бу бала кая килгәнен белеп килде микән?» – дип баш чайкап карап торалар икән. Шулай да аларның ярдәме белән эшкә өйрәндем. Аеруча Шәфигулина Гөлфия апага рәхмәтем зур. Аннары, тора-бара, таналарым да ишәйде, үзем дә остардым», – дип, Мәрьямнең фермадагы беренче эш көнен искә төшереп, көлешеп тә алдык. Сыер савуны авыр эшкә санамый да ул.

*Авылга кайтып, фермага эшкә менгәндә миңа 18 яшь иде. Үкенмисеңме, диләр. Үкенмим.*

25 ел дип әйтүе генә җиңел, уйласаң, үзе бер гомер бит! Шушы гомер эчендә табышлары да, югалтулары да булган... Бик акыллы, тәртипле Миләүшә белән Айдарлары, бүгенге матур-җитеш тормышлары, Фәритем-Мәрьямем, дип, бер-берсенә әле дә өзелеп торыр өчен яшьлектәге хисләрен саклап калулары... – болары, табышлары, билгеле. Югалтулары... Тормыш югалтуларсыз гына барса ла ул! Иң үзәген өзгәне – абыйсының аварияда яшьли гомере өзелеп, бер яшьлек баласының ятим калуы. Ул ярасы бүген дә сулкылдый.

### Медальләр чыңы

Авылда яшәп, спорт белән дә шөгыльләнергә вакыт һәм җай тапкан ничә гаиләне беләсез? Килешәсездер, сирәк алар. Мәрьям белән Фәрит Миңнеголовлар әнә шул сирәкләр инде.

Армрестлинг – кул көрәше – Фәритнең күптәнге шөгыле. Шөгыле дип, алай җитди шөгыльләнмәгән дә,









PRESSA.RU



дус-иш арасында гына сынаштыргалаган беләгенең көчен. Ә менә Миләүшәләре спортның бу төре белән ныклап кызыксынып киткән. Башта – мәктәптә, аннары – районга, республикага чыккан. Армрестлинг «чире» өйдәгеләрнең барысына да «йоккан» берзаман. Сабан туенда көндәшләрен «чүпләп» кенә барган Мәрьямне тренер да күреп алган.

...Кичке эңгер төшкәндә болынга таба икәү йөгерә. Бер көн шулай, икенче көнне... Бу икенең Фәрит белән Мәрьям булуына берәү дә аптырамый. «Әллә марафонга әзерләнәсез инде?» – дип шаярта күрше-күлән. Марафонга түгел, кул көрәше буенча республикада узасы ярышка әзерләнүе Мәрьямнең. Армрестлинг белән йөгерүнең ни бәйләнеше бар, диярсез. Бәйләнеше бар икән шул аның. «Республика буенча ярышка барыр өчен 65 кг авырлыкта көрәшергә кеше кирәк. Тиз арада шушы категориягә туры килерлек итеп ябык! 20 көн вакыт бирәм», – ди аңа беркөнне тренеры шалтыратып. Икенче көнне Мәрьям эшкә спорт костюмы һәм җиңел кроссовкалардан килә. Башкалар автобуска төялешә, Мәрьям автобус артыннан җәяү элдертә. Йөгерү килешә, егерме көндә алты килога ябыга.

Турнир узгач та бу мавыгуларын ташламый алар. «Моңарчы гел башым авырта иде. Йөгерә башлагач, башымның сызлавы бетте», – ди Мәрьям. Кышкы суыкта йөгереп, тамагына салкын тидергәч, Фәрит өйләренә тренажер – «йөгерү юлы» алып куя. Рәхәтләнеп йөгерсен менә хәзер Мәрьямкәе.

*Ашарга пешерү – минем «чирем» инде ул. Бүген пешермәм дип уйлыйм да, кул барыбер табага үрелә.*

### *Мәрьям тортлары*

Аның белән без «ВКонтакте» челтәре аша таныштык. Әле үзен дә белмибез, кайда яшәгәнен дә, ә менә гаиләсенә нәрсә пешереп ашатканыннан һәр көнне хәбәрдар идек. Бүген кемнәрдә нинди яңалыклар бар икән, дип, интернетны ачсаң, Мәрьямнән көн саен бер яңа рецепт. Кичә суган сумсасы иде, бүген бәлеш... Аның коймагы да башкаларныкы кебек түгел, челтәр-челтәр, кабартмалары да гөбердәп тора. Янына гади генә итеп пешерү тәртибен язып куйган. Төшке ашка гына кайткан җиреннән дә тиз генә тәбикмәк пешереп, фотосын интернетка чыгару аның өчен берни түгел. «Хәерле көн, дусларым!!!!!!!! Төшке ашларыгыз тәмле булсы-ы-ын! Тәбикмәк кефир белән!» дип кызыктыра ул әнә.

«Бу Мәрьям бөтен фигураны бозып бетерде инде. Әллә нинди тәмле ризыклар пешереп кызыктыра да, бүген пешермәм дигән җирдән, торып, шуны пешереп карыйсы килә», – дип «зарланыша» дуслары да.

Без дә көн саен ашарга әзерлибез, әмма Мәрьям кебек көн дә камыр кую, таба ризыгы әзерләү, аны фотога төшерү, пешерү тәртибен тәфсилләп язып, һәр көнне интернетка кую гына хәлебездән килми. Вакыты да җитми, теләге дә. Ә ул фотолар белән генә калмый, пешергәнен видеога төшереп, «Ютуб»ка да чыгара. «Сезнең каналны карап барам. Сез кайсы милләттән? Бу кайсы халык ашлары?» – дип сорау бирәләр аңа. Татарча тәмле генә итеп сөйләп, ак яулыгын чөеп бәйләгән, чәчәкле күлмәге өстеннән, билен өздереп, матур алъяпкыч япкан татар ханымы әнә шулай итеп, биек мөнбәрләрдән ялкынлы нотыклар тотмый гына, үз җаена татар милли ашларын, татар халкын дөньяга таныта.

Каян вакытын таба ул, ничек өлгерә? Әле бит гаиләсе өчен генә пешерсә – бер хәл, аның матур тортларын, гөбәдия, чәкчәкләрен күреп, безгә дә пешереп бир, дип сораучылар да күп. Дусларына күчтәнәчкә генә дип пешереп алып барган тортының тәме «сарафанлы радио» аша еракларга таралган инде. Бик тәмле шул аның тортлары. Кибетнеке бер якта торсын! «Бер тортның фотосын куйганчы, без аны алты-җиде тапкыр пешереп ашаган булабыз инде. Шул калорияләрдән котылу өчен йөгерәбез аннары», – дип шаярта Фәрит.

Артык калорияләр йокмый ла ул Мәрьямгә. Сез әле аларның бакчаларын күрсәгез! Җиләк плантацияләрен! «Җиләкне бик аз җирдән генә башлаган идек, арттыра барабыз. Нинди сорт икәнен дә белмибез. Күбесе, ничек карыйсыз, дип сорый. Белмим, аның бер сере дә юк инде. Мыекларын кисеп, йолкып утырганыбыз юк. Яздан тырма белән генә йөреп чыгабыз. Безнең урыны кояшлы җирдә, язын кардан тиз арчыла, мөгаен, шуңа күрә уңадыр, – ди ул, берәр сере бармы әллә дигән соравыма. – Узган ел көн аралаш җиде-сигез чиләк җыеп керә идек. Артыгын саткаладык та».

Кайдан вакыт таба, дигән сорауны аңа без генә түгел, интернеттагы дуслары да еш бирә. «Бар тормышыңны эшкә багышлыйсың. Үзеңне кара, ял итәргә бар, концерт-театрларга йөр», – ди беркөнне танышым. Бәлки, ул дөрес тә әйтә торгандыр. Үземнән чыгып әйтәм, теләге булган кеше, вакытын дөрес итеп бүлә белгән кеше, тормыштан ямь табып яши белгән кеше, мөгаен, барысына да вакыт табадыр, – ди Мәрьям. – Аллага шөкер, гаиләм белән дә, дусларым белән дә ял итә беләбез. Кыш көне концертларга да йөрибез. Авыл клубында бәйрәм саен үзебез дә концертлар куябыз. Миңа бит Фәритем бик булыша. Әлбәттә, кухня тирәсендә аңа йөрергә кушмыйм, үзем генә иркенләп эшләргә яратам. Ә ул минем өчен барлык уңайлыкларны тудыра. Тегеләерәк итсәк, ничек булыр икән, дисәм, ул берсүзсез мине тыңлый, кирәк әйберемне алып кайтып бирә. Тортлар ясаганданиләр кирәген ул да миңа карап өйрәнеп бетте инде».

Бүген кичкә нәрсә пешерергә белмәсәгез (без, хатын-кызларның, еш кына шулай да була), сез Мәрьям битенә кереп карагыз. Рецептлар гына түгел, ихлас аралашу, эчкерсез дуслык та бар анда. Һәркемгә үз итеп, үзенчә ягымлы итеп эндәшер ул: «Дусларыыыыымммммм! – дияр. – Мине югалтмагыыыыыз! Бүген шәһәргә барам. Тырнакларымны гына ясатып кайтам!» – дияр. Менә шундый кеше инде ул Мәндәйнең Мәрьямкәе.

## ҖӘМГЫЯТЬ

■ **Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов Кырым Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Владимир Константинов белән очрашты. Алар багланышларны төбәкара дәрәҗәдә үстерү буенча фикер алыштылар. Шулай ук Татарстан һәм Кырым арасында парламентара хезмәттәшлек турында беренче килешү имзаланды. Документка ике парламент башлыгы – Фәрит Мөхәммәтшин һәм Владимир Константинов кул куйды. Моннан тыш, Кырым Республикасы делегациясе Инвестиция үсеше агентлыгында һәм «ИТ-парк»та булды.**

■ **Мәскәүдә, Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге вәкаләтле вәкиллегендә Татарстан парламентаризмы үсешенә багышланган «Зур сәясәт чоры» фильмын тәкъдим иттеләр. Чарага Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Россия Дәүләт Думасы депутатлары, Федерация Советы әгъзалары, фильмдагы тарихи вакыйгаларны бәян итүчеләр чакырылган иде.**



## МӘДӘНИЯТ

■ Конфедерацияләр кубогы көннәрендә «Казан Кремле» музей-тыюлыгында «The Kremlin Confederation of ART» фестивале узды. Балалар һәм үсмерләрнең вокал, хор, хореография коллективлары чыгышы республиканың талантларга бай булуын раслады.

■ Танылган сынчы-рәссам Бакый Урманченың улы Айдар Урманче әтисеннән мирас булып калган бай китапханәсен – ислам диненә, татар әдәбияты тарихына, сәнгатькә, халык авыз иҗатына караган 700 исемдәге гарәп, фарсы, төрек, татар, рус телләрендәге китапларны Татарстан Республикасы Милли китапханәсенә тапшырды. Анда XVIII гасырга караган тарихи кульязмалар, Утыз Имәни, Габделҗаббар Кандалый әсәрләренең кульязмалары, догалыклар, татар телендә Коръән тәфсире һәм башка хезмәтләр бар.

## СПОРТ

■ Россиянең дүрт шәһәре – Мәскәү, Санкт-Петербург, Сочи һәм Казан футбол буенча Конфедерацияләр кубогы турнирын кабул итте. Футбол сөючеләрнең игътибары Казанда булды. «Казан – футбол шәһәре, анда Көнчыгыш һәм Көнбатыш мәдәнияте кушылып, спорт бәйрәмен бер-берсе белән татулыкта үткәрә беләләр», – диде Халыкара футбол федерациясе президенты Джанни Инфантино. Казанга иң көчле командалар – Мексика, Португалия, Германия, Чили футболчылары килде. Арада атаклы уенчы Криштиану Роналду да бар иде. Татарстан башкаласы кунак командаларны чәкчәкләр белән каршы алды. Конфедерацияләр кубогы футбол буенча Дөнья чемпионаты алдыннан репетиция буларак уздырыла. Чили футбол командасы Конфедерацияләр кубогының беренче финалчысы булды. Ул ярымфинал матчында пенальти сериясендә 3:0 исәбе белән җиңде.



## КОТЛЫЙБЫЗ



■ **РФ Президенты Указы нигезендә Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академик опера һәм балет театры солисты, Татарстанның атказанган артисты, Г. Тукай исемендәге республика премиясе лауреты, дөнья операсы йолдызы Альбина ШАҺИМОРАТОВА «Россия Федерациясенең атказанган артисты» дигән мактаулы исемгә лаек булды.**

## ТУРИЗМ

■ 2017 елның биш аенда Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгында 173 мең турист булып киткән. Музей-тыюлык үзе 1969 елда оешкан. Бирედә XIII–XIV гасырның бердәнбер архитектура һәйкәлләре сакланып калган. Музейда экскурсия маршрутлары берничә төрле. Туристлар Ак мәчет, Габдрахман коесы, Икмәк музее, дөяләр фермасы белән танышып йөри. Быел Болгарда «Яр буе» ачылды, анда «Язма мирас» музее эшли. Яр буйлап – Хан сукмагыннан, Шагыйрьләр аллеясыннан үтәргә мөмкин. Причалга туктаган теплоход туристларын Болгар ханы һәм ханбикә образындагы геройлар чәкчәк белән каршы ала.

## МӘГАРИФ

■ **КФУ галимнәре Татарстан тарихы буенча яңартылган укыту комплектын әзерли. Урта һәм югары сыйныф укучылары өчен Татарстан тарихыннан белем бирә торган әсбаплар төзү проектын татар балалар нәшрияты тормышка ашыра. Бу зур эшкә Президент Аппараты тәкъдиме буенча, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан университеты белән берлектә тотынды. Хәзер төбәк мәктәпләрендә 5–6 нчы сыйныфлар өчен дәреслек актив кулланылышка кергән.**

PRESSA.RU






Фото: Анна Арахамия



Мәдинә АВЗАЛОВА

СИРӘК БУЛА УЛ АНДЫЙ ПАРЛАР. АЛАРНЫҢ ЭШЛӘГӘН ЭШЛӘРЕ ГЕНӘ ТҮГЕЛ, ХӘТТА УЙЛАГАН УЙЛАРЫНА, ӘЙТКӘН СҮЗЛӘРЕНӘ КАДӘР БЕРТӨРЛЕ.

# БЕЗ ИКЕБЕЗ БЕРТӨСЛЕ...

Кайчандыр, бик күптән, борын-борын заманнарда биregә өч кеше килеп утырган. Бу якларга каерылып, тукталып та тормаслар иде (ул вакытларда җирләр хәттин күп булган бит), табигате гаҗәеп булган аның. Янәшәдә генә Иске Арыш авылы булгангамы, соңыннан аны Яңа Арыш дип атый башлаганар. Хәзер ул 362 хуҗалыклы зур авыл. Ерактан ук күренеп, балкып, нур таратып торган яңа мәчете, Илдар буасы, Рамил буасы дип йөртелә торган чиста-тирән күлләре, авыл уртасында гына агып яткан чишмәләре... Һәм булсынга, артсынга дип көнне дә, төнне дә белми җир тырмашып эшләгән авыл кешеләре... «Безнең авылда Президент туган», – дип мактанышып та куяр алар.

Аның: «Авылны яратам, сулаулары икенче...» – дип әйтүенә бер дә гаҗәпләнмим. Миңа калса, бу авыл кешеләренең һәркайсы шундый, туган җиренең бер патриоты, дип әйтимме. «Нур» мәчетен салганда да, «идәне җылы булсын, кыш көннәрендә дә килеп йөрерлек булсын», дип, аны «биш катлы» итеп җәйгәннәр. Ул ничек була торгандыр инде, анысын сораштырып тормадым. Иң мөһиме: җылы хәзер анда, аяк асты «май кебек». Авыл уртасында исраф булып яткан чишмәне дә чистартып, буралатып аласы бар. Монысын да алар әйтә. Тыңлап тора башласаңмы?! Әйтәм бит, Яңа Арыш һич тә бетүгә бара торган авыллар исәбенә керми. Гомумән, бездә хәзер андый авыллар юктыр да ул. Инвесторларның нәрсәгә кирәге бар алайса? Ә биредә «Рацин»га караган «Балык Бистәсе корпорациясе». Әйе, әйе, хуҗалык шулай дип атала. Һәм тагын халыкны сөте-мае, каймагы, ите белән әледән-әле куандырып торган фермер хуҗалыклары. Шул була инде ул «импортозамещение» дигәнең!

Без хәзер шуларның берсендә – Мәдинә һәм Әнәс Гыйлемхановлар хуҗалыгында. Ике катлы зур йортның зур кухнясында кайсы нәрсә эшләгән хатын-кызлар безне күрүгә җанланып китә. Әнә ике кодагый ни хактадыр берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә сөйләшә. Әнә апалары Зәмзәмия белән Миңсылу, күршеләре, дус-ишләре... Ярдәмчеләр җитәрлек, кыскасы. Мәдинә ханым безне аларның һәркайсы белән аерым таныштыра.

### *«Сөйгәнең белән алачыкта да оҗмахтагы шикелле»*

– Ә хуҗа кайда?

– Хуҗа – маллар янында, – ди хуҗабикә, елмаеп. – Мин дә аның янында буласы кеше. Сез килгәнгә генә... Гел бергә без, үзебезне белә-белгәннән бергә.

Алар икесе дә бер мәктәптә, бер парта арасында утырганнар.

– Сигезенчене тәмамлагач, Әнәс училищега – тракторчы һөнәрен үзләштерергә китеп барды. Ә мин укуымны дәвам иттердем, – дип сөйли Мәдинә. – 25 май соңгы кыңгырау көне иде. Ул кайтты. Мине шунда беренче мәртәбә өйгә кадәр озата барды.

Бер уйлаганда, аның язмышы ул елларда мәктәп тәмамлаган йөзләгән, меңләгән кызларныкыннан бер ягы белән дә аерылып тормый шикелле. Мәдинә дә, унынчыны тәмамлагач, башкалар кебек, бер ел фермада сыер сауган. Элек бит шундый гадәт булган: кыз һәм малайларга, бер ел колхозда эшләмичә, аттестатларын бирмәгәннәр. Ә аннары... кайсы кая таралышкан. Кайсы – институтка, кайсы – техникумга. Мәдинә дә, шул шаукымга кушылып, Казанга китеп, фабрикада эшләп караган. Юк, ошатмаган. «Сигез ай гына эшләдем дә, ашкынып, авылга кайттым», – ди ул.

> *Берәүләр җәйге ял саен чит илгә китә, ә минә ул Казанга барып кайтуны да зур бер ялга саный.*

Ул клубка эшкә урнаша. Әнәс белән аралар азга гына да өзелми. Егет училищеда чагында аны башка егетләр дә озата кайтмый түгел. Әмма кыз гел аларны Әнәс белән чагыштыра: бусы тәмәке тарта, монысының әти-әнисен белмим, бусы – тупас телле... Әнәстән дә шәбе, тәртиплесе юк икән бит!

1990 елның 15 мае. Мәдинәнең бу көнне гомер онытасы юк. «Төнге 12 ләр тирәсе, – дип сөйли әңгәмәдәшем. – Әнәс белән клубтан чыктык та әкрен генә юл буйлап барабыз. Берзаман яныбызга җиңел машина килеп туктады. Безне машинага утырырга чакыралар. Әнәснең дуслары булгач, утырдым инде. Ә алар машинаны туп-туры егетем яшәгән йорт каршына китереп туктатты. «Нишләвегез бу?» – дим. Әнәс мине күтәреп алды да, өенә алып кереп китте. Ә анд-а-а, өй тулы халык, түргә табын әзерләгәннәр. Алай икән, дим. Әнәс мине урлады. Ул чагында шундый гадәт бар иде авылда. Мин – бары аңа гына кияүгә чыгам дип торган кеше, моңа бик риза инде. Ни дисәң дә, биш ел яратышып йөргән кешеләр ич без. Шундук – төн уртасында минем әти-әнине, туганнарны чакырып алдылар. Күз алдына китерәсезме?! Шулай чыктым мин кияүгә. *(Ул көлеп җибәрә.)*

PRESSA.RU







Хан сараедай йортта яшәүгә ирешкәнче, Гыйлемхановларга бик күпне күрергә, хәсрәт-борчулар кичерергә туры килә әле. Бу йорттагы кечкенә генә бер кашык та зур тырышлык куеп табылган! Кашык дигәннән... «Өйләнешкәндә безнең ике тимер кашык, ике тимер кружка, ике калай тәлинкә, бер иске кәстрүл бар иде, – дип искә ала ул елларны хуҗабикә. – Тормышны шуннан башлаган кешеләр без. Бездәге юклыкны күреп, олы апам Зәмзәмия белән Фәрит җизнәм ике чиләк савыт-саба күтәреп килде. Монысын да һич онытасым юк. Аннан соң аерылып чыгып, иске генә бер өйдә яшәп карадык. Ул чагында беренче балага авырлы идем. 1991 елның 2 июне... Мин ашка киттем. Бервакыт артымнан ук: «Өегез яна» дип йөгереп килеп җиттеләр. Нидән чыккандыр ул ут, әйтә алмыйм. Өй янып бетте, ә без урамда ялангач калдык. Яңа мунча салган идек. Калган бар әйберне шуның алачыгына күчердек тә шунда яши башладык».

*Әлегә уйлаган-ниятләгән һәр эше чынга аша тора.*

Авырлык, ә бигрәк тә бәла-каза килгәндә, авыл халкы бердәм бит ул. Гыйлемхановларга да булышалар. Хөкүмәт бура белән ярдәм итә, ә туганнар, дуслар өй салыша. Яңа йортны алар соңыннан, бераз хәлләнә төшкәч салырга керешә. Ул вакытка инде бер-бер артлы өч малай туган була. Әти-әниләренең горурлыклары булып үскән Илфрузга бүген – 26, Фирдүскә – 22, Дилүскә – 18 яшь. Олылары институт тәмамлап, эшлиләр дә инде. Ә кечесе КФУда укый. Фирдүс белән Дилүс – көрәшчеләр, ярышларда төрле призлар яулыйлар. «Әнә ул тибрәткеч кәнәфине Дилүс алып кайтты», – ди әниләре, йокы бүлмәсендә торган ак кәнәфигә күрсәтеп. Шул арада шушы өйне салганда Дилүснең икенче каттан егылып төшеп, бөерен зарарландыруына офтанып та ала.

Балалар ял саен авылга кайта. Фирдүсе шундук трактор янына чыгып йөгерә. «Техниканы бик ярата анысы, – ди Мәдинә ханым. – Улларымның өчесе дә тракторчы һөнәрен үзләштерде. Кирәк икән, теләсә кайсы утыра ала». Эшмәкәр ханым үзе дә тракторга утырырга хыяллана. Машинаны йөртә лә ул. Ә менә тракторга утырганы юк әле. Ә утырасы, дөньясын онытып, җилдереп кенә кырларны бер әйләнеп чыгасы килә. Хәер, булыр аннан. Теләгәнен тормышка ашыра торган кеше бит ул. «Теләгән һәрбер нәрсәм, теләгән һәрбер хыялым гамәлгә ашып бара», – димәс иде, шулай булмаса.

## Сынауларда сынатмас

Мәдинә ханым үзен гел яңа эштә сынап карарга ярата. Шунсыз тора алмый бугай ул. Декрет ялыннан соң, фермага төшеп, сыер сауган. Аннары үзе теләп яңа ачылган мини-пекарняда ипи пешерә башлаган. Бик тәмле пешергән. Авылдашлары ул пешергән икмәкне көтеп ала торган булган. «Аның әллә ни сере юк, – ди ул, белгән кадәресе белән уртаклаша башлап. – Суга чүпрә белән әз генә он салып әчетәсең дә, янә тоз һәм суга он кушып басасың. Бөтен хикмәт – әчеткечтә. Бик тәмле була». 2005 елда аны заготовитель (хәзерләүче) итеп куялар. Заманына күрә хөрмәтле, мактаулы эш. Ул вакытларда бу вазыйфаны теләсә кемгә ышанып тапшырмаганнар да. Үзе әйтмешли, дебетны кредиттан аерырга ул шунда өйрәнә. Һәм... ниһаять, 2012 елда, ире белән киңәшләшкәннән соң, фермер хуҗалыгын оештырып җибәрү өчен грант алырга документлар җибәрә. Һәм ота да. 500 мең сум акчага әллә ни җәелеп китеп булмаса да, күп эш эшләнә: 12 баш мөгезле эре терлектән, 5-6 аттан башланган хуҗалык бүгенге көндә гөр килеп тора. Терлекне 150 башка, атларны 12 башка җиткергәннәр. Атларны ит





өчен генә асрамыйлар. Арада тупырдап торган, капканы киереп ачсаң, атылырга торган чабышкылар да бар.

– Фермагыз еракмы? Әйдәгез, киттек...

Ир белән хатын бер-берсенә карашып, көлешеп ала.

– Бик ерак, капкадан чыгуга ун адымда гына...

Менә сиңа, кирәк булса... Ә без авыл читендә дип торабыз.

– 250 гектар җир бүлеп бирделәр. Анысы авыл читендә, – ди уйларымны укыгандай Әнәс. – Шунда яңа ферма салырга уйлыйбыз.

– Әле хәбәр иттеләр: без янә 5 миллион сум грант оттык, – ди иренең сүзен эләктереп алып хатыны, – 5 миллион сум! Сыерларны 200 башка җиткерербез дип торабыз. Аннары... яңа эш урыннары да булдырачакбыз. Бу – грант алучы өчен төп шартларның берсе.

Алар бөтен эшне үзләре башкара: ә бу исә, көн дә ике мәртәбә 15 баш сыер саву, терлек асларын чистарту, ашату-эчертү, көтүгә куу, 250 гектар җирдә чәчелгән печәнен, бодаен дисеңме, арпасын-солысын дисеңме, чәчү һәм җыеп алу, кайтарту һәм башкасы, һәм башкасы. Өстәвенә, каз-үрдәкләр, чебешләр... 87 нче яше белән барган Мәдинәнең әнисе Миңзифа карчыкның: «Балакайларым кайтып кермиләр, эш тә эш аларга», – дип, кызы белән киявен кызгануымы, мактавымы... Карчык балалары күрсәткән кадер-хөрмәтне күреп бәхетле булса, балалары алны-ялны белми эшләү белән бәхетле. Ир белән хатын, мәчеттә азан яңгыраганчы ук, аяк өстендә. Әнәс авыл буйлап сөт җыярга чыгып китә, ә Мәдинә фермага – сыер саварга. Эш көн саен шуннан башлана.

– Ялга барганыгыз бармы соң? – дигән соравым Мәдинәне нык гаҗәпкә калдыра.

– Ничек инде, – ди ул ихластан, – ничек инде малтуарны калдырып, каядыр чыгып китәсең?! Гомеремә беркайда да булганым юк. Документ эшләре белән күбрәк мин шөгыльләнәм. Машинага утырып Казанга бару – минем өчен олы сәфәр. Аннан, үзенә күрә, кәеф күтәрелеп, ял итеп кайтам. Шул минем ялым. Әнәс тә шундый. Ул да минем кебек кунакка йөрергә, каядыр барып, вакыт әрәм итәргә яратмый. Без икебез гел бертөсле. Шуңа тормышлар әйбәт бара безнең. Бер-беребезне ярты сүздән аңлыйбыз.

Ире дә аның сүзләрен җөпли.

– Урлап алып кайткан хатын шәпме соң?

– Шәбен – шәп, әмма урлап алып кайтканымны хәтерләмим. Ул күзен бераз кыса төшеп, хәйләкәр елмая. Янәсе үзе сөйләсен.

## Аларның уллары – көрәшчеләр: Татарстан батырлары!

Янәшәдә генә үзләренең кибетләре. Аны 2014 елда ачып җибәргәннәр. Анда да кереп чыктык. «Тормышымда яңалык, үзгәреш булмаса, эчем поша башлый. Дөньядан артта каламдыр сыман», – ди бит ул. Шуңа да гел хәрәкәттә. Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгыннан, күп кенә башка ведомстволардан Мактау кәгазьләре, «За трудовое отличие» медале, быел үткәрелгән «Ел хатын-кызы» республика бәйгесенең «Бизнес-леди» номинациясендә җиңүче булу – әйткәненә куәт кенә. Кая, ди, ул тик тору?! Кая, ди, ул үз агымына гына тынычлана барган тормыштан канәгать булу?! Дер селкетеп тота алар дөньяның якасын. Әнә хәзер «иртәгә барып алам», дип торган 5 миллион сум акчаны бик хәстәрләп, кайсын кая бүләргә: ферма салырга, печән чапкычлар, чәчкечләр, тырмалар, печән пресслау җайланмалары алырга, заманча бер ферма салып куярга кирәк. Лизинг-грантка кереп, трактор, комбайн алып булмасмы, дип тә торалар. Эшләгән кешегә эш күп лә ул. Ә алар эшли, тәм табып, яратып эшли. Уңышка ирешүнең, ниятләгәнне гамәлгә ашыруның сере гап-гади – кумәк тырышлык. Икең бер булып яшәгәндә генә, уйлаганда һәм эшләгәндә генә шулай ул. Җитмәсә, үзләре әйтмешли, икесе дә бертөсле бит алар...

PRESSA.RU






Фото: Ландыш Әбүдәрова

# ӘНИЛӘР «КУРЧАК УЙНЫЙ»



Ландыш ӘБҮДӘРОВА

БУ СЕРЛЕ ДӨНЬЯГА МИН УЙЛАМАГАНДА-КӨТМӘГӘНДӘ КИЛЕП ЭЛӘКТЕМ. ИЛҺАМЛЫ, ИҖАТЛЫ КУРЧАКЛАР ДӨНЬЯСЫ.

**Өлкәннәрне тылсымлы балачак иленә җитәкләп алып керергә сәләтле туп-туры юл менә шушы икән, дидем. Курчаклар дөньясы көндәлек тормышны гармонияле итә, аңа үзенә бер әкияти тылсым өрә. Бу дөньяга бер чумганнан соң, мөгаен, анда гомерлеккә каласыңдыр.**

Әлеге дә баягы социаль челтәрләр «гаепле». Инстаграмда кулдан эшләнгән бер куян күреп калдым. Эксклюзив, үзенә килешле киемнәр кидертелгән, менә-менә җанланып китәр дә берәр әкият сөйли башлар төсле, үзенә җәлеп итеп тора. Тик бәясе генә тешләшә: 3000 сум дип куйган авторы.

Бер акча янчыгына, бер кул эшләре кәрзиненә карадым да үзем бәйләп карарга булдым. Ә кәрзинем минем кырыктартма белән бер: курчак бәйләрлек җепләр дә, аңа кием тегәрлек тукыма кисәкләре дә бихисап, килешлесен генә сайлап аласы.

**БЕРЕНЧЕ КИҢӘШ.** Кул эшләре белән шөгыльләнергә яратучы хуҗабикәләргә шуны әйтәсе килә: тәвәккәл булыгыз! Кулдан эшләнгән «эксклюзив» әйберләрне сатып алганчы, үзегез эшләп карагыз. Нәтиҗәсе дә сөендерер – сезнеке дә һичшиксез эксклюзив булачак! Эш барышыннан да канәгатьлек алырсыз, чөнки сез яңа идея белән танышасыз, яңа күнекмәләр үзләштерәсез, үзегез өчен яңа дөнья ачасыз. Хатын-кызга яңа кичерешләр, яңа эмоцияләр, яңа тәэссоратлар һәрвакыт кирәк. Бу аны хатын-кыз энергиясе белән баета.

Интернет сәхифәләрендә курчаклар бәйләргә өйрәткән мастер-класслар да, әзер схемалар да шактый булып чыкты. Баксаң, курчак тегү, бәйләү күптән инде үзе бер сәнгатькә әйләнгән икән. Бу өлкәдә үзенең йолдызлары да барлыкка килгән: Тильда курчаклары (авторы – норвег дизайнеры Тоне Финангер), Татьяна Коннэ курчаклары һәм башкалар. Болар – сәүдә маркалары алган брендлар булып киткәннәре. Өлгеләреннән үк танылa торганнар. Ыргак белән, инәләр белән бәйләгәннәре бар. Бу ысул амигуруми дип атала – борынгы япон техникасы буенча бәйләнә.

**ИКЕНЧЕ КИҢӘШ.** Гадидән башларга кирәк. Өйрәнчекләр, гадәттә, артык тәвәккәл (беренче киңәшкә кара) була һәм катлаулыны сайлап ала. Һәм шунда ук технологияләр белән «бәхәскә» керә. Ахыр чиктә, башлаган эш тәгәлләнмичә кала, күңел кайта. Ә калган эшкә кар ява.

Матур күренгәнен, өйрәнчекләр өчен җайлырак булган схема табып, беренче курчагыма тотындым. Билгеле, куянкай рәсемдәгечә үк килеп чыкмады. Икенче уенчык – хаталар өстендә эш булды. Бу юлы схеманың башкасын сайладым. Ниһаять, күңелгә ятышлы уенчык килеп чыкты. Балаларга да ошады. Ә үземнең күңелдә сандугачлар сайрый, күбәләкләр бии, мин – Пигмалион! Миңа рәсемдәге, башка автор ясаган курчак кирәкми, бушка бирсәләр дә аласым юк, миңа үземнеке кадерле. Илһамланып, канатланып өченчесенә тотынам. Дүртенчесенә... Минем инде җеп, тукыма, тасма, челтәрле кайма, төрле төймәләрдән торган запасларым бетеп килә, мин кул эшләре кибетенә чабам. Андый кибетләр бик күп. Мин аларның һәркайсының адресын, кайсында нинди кирәк-ярак сатылганын, бәяләрне беләм. Ләкин ул кибетләргә кергән саен, сайлау ирeгe алдында югалып калам. Миндәге идеяләр ташкынын буып тоту кыенлаша башлый, кулымнан килсә, кибетне өебезгә генә алып кайтып куяр идем.

**ӨЧЕНЧЕ КИҢӘШ.** Камиллекнең чиге юк. Шуңа да кибеткә барыр алдыннан, нәрсә кирәгeн төгәл күзаллап, хәтта ки язып чыгуың кулайрак. Моның өчен булачак курчакка ниләр кирәгeн мөмкин кадәр төгәл чамаларга кирәк. «Кирәге чыгар, бәлки» дип, кызыгып алган әйберләр тартма төбендә ятып калуы ихтимал. Әрәм-шәрәм итә торган вакыт түгел: хоббилар болай да кыйммәткә төшә торган заман.

Камиллекнең чиге юк, дидем. Минем баштa туган курчаклар образларына куллар өлгерә алмый. Зефиркадан соң бер-бер артлы Парижда яшәүче кыз, Китап укучы кыз, Режиссер кыз, Патша кызы барлыкка килде. Чиратка тезеләләр генә: Льюис Кэроллның «Алиса в стране чудес» әкиятеннән Куян, үзем язган әкиятләрдән геройлар... Китап укучы кызымның «капризларына» да түзәргә туры килде хәтта: киемнәрен килештереп кенә булмый бит! Өч кофта бәйләдем, ике ыштан тектем үзенә. Бакыр чыбык табып, күзлек тә әмәлләргә туры килде. Букча «сорап алды», шарф бәйләтте. Әлбәттә, боларны мин шушы әкияти дөньядан торып сөйлим. Чын мәгънәсендә курчак уйнаган кебек, шулай бит? Ни гаҗәп, шушы шөгылемә утыруга, кечкенә кызларым да комачауламыйлар, үзләренә уен яки берәр мавыгу табып, янәшәмдә кайнаша башлыйлар. «Курчак уйнап» утыручы әниенең күңел халәте аларга да йога, дияргәме соң инде...

*Соңгы елларда үзем «хэнд-мейд» – кулдан эшләнгән әйберләргә мөкиббән.*

**ДҮРТЕНЧЕ КИҢӘШ.** Арт-терапия практикасында курчаклар терапиясе юнәлеше дә бар икән. Моңа гаҗәпләнәсе дә юк. Үз кулларың белән тудырган яки дөньядагы иң якын кешең – әниең тегеп биргән курчактан да җылырак, йомшаграк уенчык була аламы? Андые булганда, пластмассадан койган салкын курчакны кочаклап йоклыйсы килми шул. Балаларга мондый курчакларның күзләре урынында ике төртке генә торуы, авыз-борыннарның булмавы да ошый. Боларны ул үзенең фантазиясенә калдыра.

Ә иң мөһиме: мондый курчаклар – менә дигән бүләк! Балаларга гына түгел, иптәш кызларыма, туганнарыма рәхәтләнеп бүләк итәм. Билгеле, мин дизайнер түгел, әмма аларның һәркайсына кул җылысы кергән, һәркайсы эксклюзив, бөтен матурлыклары да камил булмауларында... дидем дә, «Бу сүзләрне мин язаммы соң?» – дип хәйран калдым әле. Чөнки кайчандыр мин кул эшләре белән «җенләнүчеләргә» бик ерактан, хәтта ки биектән торып караган кеше. Үземне, кулымнан килми, ялкаулыгым көчле, дип ышандырган чаклар. Буш вакытны заяга уздырган чаклар булган икән ул.

PRESSA.RU






Равил Гарифулла улы ХӘЙРУЛЛИН. Зоотехник, колхоз рәисе, авыл хуҗалыгы идарәсе җитәкчесе, район башлыгы... Арча, Питрәч, Балык Бистәсе... Кайда гына эшләсә дә, ул иң элек кешеләр турында кайгырткан. Тырыш, булдыклы, гадел... Аны шулай бәялиләр, шулай хәтерлиләр. 2010 елдан ул – Татарстан көрәш федерациясенең башкарма директоры. Безнең көрәшчеләр бүген ярышларда Россия буенча алтын медальләрнең 60 процентын яулап баралар икән, монда аның да өлеше бар. Россиянең һәм Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре. СССРның спорт мастеры – бүләкнең монысына ия булучылар безнең республикада бармак белән генә санарлык. Буш вакытында тарихи китаплар укырга ярата. Аристотель, Сократ һәм Солон кебек фәлсәфәчеләрнең хезмәтләре белән таныш.

# «БУЛМАСТАЙНЫ ХЫЯЛЛАНМАДЫМ...»



**ТАМЫРЛАР** 1952 елны Саба районының Курсабаш авылыннан 18 кыз вербовка белән Себергә чыгып китә. Алар арасында минем әнием Рәсилә дә була. Эти белән алар шунда очрашып кавышалар. Әнигә 22 яшь булганда мин туам... Эти исә өйләнүгә армиягә китеп бара. Әби: «Әниең сине Курсабашка беренче тапкыр кырык көнлек чагыңда ук алып кайтты», – дип сөйли иде. Аларның төпчек кызлары Гөлсәрия миннән 7 айга гына зуррак, әни эштә чагында, әби безнең икебезне дә имезгән. Эти солдаттан кайткач, әни мине алып, кабат Себергә китә. Үземне белә башлаганда миңа 5 яшь булгандыр. Яңа гына тәпи басып килә торган сеңлем Асия бар. Ул инде икенче этидән. Минем үз этием вафат. Әнинең ике ире дә бер авылдан – Төмән өлкәсе, Ялутор районы, Исәт авылыннан булалар. Әлбәттә, бер-берсен белгәннәр. Үги эти: «Аның карап торышларына кадәр Гарифулланыкы», – дип, мине каккалый башлады. Боларын яхшы хәтерлим. Биш көнлек балалар бакчасына биргәннәрен дә беләм. Җәй көне анда төшкән бер фото әле дә саклана: егермеләп бала арасында иң кечкенәсе мин... Зурраклар уенчыгымны алсалар, тешли башладым: үземне үзем якламасам, кем мине якласын?! Кыскасы, үги эти янына сыймадым, әни мине Курсабашка кайтарды. Атналап балалар бакчасында яшәгәч, татарча сөйләшергә оныткан идем инде.

Әби белән бабайга «эти», «әни» дип үстем. Шаһинур бабай Бөек Ватан сугышы ветераны, 2 нче группа инвалид иде. Сугышка киткәнче, ике тапкыр авылда Сабантуй батыры булып калган. Көрәшкә хирыслыгым – аңардандыр. Мәйсүфә әбием исә бик нык нәселдән була. Әтисе туннар теккән: һөнәрле булу ул чакта зур нәрсә булган бит. Унөч баладан өчесе генә исән калалар: әбием һәм ике абыйсы. «Бик иркә идем, мохтаҗлыкның ни икәнен белмәдем. Хәтта 1921 елгы ачлыкны да сизмәдем», – дип сөйли иде әби. Мәдрәсәдә белем алган – Коръәнне гарәп язуында укый иде. Зиһенле. Гел мәкальләр белән генә сөйләшә. Безне: «Урламагыз, юлда акча тапсагыз, алмагыз, тапкан әйбер югала ул, кеше әйберенә тимәгез», – дип өйрәтә иде. 1928 елны ул бабайга кияүгә чыга, тормыш шул вакытта авырлаша. Алты балалары туа, мин – җиденчесе.

Инде эти ягы турында. 6 нчы класста укыганда Шаһинур бабай миңа әйтә: «Әгәр яхшы укысаң, мин сине Себер бабаң янына алып барам», – ди. Мин дә сүземдә тордым, ул да. Киттек икәү Төмәнгә. Исәт – шәһәрдән 75 чакрымда икән.

Барып кердек өйләренә, бабай өйдә юк. Гает бәйрәме көннәре тирәсе иде, ахрысы. Кемдер: «Ул яңа гына җиденче ашка кереп китте», – дип, килеп әйтте. Ярулла бабам авылның мулласы икән. Өйләре ике катлы, өстә җәйге өй, балконы да бар. Исәттә башка мондый йорт юк! Абзарларында ике сыер, ике ат, егермеләп сарык. Әмма мине иң шаккаттырганы стенадагы күкеле сәгать һәм ике көпшәле мылтык булды. Боларын кинода гына күргән бар бит! Бабай аучы да, балыкчы да икән. Аңа ул чакта 68 яшь. Көрәк сакаллы матур кеше. Без аларда ике кич кундык. Җарулла карт – авылда аңа шулай дип эндәшәләр иде – мине ошатты. «Равил калсын, бөтен малым аңа булыр», – диде. «Кечкенә чагында ул бит беркемгә дә кирәк булмады», – диде Шаһинур бабай шунда. Мин дә: «Юк, калмыйм», – дидем. Мулла бабай өченче – яшь хатын белән яши иде. Беренче хатынның улыннан туган оныкны ул апа да яратып тормаган булыр иде.

Ярулла бабамны икенче һәм соңгы тапкыр 3 нче курсны тәмамлаган елны күрдем. Миңа инде 18 яшь. Грек-рим стиле белән көрәшәм. Мәгаз Сәхабетдинов һәм Әдип Нуруллин кебек тренерларда шөгыльләнәм. Яңа гына Воронеждан 1 нче урын алып, «спорт мастерлыгына кандидат» исемен алып кайткан чагым. Әниләргә кунакка барган җирдән, Исәткә сугылырга уйладым. Бабай исән! Үзенең күленә алып китте. Ул гына балык тота торган аерым күл иде ул. Шул вакытта бик күп сөйләштек без аның белән. «Без монда сөргенгә сөрелеп килгәнме?» – дип сорадым. «Юк, без Күчем хан вакытыннан ук монда гомер итәбез, нәселебез затлы безнең», – дип җавап бирде. Ул миңа тагын: «Кал», – диде. Бу юлы да: «Юк, кала алмый, укыйм», – дип баш тарттым.

Әнинең тормышы җиңел булмады. 1966 елда икенче ире дә үлеп китте. Асияне ул ялгызы аякка бастырды. Сеңлем медучилище тәмамлады, кияүгә чыкты, өч кыз тапты. Аннан Төмән медицина институтында белем алды. Ире Нурмөхәммәт кияү аңа бик булышты. Без аның гаиләсе белән бик дуслар. Быел август аенда Асиягә 60 яшь тула, Төмәнгә юбилейга барырга җыенам. Соңрак, үзем аякка баскач: «Кайт», – дип әнине гел чакырдым, үзеңә аерым бүлмә булыр, дидем. Кайтмады. Асиянең балаларын үстереште. Кабере дә шунда калды аның. Ел саен барып йөрим, корбан чалдырам. Әнигә бернинди үпкәм юк минем... Әби белән бабайга бик рәхмәтлемен. Аларны да онытмыйм, каберләренә чардуган кордым.



**БАЛАЧАК** Кыш көне тауда чана шуабыз. Чана белән бер малайга бәрелдем шунда. Махсус түгел инде, ялгыш. Аның борыны канады. Әбисе чыкты да: «Син – шундый, син – мондый, син җилдән туган», – дип, мине бик нык ачуланды. Миңа 10 яшь, нәрсәдер аңлыйм бит инде – елап өйгә кайттым. «Әби, нигә ул миңа шулай дип әйтә?» – дим. «Ялгыша, әниеңнәр язылышкан иде», – дип, әби туу турындагы таныклыгымны табып чыгарды. Анда рус телендә «Хайруллин Равиль Гарифуллович» дип язылган иде. Фамилиямнең Хәйруллин икәнен шул көнне белдем. Таныклыкны икенче көнне укытучыларга алып төшеп күрсәттем. Бабайлар Хәйретдинов булгач, мине дә класс журналына шулай язып куйганнар. Төзәттеләр.

Балачактан тагын бер хатирә. 6 нчы классны тәмамлагач, тәмәке тарта башладым. Зур бит инде! Ул вакытта арба белән печән ташу бар иде. Надир исемле малай белән икәү йөрибез. Ул 2 нче класстан бирле

PRESSA.RU



тарта. Кайтканда, туктап, олылар кебек «перекур» ясыйбыз. Берәр ай дәвам итте бу хәл. Әби сизгән. «Тартасыңмы, малай?» – ди. Кызарганмындыр инде. Кыйнамады, сукмады, бер генә сүз әйтте әби шул чакта. «Нәселебездә тартучы юк иде, син беренче тәмәкече булырсың инде», – диде. «Тәмәкече – миннән кече, үлгән тәкә печүче», дию бар безнең якта. Бик хурлыклы сүз! Авызыма башка тәмәке алмадым.



**УКУ** Гөлсәрия укырга кергәндә Нурия апа 5 нче сыйныфта укый иде. Дәресне сеңлесенә гел ул әзерләтә иде. Мин дә шунда гына утырам бит – апаның һәр әйткәнен отып барам. Бәлки шуңа да мәктәпкә кергәч, миңа уку бик җиңел бирелгәндер. Математикадан контроль эшләр вакытында үземнекен генә түгел, күршемнең вариантын да чишәргә өлгерә идем. Бабай ата-аналар җыелышыннан кайта да: «Башлы дип мактыйлар, инженер булыр», – дия иде. Тик бик шук идем – терекөмеш кебек. Мәктәпкә иртәнге җидедә үк төшәм. Тизрәк кем килер икән дип көтәм – миңа уйнарга кирәк. Дәрес башланганчы берәрсе зарланмаса, беренче дәресне әле утырып укыйм. Беренче тәнәфестән соң «алай итте, болай итте», дип зарланучы табыла инде, шуннан соң мине почмакка бастыралар. Башлангыч класста укыганда ук Сабантуйларда көрәшкә керә башладым. Яшьтәшләремне дә, өлкәнрәкләрне дә җиңә идем.

1969 елны мәктәпне тәмамладым. Миңа 15 яшь. Гап-гади авыл малае. Хоккей, футбол уйныйм, чаңгы шуам. Алга таба нишлим, кая укырга барам – киләчәк турында берни уйламыйм. Беркөнне мине мәктәп директорына чакырдылар. Харис исемле классташымны колхоз стипендиат итеп Чистай авыл хуҗалыгы техникумына җибәрә икән. Моңа иптәш кирәк, имтихан да бирәсе бар. Равил барса инде, дигәннәр. Өйгә кайтып сорадым, нишлим, дип. Әби: «Үзеңә кара», – диде. Бабай бу вакыт вафат иде инде. Чистайга безне Харисның әтисе илтеп куйды. Алар авылда хәлле кешеләр дип саналалар. Әтисе тимер юлда мотовозда эшли. 250 сум ала дип сөйлиләр иде аның турында. Гади колхозчы 60 сум алган вакыт бу... Укырга икебез дә кердек. Укыйбыз. Дәресләрдән соң, көн дә көрәш секциясенә китәм. Тренер Мәгаз Сәхабетдинов кулына барып эләктем. Бездән спорт мастерларын ул ясады: Данил Галиев, Әсгать Гайфуллин, Равил Яхин, Равил Минапов, Александр Кузнецов, Анатолий Бозиннар белән бергә укыдым, бергә көрәштем.

Укыганда миңа Гөлсәйрә белән Нурия апа бик булышты. Ул чакта ай саен алар биргән ун сум акчаны бүгенге ничә мең белән чагыштырырга икән?



**УҢЫШ** Казан дәүләт ветеринария институтына укырга армиядән кайткач кердем. Бу вакытта техникумдагы тренерым Мәгаз Сәхабетдинов анда грек-рим көрәше буенча баш тренер булып эшли иде. Ул безне көрәшергә генә түгел, яшәргә дә өйрәтте... Шул елны Россия җыелма командасына эләктем. Ике тапкыр Татарстан чемпионы, Бөтенсоюз турнирлары, югары уку йортлары арасында үткәрелгән ярышлар призерлары булдым. Ә 1976 елны «Урожай» спорт җәмгыяте СССР буенча авыл көрәшчеләре арасында үткәргән ярышта Олимпия чемпионы Жаксылык Ушкемперовка (Казакъстан) оттырып, 2 нче урында калдым. Шул елны «СССРның спорт мастеры» исемен алдым. 2 нче курста чакта зачет кенәгәсендә «дүртле»м бар иде әле, аннары инде гел «бишле»гә генә укыдым. Диплом алгач, Арча районының «Заветы Ильича» колхозына зоотехник булып эшкә кайттым. Биш ел эшләдем анда. Бик яратып эшләдем! Дүрт ел эчендә өч рәис алышынды. Соңгысы килеп, бер ай узгач, безнең колхозда терлекчелек буенча район семинары узды. Күрсәткечләребез мактанырлык иде чөнки. Эшне йә эшлә, йә эшләмә. Улларыма да шулай дим. Тотынгансың икән, кеше синнән көткәннән дә яхшырак эшлә...

«Азин» колхозына рәис итеп җибәрделәр. Арча белән Әтнә бер район иде әле ул чакта. Районда 56 колхоз бар, минеке 54 нче урында... Фәйзи ага Галиев җитәкләгән хуҗалык белән күрше колхоз иде ул. Аннан эштә күп нәрсәгә өйрәндем мин. Биш ел дигәндә 2 нче урынга күтәрелдек. Кешеләр миңа ышана иде... Арча районы буенча көнлек хезмәт хакы 4 сум 45 тиен иде, ә без 9 сум 12 тиен түләдек. Мин килгәндә колхозның 543 мең бурычы бар иде. Сөт сатуны, ит җитештерүне ике тапкырга арттырдык. Иген, бәрәңге – һәммәсе сортлы иде бездә. Әйтик, бәрәңгенең килограммы 1 сум булса, чәчүлек итеп сатканда ул 3-4 сумга кадәр җитә. Бәрәңге чүпләгән өчен иң күп акча ул елларда бездә түләнде. Халык, ял алып, бәрәңге чүпләргә шәһәрләрдән кайта башлады. Уноченче хезмәт хакы керттем – районда беркем бирми иде әле. Мин киткәндә, колхоз кассасында 800 меңнән артык акча калды. 1992 елны беренче тапкыр «Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» исемен тапшырдылар. Бүләкләнүчеләр арасында мин дә бар идем.



**ДУСЛАР** Төн уртасында шалтыратып ярдәм сорый алырлык дустым? Әйе, бар андый кешем. Без Халит Галиев белән Чистай техникумында бергә укыдык, бергә көрәшеп тә йөрдек. Мин аңа теләсә кайсы вакытта, теләсә нинди үтенеч белән шалтырата алам. Халит та миңа шулай. Ул хәзер Яшел Үзәндә яши, гаиләләребез белән кунакка йөрешәбез. Тагын берничә якын кешемнең исемен атый алам. Күңел якынлыгы дигән нәрсә бар ул... Гомер иткәндә дуслар кирәк, үзең генә булмый. Берәүдән сорыйм шулай: «Сиңа ярдәм итүчеләр булдымы тормышта?» – дим. Андый кешеләр барын белә торып сорыйм. «Юк, мин үземне үзем тартып чыгардым, үзем күтәрелдем», – ди. Мюнхаузен күз алдына килде.



**МӘХӘББӘТ** Армиядән кайткач, Чистайга техникумга килгән вакыт. Тренировка вакытында аягымны имгәттем. Култык таяклары белән авылга кайтырга исә оялдыра. «Әйдә,

безгә кайтабыз», – диде күрше Ташкич авылы егете. Аның белән дә без Чистайда бергә укыдык. Бергә көрәшеп тә йөрдек. Кайттык алар авылына. Яшь чак бит, аяк авыртса да, өйдә утырасы килми – кич чыктык. Фадияне шунда беренче тапкыр күрдем... Бер күрүгә ошаттым! Таныштык, сөйләштек. Култык таяклары белән артык ерак китеп булмый, әмма клуб мөдире булып эшләүче бу кыз белән көн саен очрашу җаен барыбер таптым. Бер атна тордым мин Ташкичүдә. Соңгы көнне Фадиягә: «Егетләрең булса, аларны оныт, – дидем. – Мин сине җимешле чәй генә эчертеп яшәтермен. Безнең каберләребез дә янәшә булыр». Нинди хыялый кеше икән бу, дип уйладым синең хакта, диде ул миңа соңыннан. Аяк азрак рәтләнгәч, алты чакрымдагы күрше авылга велосипед белән киттем. Көтүләр кайткан, эңгер-меңгер вакыт. Фадия инде клубка чыккан. Элек клуб янында «Наза» уйныйлар иде. Авыл егетләренең берсе, мин килгәнне күреп, аңа юри кул сала башлады. Юк, сукмадым, әмма алымнарның берсен күрсәттем инде үзенә – җирдә тәгәрәп калды. Усал идем шул...

Бер елдан соң өйләнештек. Мин әле 1 нче курсны гына тәмамлаган идем. Кавышканда икебезгә кырык яшь иде, дип гел әйтәм, аңа – 19, миңа – 21. Ике елдан олы улыбызны алып кайттык. Мин әле озак кына тулай торакта яшәдем. Ә ул, бала тугач, әниләрендә торды. Гомер сизелми дә узды. 17 июльдә кавышканыбызга 42 ел менә. Кичә генә кебек тоела... Иң мөһиме: тигезлек, сәламәтлек хәзер безнең өчен.

Фадия минем өчен нинди хатын булдымы? Бу сорауга җавап биргәнче, бер танышымнан ишеткәнне сөйлим әле. «Мин гомер буе район үзәгендә эшләдем, авылда тордым, Равил, – дип сөйләде ул. – Хатын белән икебез бер оешмада эшлибез, кем әйтмешли, көн – бергә, төн – бергә. Начар да яшәмибез. Гөнаһ шомлыгы, бер шәфкать туташына күзем төште бит. Бер өч тапкыр моның янына бардым. Бензовозда эшләүче бер классташым алып барып кайта. Аерылу, гаиләне бозу турында сүз дә юк, мажара эзләп йөрүем генә бугай. Беркөнне тагын барырга җыенам шулай. Машина тавышын көтеп йөрим. Хатын шунда: «Син ул фәлән белән чыгып китмә әле», – дип, миңа бензовоз шоферының исемен атый. «Без бер җиргә барып килергә генә сөйләшкән идек», – дим. «Юк, син йөрмә әле. Җүнле кеше түгел ул. Миңа барысын да сөйләп бирде инде», – ди хатыным. Җир ярылса, кереп китә идем... Шулкадәр оят булды. Теге хатын белән йөрмә, дими бит, дустыңа ышанма, ди». Моның безнең гаиләгә бер катышы юк, минем Фадиям дә шундый зирәк хатын, дип кенә әйтәсем килгән иде. Зирәк һәм акыллы!



**БАЛАЛАР** Ике ул үстердек. Биш оныгыбыз бар: өч малай, ике кыз. Оныкларның берсе быел паспорт алды инде. Олы улым Фаил Чирмешән районында прокурор булып эшли. Аңа яңа гына 40 яшь тулды, пенсиягә чыкты. Салават та университетның юрфагын тәмамлады. Мин аларның тормышына, эшенә кысылмыйм дип әйтә алам. Олысы прокурор булгач, кайчак кемнәрдер ярдәм сорап миңа да чыккалыйлар. «Ул үз эшен миннән яхшырак беләм», – дим. Әйе, яхшырак белә... Уңышларга ирешү исә аның бары үзеннән тора. Мине бит менә берсе дә артымнан этеп йөрмәде... Малайлар көрәш белән әллә ни мавыкмады: бу буында көрәшчеләр ял итә, күрәсең. Дөрес, Фаиле үзе өчен генә көрәшкәләде. Ә Салават армрестлинг белән шөгыльләнде, Татарстан буенча икенче урынны алды. Улларыма иң беренче чиратта дус булдым дия алмыйм, мин – күбрәк әти. Аларны спартаннарча тәрбияләдем. Әйтик, кичке унда алар инде йокларга ятарга тиешләр иде. Хәтта җәй көне дә. Балаларга кырысрак булырга кирәк дип саныйм... Юк, сукканым, кakkаным булмады. Күз карашымнан да аңлыйлар иде. Фадия да аларга: «Атагыз!» – дип кенә торды: атагыз кайтканчы эшләп куярга кирәк, атагыз ял итә...



**КУРКУ** Мин тормышта нидәндер куркып яшәмәдем анысы... Шаһинур бабам Сталинград өчен барган сугышларда катнашкан, контузия алган. Гомеренең соңгы көннәрендә фронт хатирәләре турында шактый сөйләп калдырды ул миңа. Аңарчы нигәдер уртаклашканы булмады. Аларның Мамай курганында күргәннәре... Сугыштан да зур хәсрәт юк дөньяда. Илдә тынычлык булсын иде. Ил белән һәрвакыт зирәк җитәкчеләр идарә итсен иде.



**АКЧА** Көннәрдән бер көнне миңа тау кадәр акча ишелеп төшсә, аны кая куяр идемме? Андый акчалар беркайдан ишелеп төшмәсен беләм, шуңа күрә бернинди планым да юк. Бу мәсьәләдә мин прагматик – зур акчалар турында хыялланмыйм да. Беренчедән, акча юктан бар булмый ул. Икенчедән, хәтта ишелеп төшкән очракта да кагылмас идем: күп акча кемгә килешә, кемгә юк... Булганына шөкер итеп яшим. Пенсия алып торабыз, әле эшләп тә йөрим: Аллага шөкер, җитә. Байлыкка, бик күп акчаларга ия булуны мин бәхеткә санамыйм. Гомумән, кешене акча гына бәхетле итми. Акчага нык табынганнар, башкаларга караганда, бәхетсезрәк тә була әле.



**ҮЗЕМ ТУРЫНДА** Чагыштырмача сабыр кеше мин. Әмма кайбер очракларда давылга, зилзиләгә дә әйләнеп куя алам... Үземне кимсетсәләр, беркайчан да җавапсыз калмадым: андыйларга дәшмәсәң, аякларын сиңа сөртәләр дә китәләр, санлашмыйлар бит. Намусым чиста, монысы – иң мөһиме. Ә якыннарым өчен мин – бердәнбер. Кулымнан килгәннең барысын да эшләргә тырыштым һәм тырышам алар өчен: ярдәмчел диярләр. Ә башкалар минем турында ни уйлаганнарын үзләре әйтсен...

Гөлнур САФИУЛЛИНА

PRESSA.RU



# ТИК СИН ДИЕП...

**Кемдер, бәлки, биек сәхнәләрдә, «Татарстан–Яңа гасыр» экраннарында яшь һәм чибәр җырчы кызлар муллыгын күреп хозурлана булыр. Тик бит алар берсе дә Зәйнәп түгел. Ул «яңаларның» иң моңлы дигәннәре дә Зәйнәп ФӘРХЕТДИНОВАга охшатып җырларга тырышучылар гына. Үзе чибәр, үзе зифа, үзе моңлы җырчы ул берәү генә – Зәйнәп кенә! Ык буенда гына үсә андый кызлар!**



Асия ЮНЫСОВА

Әнисе Мәрҗәнәгә дә ул бердәнбер кыз. Ык буенда үсәр кызын ул җылы якка бәхет эзләп, дөресрәге, мәхәббәте эзеннән баргач, Ташкент каласында тапкан. Ярый әле шунда торып калмаганнар. Әлеге дә баягы шул мәхәббәткә ияреп, янәдән Сарлы авылына кайтып төпләнгәннәр. Менә шулай итеп, рус мәктәбендә укып, үзбәк арасында үсәсе кыз Ык буе талларына сарылып, зифа булып, моңлы булып үзебезнең туфракта буй җиткергән. Җырчы булып киткән. Моңлы сукмактан башланган юлы аны Халык йөрәге дигән мөнбәргә менгергән. 25 ел дәвамында ул шул биеклектән төшми.

Минем бу чибәркәй белән тәүге танышуым да ул сәхнәдә чагында булды. Мәртәбәле сәхнә түренә иң беренче тапкыр гына чыгуы иде бугай әле аның. «Татар җыры-91». Бер-бер артлы сәхнәгә җырчылар чыга тора. Жюри тыныч. Чөнки хисләнергә сәбәп юк. Озынга сузылган тамаша ялыктыра да төште. Залда да битараф шыбырдашу. Кем күршесе белән сөйләшә, кем конфет кәгазен сүтә. Мин дә фойедан алып кергән реклама газеталарын караштырам. Менә сәхнәгә бер кыз чыгып басты. Кулымдагы газета шуып төшеп китте, янәшәмдәге тамашачы конфетын кабарга онытты, жюри әгъзаларының каләмнәре һавада эленеп калды. Фотографлар гына кинәт тынгысызлана башлады. Бу әле матурлык, сылулык кодрәте генә иде. Төрек фильмнары аша таныш чибәр актриса түгелме соң бу?

Без шулай бит инде – затлы нәрсәнең иясен читтән эзли башлыйбыз. Юк. Бу Түркән Шорай түгел, бәлки төрки дөньяның сәнгать күгендә үз йолдызын кабызырга тиешле япь-яшь кыз Зәйнәп Фәрхетдинова иде. Чибәрлек, буй-сын, талант, белем – бөтенесе бергә килгәндә уңыш казану мөмкин еллар иде әле бу. Халык мәхәббәте бу җырчыны шунда ук кайнар колачына төреп алды. Дәрәҗәле исемнәр белән беркетелгән казанышлар кадәресенә кызның исе китмәде дә бугай. Хатын-кызның, хәтта бик талантлысы да, янында яры, итәгендә балалары, күңел юатырлык шөгыле булганда үзен бәхетле, көчле итеп тоя. Арганын да, талганын да белмичә, янып-көеп эшли дә эшли.

Халкына кадерле икәнен белеп алгач, бу сылу кыз да шул фидакарьләр юлыннан китәр инде. Тик ялгыз гына китмәс. Шөкер, янында үзенә тиң асыл яры бар. Һәм бу асыл яр сөйгәне баскан сукмакка яшел чирәм булып түшәлергә әзер тора. Күп кызларның йөрәгенә ут салырга өлгергән, «Сандугачлар капкада» җыры белән гаять популяр булып киткән Зөфәр Билалов Зәйнәп бармагына балдак кигереп өлгергән түгелме соң? Репертуарындагы «Тик син диеп...» дигән җыры да аңа – сөйгән ярына багышлангандыр. Тәгаен шулай!

«Зәйнәп+Зөфәр» җитәкләшеп узган юлларга йөзләрчә җырлар сибелеп калган. Бүген татар эстрада сәнгате күгендә альфа йолдыз булып балкыган Татарстанның халык артисты Зәйнәп Фәрхетдинованың җыр дөньясына «Зәңгәр кыңгыраулар» җыры белән кереп киткән идем.

Хәйләсез, кыланусыз, садә башкару алымы, нәфис, әмма көчле һәм тыгыз агымлы тавыш тембры, моңлы



*Бу икәүнең «Зөфәр+Зәйнәп» ансамбле булып, илебез төбәкләре буйлап киткәненә дә чирек гасыр узды инде.*

авазлардагы бөдрә бормалар, бай хисле аһәң... Зәйнәп Фәрхетдинованың җыр дөньясын бәяләп бетерү өчен татар теленең сүз мөмкинлекләре дә көчсезләнеп кала бугай. Җыр тыңлаганда сүз нигә соң ул! Тыңлыйк та хисләник кенә, ләззәтләник, яңа аерткан бал кебек татлы моң агымында йөзик.

Гомер иткәндә юл-сукмакларыбыз кисешкәли торган иде. Бервакыт мин «Зөфәр+Зәйнәп» ансамбле артистлары белән юлдаш булдым. Автобус төне буе бәйрәм буласы район үзәгенә кайтты. Утыргыч култыксаларына аркылы ятып барып йокы күрмәделәр инде бәгырькәйләр. Команда дилбегәсе Зәйнәп кулында иде ул төнне. Тәртиптән тайпылырга исәбе булганнарны бик тиз айныта белде ул. Мин назлы Зәйнәпнең каты куллы оештыручы да була белүенә хәйран калган идем ул чагында. Мәскәүнең «Россия» тамаша залы сәхнәсендә дә күрдем мин аны. «Татар җыры» фестивальләренең «Алтын барс»ларын елның-елында (хәзер алар аның – 16) алып китә торганына да күп тапкырлар сөенгәнем бар. Чистай урамындагы бәләкәй фатирларында бәби малае белән келәмдә тәгәрәп уйнап ятканын да хәтерлим. Аны төрле рәвешләрдә күрүчеләр, хәтерләүчеләр бер мин генәмени? Әйтик, Балык Бистәсе районының Олы Елга авылы кешеләре: «Ул безнең килен, аның зифа буен уйнатып, чишмәдән су алып кайтканын да, кара яндырып мунча чабынырга яратканын да беләбез», – диярләр.

Зәйнәп Фәрхетдинова тормыш keләмен әнә шулай ефәк һәм киндер җепләрне бер-берсенә саба-саба тукый, тукыганын исә җырлары белән бизәкләп бара.

PRESSA.RU



Аның дөньясын аңлыйм дисәң, җырларына кер дә чум! Җырлар исә күп, бик күп! «Зөфәр+Зәйнәп» эстрада ансамбле егерме биш ел дәвамында Казандагы имтихан концертларын өр-яңа җырлары язылган диск белән йомгаклап куя.

*Хәзер инде аларның «Аваз» исемле тавыш яздыру студияләре дә бар.*

Йөзәр җырны сыйдыра алырлык егәрле «МР-3»ләр дә бу икәүнең барлык җырларын сыйдырып бетерә алырлык түгел икән ләбаса. Әле моңлы, әле шаян җырлар ташкынын төне буе тыңладым да, яңа адреслары буенча Билаловларның үзләрен эзләп киттем. Җыр дөньясындагы урыннарына бәрабәр икән фатирлары – әллә ике, әллә өч катлы квартираны фатир дип түгел, йорт дип атыйсы килә. Торагың өчен тиешлесен түләп бетерә алсаң, иркенлек әйбәт инде ул. Егет булган Булатка да, үсмер егет Фоатка да, ерак җирне якын итеп килгән гаип кунакка да урын иркен монда. Зәйнәпнең белер-белмәс тәнкыйтьчеләр, тик торганнан бер эш булсын әле дигәндәй, килешмәгән җирен эзләргә ярата торган затлы күлмәкләренә – аерым, Зөфәрнең сәхнә киемнәренә аерым бүлмә. Зәйнәпнең буй-сынын тәртиптә тотарга, малайларның көч-дәрманын сынарга тиешле спорт тренажерлары өчен дә урын табылган. (Хәер, Зәйнәпнең энергетикасы тренажер торган бүлмәгә генә сыеп бетмичә, ул күнегүләрен парктагы йөгерү юлларына да алып чыккан икән инде. Сулышын, гәүдә сылулыгын юбилей концертлары өчен әзерләп йөрүе.)

Тату ояның символы Билаловларда да кухня икән. Зур өстәлле, мул табынлы, уен-көлкеле кунакчыл кухня, Зөфәр кызыл күрекле баянын бар колачына җәеп җибәргәч, бу кухня җырга уралган хатирәләр мәйданына әйләнде дә куйды. Миңа төне буе тыңлаган җырларымны берәм-берәм шул хатирәләр кулъяулыгына төреп барасы гына калды.

Оныттылар, диеп үпкәләмә, / Карурманнар үскән илләрдә. / Сине сагынып җаннар өзгәләнә / Айлы әкият кебек төннәрдә...

«Авыл» көе бу. Гамил Афзал сүзләренә җырлана торган, үзәкләрне өздереп ала торган җыр. Зәйнәп Фәрхетдинова репертуарында «авыллы» җырлар байтак. (Җырчы «авыллы» ике җырына кабат яңа аранжировка эшләтеп куйган әле. Бу җырлардан бизә белмәгән тамашачыларына бүләк.) Аларның берсе минем авылым, икенчесе Шәмсия Җиһангированыкы, өченчесе Зифа Нагаеваныкы һәм барысы бергә – Зәйнәпнеке. Җырлый-җырлый Сарлыны сагына ул. Аланнарда җиләк җыйганнарын, Ыкта кер чайкаганнарын, көтү каршылаганнарын. Тормышның беренче сынаулары да, тәүге сөйгән ярлар да шунда булган. «Ыкта су коенганда суга баттым бит мин. Чәчемнән тартып чыгардылар»,– дип искә ала Зәйнәп. Мин тетрәнеп китәм. Әгәр чыгара алмаган булсалар...

Юк, юк, ул хатирәне онытыйк та икенчесен тыңлыйк. «Минем әнием бик матур кеше иде. Аның исеме дә матур иде – Мәрҗәнә! Ул матур итеп яшәде. Минем әни бит ул! Әни безне, иртәнге матурлыкны күреп, сандугач сайравын ишетеп калыгыз, дип уята торган иде. Аннары йокласак та ярый. Их, әни кебек һәрбер мизгелнең матурлыгын тоеп яшәргә иде ул! Әни киявен дә бик кадерләде. Егерме җәйне әни янында үткәрдек. Әни иртәнге дүрттә Зөфәрне уятып, аңа көн дә яңа сауган сөт эчерә торган иде. Ә мин көнләшәм. Каймак ясасаң да, коймак пешерсәң дә әни кебек җиренә җиткереп эшләргә кирәк ул. Әни тәрбиясен безнең ансамбль артистлары да татыды. Ерак сәфәргә китешли дә, сәфәрдән кайтышлый да, кошлар кебек, безнең авылда ял итеп китә идек».

Әнә шулай итеп авыл үзеннән-үзе әнигә ялганды. Зәйнәп күз яшьләренә коенган арада, сөйгәнен ничек юатырга белмәгәннән чарасыз Зөфәр элек булган хәлләрне сөйләп алды: «Әби 2009 елда вафат булды. Зәйнәп шуннан соң озак тынычлана алмады. Без Төркиядә ялда идек. Мин Зәйнәпне комлыкта калдырып балалар белән суга кереп киткән идем. Зәйнәп янына әйләнеп килсәк, аңа әллә ни булган. «Зөфәр, әни үлә, мин әле генә аның тавышын ишеттем. Әнә теге куаклар арасында бер сәер кош күренде, канатларын кагынып миңа ишарәләр ясады. Мин якын баруга югалды». Моңа кадәр дә, моннан соң да кош мазар кагынганы булмады. Сәерсендек. Кошы да гаҗәеп бер кош булган икән. Берничә минуттан телефон шалтырады: «Мәрҗәнә апа вафат», – диделәр. Кызын эзләп табып, бәхилләшүе булган икән изге җанның».

Инде аларның икесенә бер әни – Фатыйма апа калган. «Хатын сүзен санлый белә торган малайлар үстергән кайнанама рәхмәтем бик зур минем», – ди Зәйнәп. Алсу йөзле, озын толымлы, моңлы тавышлы киленен – улын яраткан кызны Фатыйма апа да яраткандыр. Хәер, егетлеген гамәл белән дәлилли белә торган егетләрне кызлар ярата инде ул. «Чәчәк бәйләмнәренә дә, арттан калмый йөрүенә дә исем китмәгән иде. Ишек ачмаганыма күрә, бүлмәмнең пыяла ишеген алып кергәч, җен ачуларым да чыккан иде әле. Әмма бер көнне өченче каттагы тәрәзәмә су торбасы буйлап үрмәләп менгәннән соң эредем, яратуына ышандым, мәхәббәтен кабул иттем».

Бу йорттан мәхәббәт әле дә китмәгән. Концерт программаларының берсен «Ярату хакына, ярату хакында» дип атаганнар икән, шагыйрь әйтмешли, юкка түгел, юкка түгелдер. Әнә, яратуның матди дәлиле булып, әтисен инде буйга узып киткән, гитара җене кагылган Булат кереп-чыгып йөри. «Монда сезнең күңелле икән» дигәндәй, бер елмаеп ала да, тагын югала. Ул сәхнәдә дә әнисенә таяныч. Җае белән генә үзе дә җыр белән катнаша. Сәхнә техникасы чыгымчылап куйганда да хәзер рәтләп куя. Мондый ярдәм дә, ярдәмчеләр дә бик кирәк вакыт. Зәйнәп Фәрхетдинова матур юбилеенда халыкны моңарчы күрелмәгән шоу-тамаша белән сөендерергә хыяллана. Тыйнак кына «Бер көн» дип аталган ул бәйрәм тамашасында халык елар да, көләр дә дип фараз ителә. 30 сентябрьдә Боз сараенда үтәчәк ул тамашага

әзерлек эшләре кайный инде. «Мин сине сөйгәнмен күптәннән» дигән җыр премьерасы тамашаның эчтәлеген билгеләр дип уйланыла. Зөфәрнең уйлары салынды микән әллә бу җыр тукымасына? Хәер, күптәннән үзе дә җырлар язып йөрсә дә, бу юлы Зөфәр концертка котлаучы сыйфатында гына килергә җыена бугай. Әллә?

– Юк, юк! Зөфәрнең мөһим эшләре бар. Алай да дуэт белән җырларга ниятләп торабыз. Юбилей концертыннан соң Башкортстан, Мәскәү тарафларына бергәләшеп җырлы юлга чыгарбыз. Җыр ул гомерле, җырлы юл озын да, кыска да ул!

«Җыр ул гомерле», – дип, Зәйнәп минем уемдагын әйтеп салды. Мин нәкъ менә: «Җыр ул җырчы килеп киткән урында яшәп кала. Хәтта җырчылар бу урынга кабат әйләнеп килгәч тә халык алар авызыннан теге юлы отып калган җырны, җырны гына түгел, Зәйнәп концерт вакытында сөйләгән шигырьләрне дә кабат-кабат ишетергә тели», – диясем килгән иде. Ә Зәйнәп бер җырны еллар буе җырлап йөрергә яратмый. Алай да репертуардан төшми торган җырлар бар. «Озату», «Гаепләмә», «Авылым хатирәсе» шундыйлардан. Аларны халык һаман сорап йөдәтә. Ә Зәйнәп Фәрхетдинованың яңадан-яңа җырлар җырлыйсы килеп кенә тора. Күрәсең, аның әле яшьлек ашкынуы узмаган. Алла Пугачева да бит яшьлегендә кулына эләккән һәр шигырьне җырга сала торган иде. Заман килде – урыс эстрадасының анасы Яңа ел концерты өчен генә күчтәнәчкә елына бер җыр әзерли башлады. Хәер, хәзерге техника мөмкинлекләре җырчының борынгы җыр тәлинкәсе кебек һаман бер түгәрәктә әйләнүен кирәксенми дә. «Хәзерге техниканың уңайлылыгы! – ди Зәйнәп. – Җырлаган саен җырлыйсы гына килеп тора. Тавышка көч китерми торган, ардырмый торган техника! Эх, шул мөмкинлекләр белән халыкара конкурсларга, әйтик шул ук «Евровидение»гә барсаң иде ул. Без бит сәхнәгә конкурслар аша килгән җырчылар. Ярыш дәрте безнең канда! Тагын бер хыялым – уен кораллары ансамбле булдырып, шуның белән концертлар куеп йөрсәң иде ул!»

Зәйнәбенә җыр җиткерә алмаган Зөфәр инде үзе иҗатка тотынган – җырның сүзләрен дә, көйләрен дә яза. Һәм алар начар җырлар да түгел. Тормыш гимны кебек яңгырый торган «Теләк» җырын халык бик яратты. Зәйнәп үзе дә җырлар яза. Концертларының сценарийларын үзе яза, күп вакыт режиссеры да үзе. Хәзер аның яңа бер хоббие табылган – ул рәсемнәр ясый. Кеше дигәнең һәрвакыт яңару, яңага юл яру әмәлен эзли.

Зәйнәпнең җыр иләге элеккечә талымчан. Ул берәр җырны җырларга алына икән, аның хитка әйләнәчәге көн кебек. Мин үзем, сүзен яки көен ошатмасам да, җырчыларның тавыш тембрына, сулыш киңлегенә соклану, татлы авазлардан ләззәтләнү өчен генә булса да, тыңлыйм аларны. Эх, ишеттерәсе иде, яңгыратасы иде бу тавышны бөтен дөньяда, һичьюгы төрки дөньяда! Роза Багланова, Зәйнәп Ханларова, Далида кебек популяр булыр иде безнең Зәйнәп тә. Зөфәрнең киң диапазонлы, бай төсмерле тавышы да Тарканныкыннан ким түгел. Ил бусагаларын атлап чыгарга ни комачаулый соң? Мөгаен, оста, тәҗрибәле, үткен менеджерлар табылмаудадыр хикмәт. Югыйсә Зәйнәп Фәрхетдинова Төркиядә узган төрки халыклар җыр фестиваленең Гран-приен аздан гына алмый калган иде.



*Яңаруга омтылган җаннар яңарып торсын.*

Себер, Башкортстан, Мәскәү тамашачысы да җитә кебек үзе. Ләкин бит Үзбәкстандагы, Кыргызстандагы, Таҗикстандагы милләттәшләр дә җыр көтә. Мөгаен, ул республикаларның төп халкына да татар җыры ят булмас иде. Нигәдер, без халкыбызны таныту җәһәтеннән ялгыш юлдан киттек. Нефть белән, спорт белән... Ә бит элгәре татар кешесен акылы, гыйлеме, тапкырлыгы, сәләте өчен хөрмәт иткәннәр. Шагыйрьләрен белгәннәр. Төркия мәмләкәтендә бүген дә үзләренә Конституция язып биргән кешенең ватандашлары итеп кабул итәләр татарларны. Зәйнәп концертларына Төркия шәһәрләрендә дә, Баку белән Алматыда да, Бишкәктә дә, Ашхабад белән Дүшәмбедә дә халык агылыр иде. «Ай-вай, татар кызы» дип, Зәйнәпкә соклану аша татарның һаман иярдә икәнен белерләр иде.

Дуэтлар җәһәтеннән дә шулай. Әйбәт кенә дуэтлар бар хәзер. Ләкин ике тавышның да Зөфәр белән Зәйнәпнеке кебек бертигез матур һәм егәрлесе сирәк. Чөнки бу икәү чын хисләрен җырга салалар, аларның бер-берсенә битараф түгеллеге һәр авазны, һәр сүзне әйтү рәвешеннән үк сизелә. «Ак майларда ак вәгъдәләр бирешкән идек, җаным», – дип өзелгәндә тамашачы бу икәүнең еллар үткәч тә бер-берсенә суынмауларына сөенеп, алар кичергән хисләргә үзенекен ялгап утыра.

Менә шулай инде, җырчы белән җыр турында сөйләшү, барыбер, мәхәббәт хакында сөйләшүгә әйләнә.

PRESSA.RU



Оксана ИЛЬЮП

# ЯРАТАМ ШУЛ...

«Хәерле көн, якыннарым!» Интернет халкы танып алгандыр инде: бу, әлбәттә, Оксана Ильюп! Һәр көн иртән ул шулай сәламли. Чиләбедә яшәүче талантлы бу яшь ханым тумышы белән Башкортстанның Салават районындагы матур табигатьле Лаклы авылыннан. Әнисе Оксана дип исем кушкан, ә мулла азан әйтеп биргән аты – Аксәнә. Мәктәп елларында шигырь язучы бу кызны Аксәнә Гыйләҗева буларак күпләр хәтерли. Бик популяр автор-башкаручы. Мәшгульлек һәм социаль мөнәсәбәтләр академиясен тәмамлаган, белеме буенча икътисадчы. Ире гитарада уйнарга өйрәткән. 2012 елда «Шалтырат инде» дигән беренче җыры чыга, «Чәчәкләр гаепләме?» дигән клибы төшерелә, 2013 елда беренче альбомы дөнья күрә. Ютубтагы җырларын караучылар саны шаккаттыра. Кайбер видеоларын 300 меңнән артык кеше караган. Сәяхәтләр ярата, мотоциклда, автомобильдә җилдертә, кулдан татарча открыткалар ясый, буш вакытларында скрапбукинг белән шөгыльләнә. «Елмай һәм дөнья да сиңа елмаер!» – монысы аның тормыш шигаре. Елмаеп, үз дөньясына, иҗатына алып керәп китә дә шигырьләре, җырлары, фотосурәтләре белән тәмам сихерли Оксана.

## *Яздан такыялар үрәм*

Ә мин яздан такыялар үрәм.
Мин яз белән бизим күңелне.
Кара әле, әнә аяз күктән
Мамык карлар ява түгелме?

Алмагачлар акка төренгән чак:
Ап-ак таҗлар җиргә коела.
Бу хуш искә изрәп күңелем дә
Чәчкә ата кебек тоела.

Шундый таныш миңа язның моңы.
Мин үзем дә назлы яз гөле!
Кара әле, мин дә оча беләм
Күктән яуган таҗлар шикелле.

Язны сулыйм башым әйләнгәнче.
Язны эчәм, танып тәмендә
Һәр нотасын. Һушым китеп чумам
Искитәрлек дөнья ямена.

Бар галәмгә үлеп гашыйк булып
Яратамын һәрбер мизгелне!
Мин бу яздан такыялар үрәм.
Мин яз белән бизим күңелне!

## *Йә атлыйм, йә очам*

Җиденче күкләргә җитәрлек
Халәтем. Йә атлыйм, йә очам.
Сүз генә әйтмәгез, карагыз –
Ак каурый болытлар мин кочам.

Сүз генә әйтмәгез, мин аңлыйм
Нәрсәдә булганын ялгышым.
Бер атлап, бер очып, белмәссең,
Кай якка бу китеп барышым.

Мин синең алдыңда, әйтерсең,
Яшь яфрак җилләрдә тибрәлгән.
Син якын. Җилеңнән тоямын –
Янымда җәяүли күләгән.

Тының да шифалы. Сулышың...
Дулкыны бәлзәмгә әверелә.
Күргәнем бар сине – бик күптән...
Бу тәүге очрашу түгел лә...

Кайчандыр, ниндидер дөньяда
Уяулы-йокылы халәттә,
Күзгә-күз карашып, бер гомер
Йөзгәнбез коенып ләззәттә.

Хатирә төбенә уелган
Күзләрең, карашың ырымлы.
Бер очкын да җитә – онытылып
Яныңа кабаттан барырмын.

Иләсле йөрәгең шашуын
Мин сизеп бер очам, бер атлыйм.
Елмаеп, ишетелер-ишетелмәс:
«Яратам шул...» – диеп кабатлыйм.

Иренем кагыла ир(е)неңә –
Күңелең ишеген мин ачам.
Җиденче күкләргә җитәрлек
Бу шашу, миндәге исәрлек!..

## *Яңгырның да бардыр җаны...*

Көне буе, төне буе яңгыр.
Төбе төште әллә күкләрнең?
Хисләр белән тулы йөрәгем...
Булыр микән чиге үпкәнең?

Яңгырның да була икән җаны.
Ул да ярсый үлеп сагынудан.
Ул да шаша, ул да белә синсез
Бу дөньяда ялгыз калудан.

Яңгыр ява. Көне-төне яңгыр.
Аннан гына качып булыр ул.
Китмә! Очма! Күкләр синсез яшәр,
Ә мин менә яши алмам шул...

Яңгырның да бардыр җаны…
Җаным…
Шалтыратма. Язма. Бул гына!
Яшә генә җирдә. Китмә генә.
Яшә генә җирдә.
Шул гына…

…Яңгыр ява. Нигә елый икән?
Сөйли микән истә калганын?..
Тыныч кына сине тирги-тирги
Мин күзәтәм яңгыр яуганын…

###Ниндидер икенче

Ниндидер икенче мин бүген
(бигрәк хыялый, и Аллам!):
Ят күзләр көзгедән текәлгән,
Мин хәтта бүтәнчә тын алам.
Дөньяны танымыйм –
Әй, кызык!
Әй, ошый үземә шул халәт!
Мин гашыйк кемгәдер – мин юләр
Һәм үзем үземә канәгать.

Дөньялар үзгәрдеме кинәт?
Әллә бу икенче чынбарлык?
Уйларым да бүтән. Әлләсе
Бу әзрәк дуамал булганлык?
Котыплар алмашканмы шунда?
Кузгалган күчәреме Җирнең?
Таный алмыйм бүген дөньяны –
Ниндидер икенче мин бүген…

* * *

Миңа сине көтәргәме?
Күпме вакыт?
Уйлар синсез дөрес акмый.
Йөрәк – ватык.
Синле булган мизгелләрдә
Калдым торып.
Әйдә, вакыт агылышын
Карыйк борып.
Иң беренче хатың кабат
Язып кара:
«Ике сәгать минем белән
Синең ара…»

### Илһам тулган күңелемә

Илһам тулган булган күңелемә.
Шуны сизми икән йөргәнмен.
Уттай янган тугры йөрәгемнең
Ялкыннары инде сүнгәнме?
Сүнмәгән шул. Әле бүген дә мин
Язгы гөлдәй хуш ис таратам.
Әле бүген дә мин элеккечә
Өзгәләнеп, өзелеп яратам.
Ә күңелем, сусап илһамына,
Гөлләр яңгыр суын көткәндәй,
Синең кайтканыңны һаман көтә,
Саклап назларыңны үткәндә.
Ә күңелем сиңа тугры кала,
Илһам аңа тугры булгандай.
Сагышларым күпкә көчәйгәндәй,
Төнге күктә ак ай тулганда.
Хатирәләремне күмеп булмый –
Алар бәйсез, алар ирекле.
Ә син хәзер булган яклар кайда?
Еракмы юл? Таулар биекме?
Барам дисәм, барып җитәрменме?
Әллә килерсеңме? Үзеңме?
Мин бит әле тере. Җәфалама.
Сал җилләргә тик бер сүзеңне.
Алып килер түкми-чәчми. Минем
Өчен шундый мөһим хәбәрең.
Сагышларым сүрелерлек түгел…
Ә син ничек? Ничек хәлләрең?

Илһам белән тулган күңел. Ә мин
Тыным бирәм язган җырыма:
Кара белән язмыйм, каләмемнең
Очын манып язам ярама.
Сине сагынулар, тере җандай,
Миңа ияләшкән, яраткан.
Югыйсә бит хәтта илһамым да,
Хәтта ул да синең тарафтан…

### Бүлмә

– Бүлмәңдә коточкыч караңгы!
Күрергә, сизәргә син өйрәт.
Кем синең күзләрдән
һаман да ояла?
Кем хайван, кем кеше? Кем өрәк?

– Дөньяда искиткеч яктылык!
Кайлардан, нәрсәдән бу ялкын?
Кем якын буларак хәтсез чит
һәм ерак?
Кем ерак булса да – бик якын?

– Бүлмәңдә үлгән ат исе бар.
Чарасыз, һавасыз – чык аннан!
Бу төксе диварлар уйларны чуалта.
Мин алай күнмәгән.
Мин куркам.

– Сириннәр исе бар дөньяда.
Тупсадан әллә язмы атлый?
Ничек соң бу салкын кышларның
төбеннән
Сириннәр исләреме аңкый?

– Бу бүлмәң бик тыгыз – тын кыса…
Чык моннан!
Күрсәтимме юлын?
Тәрәзләр капланган, яктылык юк.
Әйдә мин сине коткарам!
бир кулың!

– Бу дөньяң искиткеч! Бик телим
Шәрабын татыплар эчәргә.
Әмма бу бүлмәдә мин туган,
мин үскән –
Күнеккән кояшсыз яшәргә.

– Иңеңдә нәрсә ул? Канатлар?!
Димәк, син бит оча аласың!
– Очкан бар. Тик төшеп җирләргә
канатның
ялыймын сыкраган ярасын.

– Яралы канатың төзәлер.
Бу читлек. Кач моннан!!!
Син!! Юләр!

– Гафу ит.
Мин инде күнеккәнмен күптән.
Гафу ит!
Гафу ит һәм…
…җибәр…

### Мең дә бер

Мин сине мең тапкыр очраттым.
Мең тапкыр!
Бер гомер эчендә.
Без мең кат күрешеп, мең кабат
Аерылу афәтен кичергән.

Кемнәрдән көч алдың яшәрлек
Сөюсез, миннәрсез төннәрне?
Кемнәргә шигырьләр багышлап,
Иркәләп назладың кемнәрне?

Ничә мең китаплар укыдың,
Күзләрең сукраеп беткәнче?
Тагын бер күрешеп калыйкчы
Кышыбыз узыплар киткәнче.

Аннары без барган сукмактан
Бер-берен кочаклап кемнәрдер
Үтәрләр. Ә безнең тарихта
Бу уйлап чыгарган
мең дә бер… Кичәбез!

PRESSA.RU



Соңгы вакытта аның исеме еш күренә, еш ишетелә башлады. Журналист, шагыйрә, язучы Венера Мәҗитова – Уфада чыгып килүче «Кызыл таң» газетасының Илеш, Чакмагыш районнары буенча үз хәбәрчесе. «Туйга өч көн кала» хикәяләр җыентыгын укучылар яратып кабул итте. Күптән түгел дөнья күргән «Өй ашлары» китабы белән ул хатын-кызларны аш-су әзерләү серләренә өйрәткән уңган хуҗабикә булып танылды. 2017 елгы «Бәллүр каләм» фестивалендә исә Венера Мәҗитова «Туган тел» номинациясендә җиңүче булды. Сабантуйлар чорында, сыйныфташлар очрашулары гөрләгән бер вакытта, авторның «Җирәнчәч» хикәясе кабат яшьлеккә алып китәр, күңелдәге хатирәләр яңарыр...



Венера МӘҖИТОВА

# ҖИРӘНЧӘЧ

(Хикәя)

Укучыларымны кайтарып җибәреп, аларның иҗади эшләрен тикшереп утыра идем, кесә телефонымның шалтыравын ишетеп, сумкама үрелдем. Экранда таныш түгел номер. Билгесез номерларны, гадәттә, җавапсыз калдырсам да, бу юлы алай итмәдем. Шалтыратучының кем икәнлеген ачыкларга теләп, телефонның яшел төймәсенә бастым:

– Алло, Айсылумы бу? – дип эндәште бер ир заты. Шалтыратучының тавышы таныш та, таныш түгел дә кебек, шуңа сагаеп калдым.

– Әллә начар ишетеләме? – дип дәвам итте ул. «Мине белеп шалтырата инде бу. Кем икән? Тавышы да ягымлы гына тоела», – дигән уй йөгереп үтте баштан.

– Әйе, тыңлыйм, – дип җавап бирдем.

– Айсылу, мин бит бу, Алмаз!.. Сыйныфташың. Таныдыңмы? – дип тезеп китте шалтыратучы.

Бермәл өнсез калдым. Таныдым тавышын, нишләп танымыйм, ди, инде. Унбер ел буена бергә укыган сыйныфташны да танымаска. Телемне чак әйләндереп:

– Әйе, таныдым, – дип җавап бирдем.

– Әллә элемтә начар инде? Син бик начар ишетеләсең? – диде Алмаз.

– Ә мин сине бик әйбәт ишетәм, – дип, теләр-теләмәс кенә җавап бирдем.

– Номерны каян тапты икән бу, дип аптырый күрмә, яме. Өегезгә шалтыратып белештем... Айсылу! Сине сыйныфташлар белән очрашуга чакырып шалтыратуым иде. Бу җәйдә мәктәпне тәмамлауга унбиш ел була бит. Килә аласыңмы? – дип сорады Алмаз.

«Ә» дә, «җә» дә диялмәдем. Шулай да: «Ярар, уйлап карармын. Вакытын алдан хәбәр итәрсең», – дип әйтергә өлгердем бугай.

Телефоннан килгән өзек-өзек сигнал мине гүя айнытып җибәрде. «Тукта, Алмазның тавышын ишетүгә нигә каушап калдым соң әле? Теге чакны хушлашу кичәсендә хәтерне калдырганы өчен юньләп сөйләшергә теләмәдемме? Әллә башка сәбәптән тел көрмәкләндеме?..»

Хәтерне нык кына калдырган иде шул Алмаз ул чакта, ничәмә төн рәттән күз яшьләрен түктергән иде. «Еллар үткән саен, бар да онытылды бит инде, хатирәләрне нигә киредән яңартырга?» – дип, акылым шунда ук икенче яктан йодрык төйнәп алды. Кемгәдер үпкәләп, ачу саклап йөрүдән миңа файдамы да, башкагамы? Яшь чакта, юләр чакта хаталы гамәлләр кылына, җиде кат уйланылмаган сүзләр әйтелә инде ул. Әнә бит хәзер бер дә «Җирәнчәч» дип үчекләми, «Айсылу» дип, ягымлы гына эндәшә. Ул вакыттагы кебек 17 яшь түгел, 32 бит инде безгә! Шулай уйлап, башлаган эшемне дәвам итәргә булдым. Тик соңгы кыңгырау кичәсендә булган күңелсез хәл белән бәйле хатирәләр һич тынгы бирми. Җитмәсә, тәрәзә аша үтеп кергән

май кояшы, «Утырма инде шушында, чык тизрәк урамга!» дигәндәй, тышка чакыра.

Дәфтәрләрнең тикшерелмәгәннәрен пакетыма салдым да тиз-тиз генә киенеп урамга чыктым. Тулай торак белән мәктәп арасы ун минутлык кына юл. Күкрәгемне тутырып язгы май һавасын суладым да салмак кына атлап кайтыр якка кузгалдым.

* * *

Кайбер кешегә Ходай Тәгалә барын да берьюлы өеп бирә: зифа буй-сынын да, чибәрлеген дә, сәләтен дә. Мин генә, нишләптер, андый бәхеттән мәхрүм калганмын. Йөз-кыяфәтем дә, килеш-килбәтем дә ташка үлчимлек кенә. Җәлпәк борын, кысык күзләр, җирән чәч, кыска буй... Көн тудымы, әни белән әти, сүз куешкандай: «И минем матурым, и минем акыллым», – дип, аркадан сөйгән булалар. Сизеп торам, минем күңел булсын өчен генә шулай диләр инде. Хәер, әнәле булса да, керпе дә бит әнә баласын «йомшагым», – дип сөя ди. Үз балалары булгач, әни белән этигә, бәлки, матур булып күренәмдер дә. Көзгә генә нәкъ киресен сөйли шул. Аңа караган саен: «Их, әнекәччәем, карынында яткан чагымда, «матур булсын бу бала», дип никләр теләмәдең?» – дип уфтанам.

Шул ямьсезлегем аркасында туганнан башлап күпме кимсенү кичергәнмендер. Тигәнәк төсле ябышып калган бер түгел, мең кушаматым бар минем. Балачакта, исемем белән дәшкән кеше дә юк, урамга чыккан саен: «Әй, җәлпәк борын, кысык күз, җирәнчәч, кәтүк» дип үчекләп җанга тияләр иде. Ходай Тәгалә шундый итеп яратканга әйтерсең лә мин гаепле. Исемемне дә бит, ичмасам, гадине генә сайламаганнар, «Айсылу» дип кушканнар. Кай җирем ай да, кай җирем сылу инде? Регинадыр, Алинәдер кебек мәгънәсе билгесез берәр исем кушсалар, ни булгандыр.

Матур булмаганга күрәдер инде, югары сыйныфларда укыганда минем белән бер генә егетнең дә дуслашасы килмәде. Йөзгә-биткә сөйкемле сыйныфташ кызларның егетләр белән чыркылдашуыннан йөрәк өзелә иде.

Бүгенгедәй хәтеремдә, соңгы кыңгырау бәйрәменә әзерлек бара иде. Мәктәпне дүрт кыз һәм дүрт егет тәмамлыйбыз. Күңелдә сагыш катыш горурлык хисләре бөтерелә. «Хушлашу вальсы»на әйләнгәндә ничек яхшы булачак. Берегез дә парсыз калмаячак», – диде бер көнне сыйныф җитәкчесе, безгә карап. Шунда арабыздагы иң ачы телле егетләрнең берсе – Айнур – ярым пышылдап, ярым мыскыллап:

– Җирәнчәч белән кем вальс әйләнер икән? – дип әйтеп салмасынмы.

Алия Харисовна бу сүзләрне ишетмәмешкә салышты. Минем исә гарьләнүдән күзләргә яшь бөртекләре бәреп чыкты. Аларны сыпырып алдым да, кычкырып елап җибәрүдән чак тыелып, сыйныфтан чыгып киттем. Тынычлангач, кире кердем. Керә-керешкә, Айнур янә теле белән «чагып» алды:

– Җирәнчәчне Алмаз белән биетәбез, – диде ул хихылдап.

– Мин аның белән вальс әйләнмим. Минем Гөлнур белән биисем килә, – дип әйтеп салмасынмы Алмаз!

Өстемә бер чиләк салкын су койдылармыни! Унбер ел буена бергә укыган иптәшләремнән мондый мыскыллау сүзләре ишетермен дип һич уйламаган идем. Күңелем нык кителсә дә, күз яшьләремне күрсәтмәдем. Шул мизгелдә: «Бөтен мәктәп каршында Алмаз кыен хәлдә калдырмас. Ни дисәң дә, без бит сыйныфташлар», дигән уй ялтырап үткәндәй булды.

Тик уйлаган уйларым юш килмәде. «Хушлашу вальсы» агыла башлауга сыйныфташым, үч иткәндәй, Алия Харисовнаның каршысына барып басты. Сыйныф җитәкчесе, Алмазга ачулы карашын ташлап, теләртеләмәс кенә артыннан иярде. Инде елап җибәрәм дигәндә, физкультура укытучысы Илгиз Гайниевичның каршыма атлавын күреп, тыелып калдым. «Айсылу, әйдә вальс әйләнәбез», – дип, ул мине җай гына биергә алып төшеп китте.

Моңсуланып йөрүемне әни дә сизә инде. Теге чакны соңгы кыңгырау бәйрәмендәге хәлләрне үз күзләре белән күрде бит. Җае туры килдеме: «И кызым, сиңа дигәне табылыр әле. Мин әйтте диярсең, бер дигән егет карар үзеңә. Күңелең матур бит синең. Бу дөньяда якты һәм матур күңелле кешеләр сирәк ул», – дип юаткан була. Әле дә әти-әни бар инде күңелне үсендерергә. Алар булмаса, бу дөньяда серләремне кемгә сөйләр идем дә, шатлыгымны кемнәр белән бүлешер идем?

Кичләрен йоклап китә алмый борсаланып яткан чакларда: «Нәрсә соң ул матурлык?» дигән сорауны үз-үземә еш бирәм. Матурлык, әни әйтмешли, кешенең күңелендә булырга тиештер, минемчә. Күңеле матур кешенең йөзе дә якты, уйлаган уйлары да чиста-пакь була бит. Матурлыкны, бәлки, кемдер йөз-кыяфәтнең чибәрлегенә, килешле буй-сынга кайтарып калдырадыр. Тик йөз чибәрлеге генә матурлык төшенчәсенең бөтен асыл сыйфатларын да ачып сала ала микән? Минемчә, матурлык ике төргә бүленә: тышкыга һәм эчкегә. Тышкысы йөз-кыяфәтнең чибәрлегенә генә кайтып калса, эчке матурлыкның мәгънәсе тирәнрәк. Тышкы һәм эчке матурлык тәңгәл килгәндә генә кеше бар яктан да камил шәхес була аладыр ул.

* * *

Вакыт дигәнең аккан су белән бер: «һә» дигәнче үтә дә китә икән. Алмаз белән сөйләшүдән соң бер ай чамасы вакыт узган иде бугай. Экранда янә аның номеры калкып чыкты:

– Сәлам, сыйныфташ, таныдыңмы? – дип сүз башлады ул.

– Таныдым, шалтыратучылар исемлегендә хәзер беренче булып торасың, – дип, тыныч кына җаваплладым.

– Алдагы атнада Сабантуй икәнлеген онытмагансыңдыр бит. Авылныкыннан соң, барыбыз да җыелып Агыйдел буена төшеп китәбез, – диде Алмаз, «юк» дип әйтергә урын калдырмаслык итеп.

«Ялгыз кешенең нинди планы булсын инде?» – дип әйтмәкче булган идем дә, тыелып калдым:

PRESSA.RU

– Барырга уйлап тора идем, – дип җаваппладым.

– Алайса, Сабантуй яланында очрашканчыга кадәр, – дип саубуллашты Алмаз.

Шәһәрдә яшәү һәм эшләү сәбәпле, сыйныфташлар белән юньләп күрешкән дә юк. Сигезебездән беребез дә авылда калмадык. Алмаз – Мәскәүнең үзендә үк эшли, эшкуарлык белән шөгыльләнә, диләр. Айнур белән Гөлнур – Чаллыга, Илнар белән Рәсим район үзәгенә урнаштылар. Сөмбел белән Айгүзәлне чит районнарга кияүгә алып киттеләр. Алмаз белән миннән башкалар барысы да гаиләлеләр. Һәркайсы берешәр-икешәр бала үстерә. Әни теге чакта: «Сиңа дигәне табылыр әле», – дисә дә, һаман үз парымны очрата алганым юк. Мәктәп белән тулай торак арасын таптап уза гомер. Юк, тулай торакта гына бикләнеп утырмыйм мин. Кайбер чакларда бүлмәдәш кыз белән татар концертларына баргалыйм. Ничәмә тапкыр концертка барып, юри генә булса да ялгызы гына килгән егетне очратканым булмады. Үткер кызлар яхшы егетләрне яшь чакларында ук сайлап алып бетерәләр диюләре дөрестер, күрәсең.

* * *

Иртәгә Сабантуй дигән көнне шәһәрдән авылга кайтып төштем. Әни мин кайтуга телне йотарлык тавык ашы, бер өем тәбикмәк пешереп куйган, әти мунча өлгертеп йөри. Рәхәт тә соң туган йортта. Тәбикмәк белән чәй эчеп, мунча кереп чыкканнан соң, тәннәр язылып, сулышлар иркенәеп киткәндәй булды. Әни җәйгән йомшак түшәккә менеп ятуга изрәп йоклап та киткәнмен. Йокыдан уянганда кояш кыздыра башлаган иде инде.

– Бигрәк тәмле итеп йоклый идең, бәбкәм. Шуңа иртән иртүк уятырга кыймадым. Сабантуй башлангандыр инде, тамак ялгап ал да менеп китәрсең, – диде әни.

Йомшак түшәк җылысыннан аерылырга теләмичә, бераз киерелеп-сузылып алдым да торып утырдым. Аннары тышка юынырга чыгып киттем. Кәеф шәп, күңел күтәренке. Җитмәсә, гомер булмаганны, матур төш керде бүген – тау башына менеп пар күгәрченнәр очырып йөрдем.

Тиз-тиз генә тамак ялгап алдым да тау башында гөрләгән Сабантуй яланына менеп киттем. Тауга күтәрелеп кенә килә идем әле, кызу-кызу адымнар белән миңа таба килүчене шәйләп, туктап калдым. Кем соң бу? Бәй, Алмаз түгелме соң? Кара син аны, ничек калынаеп киткән. Мәскәү килешкән үзенә. Алмазны күргәч, башка килгән тәүге уй шул булды. Агыйдел суыдай яшькелт-соры күзләре, кызларныкыдай нечкә иреннәре, дулкынланыбрак торган коңгырт чәчләре, май кояшы кебек елмаюы – берсе дә үзгәрмәгән.

– Кара әле, танырлык та түгел үзеңне. Син бит, Айсылу, тагын да матурланып киткәнсең, – дигәч, «Нәрсә, бу мине үчеклиме, әллә чынлап әйтәме?» – дип сагаеп калдым.

– Урамда күрсәм, билләһи, танымас идем үзеңне. Бер кашык суга салып йотарлык булгансың. Хәер, укытучы кеше шулай матур булырга, үзен карап кына йөртергә тиеш инде ул. Безнең Алия Харисовна да шундый иде бит, – дип, минем «матурлык»ка мәдхия җырлавын дәвам итте Алмаз.

Кем кем, ә Алмаз белән күрешүне болай итеп күз алдына да китермәгән идем. Май кояшымыни, әллә каян балкып тора. Әйтерсең лә теге чакны кыз күңелен бөтенләй рәнҗетмәгән дә, мине кеше алдында мәсхәрәгә калдырмаган. «Уф, яшең барган саен, бигрәк бөтен нәрсәне энә күзеннән үткәрергә өйрәнеп киттең әле. Күрмисеңмени, сыйныфташың сине ничек якын итеп тора. Шул җитмимени сиңа, тинтәккә», – дип, күңелгә килгән килделе-киттеле уйларымны куып җибәрергә тырыштым.

Алмаз мине ялан читендә үсеп утыручы кушкаенга таба алып китте.

– Сыйныфташларның барысы да җыелып бетте. Сабантуй беткәнне көтеп тормыйк, хәзер үк Агыйдел буена төшеп китик, диләр. Син каршы түгелдер бит, Айсылу? – дип сорады ул, күзләремә туп-туры карап.

Егетнең карашыннан тән куырылып киткәндәй булды. Гап-гади генә сорау бирде югыйсә.

– Башкалар фикеренә мин дә кушылырмын инде, – дидем, килешүемне белдереп.

Сыйныфташлар белән якын туганнар кебек күрештек. Барысы да сагындырган икән. Гөлнур белән Айгүзәл бәбидән соң ярыйсы гына түгәрәкләнеп киткәннәр. Сөмбел исә бөтенләй үзгәрмәгән дә: мәктәптә укыгандагы кебек зифа буйлы килеш калган. Егетләр турында сөйләп тә торасы түгел, әллә хатыннары пешергән ризыклар килешкән, әллә эчкән сулары – барысы да Алмаз кебек калынаеп беткән. Очрашуга һәркем үз пары белән килгән, балаларын гына алмаганнар. Һәркайсының мине якын итеп торуын күрүгә үземә дә рәхәт булып китте. Күңелдә йөргән кимсенү тойгысы да үзеннән-үзе эреп юкка чыккандай булды. Хәтта кеше арасында кыен хәлгә калдырган Алмазга да тырнак очы кадәр дә үпкәм калмады.

Миннән башка барысының да үз транспорты бар иде. Азык-төлекне мин килгәнче үк алып куйганнар, һәркем, үз машинасына утырып, Агыйдел буена ашыкты. «Мин кемгә утырып төшим икән?» дип аптырап торганда, Алмаз: «Айсылу, сине үзем алып барам», – дип, җиңелчә генә иңнәремә килеп кагылды һәм җитәкләп алып машинасы янына алып китте.

«Карале, мәктәптә уртача гына укып йөри иде. Чит ил машинасы ук алып җибәргән. Төшемле урында эшлидер, мөгаен», дип уйлап куйдым «тимер аты»на карап. Кайда эшләве, тормыш-яшәеше турында төпченергә генә кыймадым. Кирәк дип тапса, табында утырганда үзе сөйләр әле, дип уйладым. Өйгә кереп, өстемне алыштырып, әни пешергән ит бәлешен алдым да, йөгерә-атлый Алмаз янына чыгып киттем.

Агыйдел елгасының текә ярындагы аланлыкка барып җиту белән егетләр учак ягып җибәрде, кызлар табын хәстәрләү эшенә тотынды. Сыйныфташ кызлар тәмле-тәмле бәлешләр пешереп алып килгәннәр.

Һәркем сый-нигъмәтен тезеп салгач, өстәл тагын да матурланып китте.

Ул арада уха да пешеп чыкты. Айнурның абыйсы кичә балыкка барган, кучтәнәчкә дип җибәргән икән. Иң элек балык шулпасыннан авыз иттек. Ашап-эчеп алганнан соң, тост әйтүләр башланды. Беренче булып шушы чараны оештыручы Алмаз сүз алды:

– Дусларым! Сезнең белән очрашуга Мәскәүнең үзеннән үк очар коштай талпынып кайттым. Сезнең белән күрешүемә шатмын. Иң мөһиме: барыбыз да исән-сауларбыз. Җир йөзендә яшәүдән, сау-сәламәт булудан да кыйммәтрәк нәрсә бар бу дөньяда?! Тормышта барыгыз да үз урыннарыгызны тапкансыз, гаиләләр коргансыз, балалар үстерәсез икән. Айсылу белән безгә дә андый бәхет елмаер, Аллаһы боерса. Иртәме-соңмы без дә сезнең кебек үз тиңнәребезне очратырбыз

Моңарчы эндәшми-тынмый гына ашап-эчеп утырган Рәсим моны шундук эләктереп тә алды, уенын-чынын бергә әйтеп тә салды:

– Соң нигә ул үзеңә тиң ярны читтән эзләргә, Алмаз? Син өйләнмәгән, Айсылу кияүгә чыкмаган. Кавышыгыз да куегыз. Мин әйткән иде диярсез, менә дигән пар чыгачак сездән. Очрашырга тагын бер яхшы сәбәп булачак бит бу, шулаймы, сыйныфташлар?

Башкаларга бу сүз җитә калды, «шулай», «шулай» диешеп, гөрләтеп кул чабарга тотындылар. Җир тишеге булса, валлаһи, кереп китә идем шул мизгелдә. Колак яфракларыма кадәр кып-кызыл булып чыкты. «Нәрсә, тагын күмәкләшеп миннән көләргә уйладыгызмыни?» дип үпкәләп, табыннан торып ук китмәкче булган идем дә, уемнан кире кайттым. «Язмаганны сөйләмә әле, Рәсим», – дип, карашымны җиргә төбәдем, шул мизгелдә күз кырые белән генә Алмазга карап алдым.

– Дөрес фикерлисең, Рәсим. Айсылу егет карамаслык кыз түгел, – диде ул, бу сүзләргә җавап итеп.

Алмаздан мондый җавап көтмәгән идем, алга таба вакыйгалар нинди юнәлеш алыр икән дип, карашымны җиргә төбәп утыруымны дәвам иттем. Рәхәт тә, кыен да иде миңа бу мизгелдә. Рәхәт – чөнки бу сүзләрнең ихластан әйтелгәнлеген тоям, кыен – чөнки Алмазга күтәрелеп карарга оялам.

Тукта, аның белән тәүге тапкыр телефоннан сөйләшкәннән бирле иләс-миләс килә башлады түгелме соң инде бу күңел? Шулай бугай шул, элгәре мондый халәттә йөргәнемне хәтерләмим. Әллә 32 яшькә кадәр егетләр белән йөргәнем булмаганга шулай тоеламы бу, белмәссең. Үзгәрдем, нык үзгәрдем мин соңгы вакытта: хәтерем югалды, башымдагы уйларым чуалышып бетте, күңел кошым, читлегеннән очып чыгардай булып талпынып, канат кагына башлады.

– Рәсимнең әйткәннәре Аллаһы Тәгаләнең «амин» дигән чагына туры килсен, дип, әйдәгез монау чокырларны күтәреп куйыйк, – дигән сүзләр татлы уйларымнан арындырып җибәрде.

Чокырлар бушагач, мине кыен хәлдән коткарырга теләптерме, Алмаз барыбызны да күмәк уенга чакырды. Уен уйнап, шашлык кыздырып, су кереп, көннең кичкә авышканлыгын сизми дә калганбыз.

«Инде кайтырга да вакыт җиткәндер», дип уйлап кына куйган идем, шулчак кемнеңдер машинасыннан «Соңгы кыңгырау» бәйрәмендә яңгыраган «Хушлашу вальсы» көе агыла башлады:

Әйләнәбез парлашып,
Балачакның соңгы вальсы.
Бергә узган шул вакытлар
Күңелләрдә мәңге калсын...

Таныш көйне ишетеп, дертләп үк киттем. Унбиш ел элек булган вакыйгалар чылбыры йөгерешеп күз алдымнан үтте. Күзләремә ачы яшь бөртекләре килеп тыгылды. Ул арада сыйныфташлар, һәркайсы үз парын алып, биергә төшеп китте. Шунда берәүнең сак кына иңсәмә кулын салганлыгын тоеп, сискәнеп киттем. Яныма Алмаз килеп баскан икән.

– Айсылу, биибезме? – диде ул, мине җиңелчә генә үзенә тартып. «Мин синең белән биемим», – дип авызымны турсайтасым килсә дә, аякларым үзеннән-үзе аның артыннан атлады. Алан уртасына чыгып басып, кулларымны аның киң җилкәсенә салуга, Алмаз: «Җирәнчәчем», – дип, мине күкрәгенә кысты. Муеныма аның җылы тыны килеп бәрелде. Чытырдатып күзләремне йомдым. Аннары күтәрелеп Алмазга карадым. Аның миңа төбәлгән яшькелт-соры күзләреннән оялып, тиз генә карашымны читкә бордым. Шунда бу көйнең Алмазның машинасыннан агылганлыгын шәйләп алдым һәм үзалдыма елмаеп куйдым. Үзем исә егетнең киң күкрәгенә тагын да ныграк сыендым. Бу мизгелдә талгын гына агылган «Хушлашу вальсы» йөрәктән йөрәккә күпер салырга өлгергән иде инде.

* * *

Парлы биюдән соң, кайту ягын хәстәрли башладылар. Алмаз: «Әйдә, тагын аз гына утырыйк инде, бергә-бергә күңелле бит», – дип, сыйныфташларны калырга үгетләп караса да, «Өйдә балалар көтеп тора, әнкәйләр дә борчыла башлаганнардыр, болай да көне буе Агыйдел буенда яттык», – дип, сүз куешкандай, тиз-тиз генә кайтып китү ягын карадылар. Агыйдел буенда Алмаз янында каласым килсә дә, мин дә, сабакташларым белән беррәттән, кайтырга җыендым. Парлы биюдән соң, Алмазга утырып кайтмаска, дигән карарга килгән идем. Шуңа да:

– Мине дә үзегез белән алып кайта алмассызмы икән? – дип, шыпырт кына Гөлнурга эндәштем.

– Әллә синең күзләрең томанланган инде, сабакташ? Югыйсә Алмазның үзеңә күзе төшкәнлеген күрми калмас идең. Әллә күреп шулай кыланган буласыңмы? Исәр булма, тәкәбберләнмә, сөю кошы менә-менә күңелеңә очып керәм дип торганда, кулыңнан ычкындыра күрмә. Булса – бүген кавышып калачаксыз, булмаса – икегез ике якта каңгыраячаксыз, – дип пышылдады Гөлнур.

– Уңайсыз бит әле, – дигән булдым җавапсыз калмас өчен генә. Үзем исә, Алмазны күргәннән бирле, вакый-

PRESSA.RU

галарның нәкъ Гөлнур әйткәнчә борылыш аласын күңелдән генә көтеп йөри башлаган идем инде.

Гөлнур дөрес әйтә, тәкәбберлек бар инде миндә. Үземә гел зыянга гына эшли торган тәкәбберлек ул югыйсә. Бүген менә холкымдагы шул сыйфатны аяк астына салып таптарга кушалар. Бара алырмынмы бу адымга? Сөю кошын тотып кала алырмынмы? Хәер, нигә вакыйгаларны ашыктырырга? Бар да үз җае белән барсын соң, дип уйлап, учак сүндереп йөрүче Алмаз янына килеп бастым.

– Без дә кайтабызмы? – дим, бер-бер артлы кайтыр якка кузгалыша башлаган машиналарга ымлап.

– Ашыгасыңмыни? – дип сорады Алмаз, вакытны сузарга теләгәндәй.

– Юк, ашыкмыйм. Ашыгып барырдай җирем юк алай, – дип, иңнәремне сикертеп куйдым.

– Ашыкмагач, әйдә, Агыйдел буенда бераз сөйләшеп утырыйк. Ни дисәң дә, унбиш ел аз вакыт түгел. Кемгәдер серләреңне сөйләгәч, күңелләр бушанып кала бит ул.

– Ярый алай булгач, син әйткәнчә булсын, әйдә, – дидем, ризалашуымны белдереп.

Шулчак Агыйдел өстен яңгыратып ак пароход кычкыртып җибәрде.

– Әйдә, пароходка сәлам биреп калабыз. Ул да безне күреп кычкырта бугай, – дип, йөгерә-атлый текә яр буена килеп бастык.

Ниндидер бәйрәм үткәрәләр, ахрысы, пароход палубасы шау-гөр килеп тора. Җырлыйлар, биилә, күңел ачалар. Парлашып Агыйдел ярын күзәтеп баручылар да бар. Серле бер тынлыкта пароходны күз карашыбыз белән озатып калдык. Тынлыкны Алмаз бозды:

– Ямьле дә соң үзебезнең Агыйдел буйлары! Шушында кайтып, күкрәк тутырып бер сулыш алсам, Агыйделдә тансыгым басылганчы су коенсам, тәнгә еллык дәрман кереп тулгандай хис итәм үземне. Шуңа да ялымны һәрвакыт җәйге чорда алырга тырышам. Айсылу, син дә җәйге каникул чорында өйдә ятасыңдыр бит? Мин кайткан вакытларда нишләп бер дә урамда күренмәдең икән? – дип, кисәк кенә сорап куйды Алмаз.

– Мин бит, Алмазга күреним әле, дип, урам буйлап чабулап йөрмим. Өйдә генә утырам, – дип, төрттеребрәк җавап бирдем.

Ул «алай икән» дигән мәгънәдә баш кагып куйды да, миңа якын килебрәк:

– Әнә, күрәсеңме анау утрауны, – дип, Агыйдел елгасының уң ягында урнашкан комлыкка төртеп күрсәтте.

– Күрәм, – дим, утрауга таба карашымны борып.

– Беләсеңме аның ничек аталганын? – дип, миннән сорау алуын дәвам итте егет. Шушында туып-үссәм дә, утрауның ничек аталганлыгын белми идем, шуңа, «юк», дип, иңсәләремне сикертеп куюдан уза алмадым.

– Мәхәббәт утравы ул, – диде егет белдекле кыяфәт чыгарып.

– Нигә шулай аталган инде ул? – дип кызыксындым.

– Менә монысын ук белмим инде, Айсылу, – диде ул, бу хакта нигә сүз кузгаттым инде, дигәндәй.

– Алмаз, бигрәк серле күренәсең әле син бүген.

– Серле дип, серле дә түгел инде, – дип, кыяр-кыймас кына җавап бирде Алмаз.

Сизеп-күреп торам: аның миңа нидер сөйлисе килә. Тик башлап китә алмый гына интегә.

– 32 яшемә җитеп, кызлар кулы да тотып караганым юк, дия генә күрмә, барыбер ышанмыйм, – дидем, аңа сөйләр сүзен башлап китәргә җай биреп.

– Дөрес әйтәсең, кызлар кулы тотып карамаган егет түгел инде мин, – дип килеште Алмаз.

– Шуннан, ниндирәк егет инде син? Сөйлә, давай, ялындырма. Мәктәптә укыганда бер дә мондый түгел идең ич. Бер сөйли башласаң, туктата алмый интегә идек, – дип шаяртып алдым аны.

– Сөйләгәч сөйлим инде, Айсылу. Тик минем хикәятемнән соң бер генә минутка да минем янда каласың килмәс, дип кенә куркам шул.

– Нинди куркак куян булдың соң әле син, Алмаз? Куркам да, куркам дисең. Сөйлә башта, аннан карарбыз. Барыбер синсез кайтып китә алмыйм бит инде. Караңгы төндә урман эченнән ялгызым атларга әллә мине куш йөрәкле дип беләсеңме? – дидем, шаяртып. Кайдан сөйли башларга соң әле, дигәндәй, бераз тын утырды да башлап китте:


– Бәлки ишеткәнсеңдер, Мәскәүдә мин зур гына фирманы җитәклим. Эшем, Аллага шөкер, көйле бара, клиентлар ышанычлы, бизнесым тотрыклы. Күңелнең матди ихтыяҗын басардай бар да бар миндә. Тик менә монда гына бушлык, – диде ул, йөрәк турысына төртеп күрсәтеп.

Күңелен бушатырга җыенган кешене артык сораулар биреп бимазалыйсым килмәде. Күрәм, бик үк ачылып китәсе килми егетнең. Шул ук вакытта күңелен бушатасы да килә.

– Ялгыз кеше өчен, беләсеңме, иң авыры нәрсә, Айсылу?

– Юк, белмим, – дим аңа, үзем исә: «Мин дә ялгыз бит. Чыннан да, нәрсә соң әле иң авыры?» дип уйлап алам. Озын кичләрне бер ялгызың үткәрүдер, мөгаен. Алмаз минем уйларны укыгандай:

– Озын кичләрдә бер ялгызың калу, – дип сүзен дәвам итте. – Шундый чакларда күзгә яшьләр килә. Егетләр еламый, дигән булалар да ул. Еламый димени, күңел кемдә дә бер бит инде ул. Күңел йомшарган чакларда: «Эштән кайтуга хатыным йөгереп чыгып каршы алса, тәмле ашлары белән сыйласа, балаларым, «әти» дип, муеныма килеп сарылса, мин нинди бәхетле булыр идем!» – дип уйлап куям. Чынлап әйтәм, элек бу хакта уйлап та караган юк иде. Утызны узгач, күңелгә шушындыйрак уйлар керә башлады. Җитмәсә, әнкәй ялга кайткан саен: «Өйлән, давай, әнә, сабакташларың икешәр-өчәр бала үстерә. Оныклар сөймичә дә үлеп китәм ләбаса», – дип теңкәне корыта. «Әнә, Айсылу ялгыз йөри дә, син», – ди.



Рәсем: Наталья Васильева

Егетнең бу сүзләре миңа корт чаккандай тәэсир итте:

– Әнкәң кушканга мине сабакташлар белән очрашуга чакырырга булдыңмы? – дип, егетне бүлдереп сорау бирдем.

– Юк инде, нишләп аңа булсын. Монысын ук сөйләмәм диган идем дә, тәки сөйләтәсең инде, – диде дә егет, бераз тын торганнан соң дәвам итте:

– Әйткән идем бит кичләрне ялгыз үткәрү кыен иде, дип. Эшкә баргач, дус дип санап йөргән бер хезмәттәш егеткә сүз уңаеннан гына шул хакта ычкындырдым. Тегеңә җитә калган бу сүзләр.

Икенче көнне туган көнем иде. Иртүк кабинетыма килеп кереп: «Мин сиңа бик шәп туган көн бүләге әзерләдем. Кафега-фәләнгә чакырам дип, авызыңны да ачма, дус кызым белән өеңә киләбез. Әзерләнеп көтеп тор», – дип, борылып чыгып китте. Табын әзерләтү проблема түгел хәзер. Бер генә шалтыратасың, җаның ни тели, шуны өеңә үк китереп бирәләр. Мин дә шулай иттем. Кичке сәгать җидегә бәйрәм табыны әзер, мин кунакларымны көтеп басып тора идем инде.

Хезмәттәшем бик төгәл кеше минем. Җиде тулу белән ишектә кыңгырау тавышы ишетелде. Ишекне барып ачсам, ни күрим, икәү генә түгел, өчәүләп килгән болар. Үзләре белән бер кызны да ияртkәннәр.

– Алмаз, ачуланма инде. Анжела янына ахирәте кунакка килгән булган. Аны да үзебез белән иярттек, – дип, гаепле кешедәй миңа карады Артем. Шунда сул күзен дә кысып алды. «Миңа кыз димләргә җыена түгелме соң бу Артем?» – дигән уй йөгереп үтте. Шулай да тиз генә үземне кулга алырга өлгердем:

– Әйдәгез, үтегез, – дип кунакларга дәштем.

– Наташа, – дип, таныш түгел кыз күрешергә кулын сузгач, егылып китә яздым. Ике тамчы су кебек сиңа охшаган иде ул, Айсылу. Килеш-килбәте, буй-сыны, йөз чалымнары, җитмәсә, чәчләре дә нәкъ синеке төсле җирән иде... Йөрәгем тотамы, дип торам. Үзем аңа карап катканмын, үзем: «Кит, дивана, әллә юләрләндеңме? Нишләп Айсылу булсын ул», дим эчтән генә. Каушадым да төштем, шулай да кызның йөзенә тагы бер кат текәлебрәк карарга батырчылык иттем. Бары шунда гына борын очында миңе барлыгын да, күзләренең төсенең дә синеке кебек яшькелт түгел, зәңгәр икәнлеген, буеның да кыскарак булуын чамалап өлгердем.

Табынга утыргач, Наташа, тәлинкәмә әле салат салган булып, әле уылдыклы кабымлык куйган булып, үзенчә мине кайгыртырга тырышты. Кызның ничек тә миңа ярарга тырышуы әллә каян күренеп тора. Шуның белән үзеннән биздерде дә куйды ул. Чебен кебек артык күзгә кереп барган кешене яратмыйм мин. Кызларның да әрсезләренә түгел, тыйнакларына өстенлек бирәм... Үзем, иплән кенә, таныш булмаган кызга күз салам, үзем: «Ярты сәгать саен тәмәке тарткан, ирләр кебек шәраб чөмергән кыз белән чәчемне чәчкә бәйлимме соң, Аллам сакласын! Чуртыма да кирәк түгел бу миңа. Тыйнак, әдәпле, оялчан булулары белән аерылып торучы үзебезнең кызларга җитәме соң!

PRESSA.RU

Өйләнсәм дә, үз динемдәге кызга гына өйләнәм!» дип уйланам. Бер сүз белән әйткәндә, күңелемә хуш килмәде минем туган көн бүләге. Бер-ике сәгать вакыт үтүгә, кайчан кайтып китәр инде болар, дип утыра башладым. Ә алар, үч иткәндәй, китмиләр дә китмиләр: юк-бар сүз сөйләп, ашап-эчеп утыралар.

Кәефләнеп алгач, Наташа тагын да ныграк кыюлана башлады. Әле алдыма менеп утыра, әле чытлыкланып битемнән үбеп китә. Кунак булганга гына тешемне кысып түзеп утырдым инде. Кунак булмаса, әллә кайчан ишектән борып чыгарып җибәрә идем үзен... Сәгать унике тулгач кына кунакларым кайту турында сүз кузгата башладылар. Шунда Наташа: «Синең яныңда калырга бурамы?» – дип колагыма пышылды. Кызның шәраб исе аңкып торган тыны килеп бәрелүгә күңелне җирәнүле тойгы биләп алды. Шуңа да ике дә уйлап тормыйча: «Юк», – дип җавап бирдем. Теге, авызын турсайтып, ишеккә таба атлады.

Кунаклар кайтып китүгә авылга шалтыратып синең хакта белештем. Күршем Таһир: «Айсылу шәһәрдә укытучы булып эшләп йөри. Аның кебек күркәм холыклы, матур күңелле кешене көндез чыра яндырып эзләсәң дә таба алмыйсың», – дигәч кенә җаныма җылы йөгерде. Беләсеңме, шул көннән башлап әллә нәрсә булды миңа, Айсылу. Гел синең турыңда гына уйлап йөри башладым. «Җирән чәчләре һаман шул килеш микән, буятмадымы икән?» дип, сине төрле кыяфәттә күз алдына китерергә тырыштым. Теге чакны – «Соңгы кыңгырау» бәйрәмендә сине рәнҗетүем бер генә минутка да күз алдымнан китмичә җәфаландым. Яшь идем шул ул чакта, акны карадан аера белми идем. Сине тизрәк күреп сөйләшәсем, яшьлектәге шул хатам өчен гафу үтенәсем килде. Уйланып йөри торгач, сыйныфташлар белән очрашу оештырырга кирәк, дигән фикергә килдем. Шунда гафу үтенергә берәр җай чыгар дип өметләндем.

– Һәм барысы да син уйлаганча килеп чыкты, әйеме? – дип көлемсерәдем, егетнең бу хикәясен тыңлагач.

Үзем исә ышанырга да, ышанмаска да белмәдем аның бу сүзләренә. Ышанмаслык та түгел шул, берберенә ике тамчы су кебек охшаш кешеләр Җир йөзендә юк түгел. Ялганламыйдыр Алмаз. Ялганлаган кешенең күзләре янып тора бит ул. Әнә бит егетнең күзләрендә һичбер андый кылану чаткылары юк. «Яшь чак – юләр чак», дип борынгылар белми әйтмәгәндер. Адәм баласы бит ул да. Ә адәм баласы хаталардан хали түгел. Бүгенге дөньяда бер гөнаһысы да булмаган бәндәне, бар, табып кара. Юк ул андый кеше. Без бит бу җиргә абынырга, хаталанырга һәм дөрес юл табып, кабаттан торып китәр өчен килгәнбез. Тормыш юлында каршылыклар очрап тормаса, аларны җиңә белмәсәң, яшәүнең нинди кызыгы булыр иде дә, нинди яме булыр иде, дип уйландым эчемнән генә.

Алмаз, хикәятем тәмам дигәндәй, көрсенеп куйды да кыюсыз гына:

– Айсылу, теге вакыттагы хатам өчен гафу итәсеңме мине? – дип сорады. Шул мизгелдә: «Юк, итмим», – дип, авызымны турсайтып торып китәсем килсә дә, сүзләренең ихласлыгын, карашының әчкерсезлеген тоеп:

– Итәрмен инде алай бик инәлеп сорагач, – дип, керпе кебек энәләремне тырпайтып кына җавап бирдем.

– Рәхмәт сиңа, – диде ул, иңбашымнан кочаклап алып.

– Нәрсә өчен рәхмәт? – дип, исем өчен генә сорадым аннан.

– Хаталарны кичерә белгәнең өчен рәхмәт, – диде ул Агыйделгә карап.

Аны кыен хәлдән коткарырга теләп:

– Синең турыңда белдек, хәзер мин үзем хакында сөйлимме соң? – дип егеткә таба борылдым.

– Үзеңә кара. Сөйләмәсәң дә, мин синең хакта белеп торам инде. Әйбәтлегең йөзеңә язылган бит, – диде ул, чәчләремә җылы тынын өреп.

Тыны чәчләремә килеп кагылуга, әллә ничек – тән куырылып киткәндәй булды. Алмаз, мена-менә «Җирәнчәч», дип үчекләр кебек тоелды. Ул исә минем янга тагын да якынрак күчеп утырып, авызын колагым турысынарак куеп:

– Җирәнчәчем, – дип пышылдады.

Бәхеттән башым әйләнә башлавын тоеп, күзләремне йомдым. Үзем җаным-тәнем белән шушы мизгелнең тагын да озаккарак сузылуын теләдем.

* * *

Агыйдел әкрен генә дулкыннарын ярга кага. Биткә дымлы җылы җил килеп бәрелә. Елга өстеннән ак томан күтәрелә. Анда-санда акчарлаклар тавышы ишетелә. Аларга чикерткәләр җыры, текә яр хуҗалары – имәннәр шавы кушыла. Бар дөньямны онытып, Агыйдел буеның кабатланмас табигатенә сокланып утырганда, парлап кычкырган акчарлаклар тавышын ишетеп, сискәнеп киттем. Алмаз да карашын шул якка борды.

– Кара әле, акчарлаклар! Парлылар! Алар шулай таңда ук уяналар микәнни? – диде ул, гаҗәпләнеп.

– Балаларын ашатасы булганга иртә таңнан уянганнардыр, – дидем җавапсыз калмас өчен генә.

– Юк, аңа түгел, безне сәламләр өчен шулай парлап очып йөриләрдер алар, – диде Алмаз, мине үзенә табарак тартып.

...Без, Агыйделгә сокланулы караш ташлап, кайтыр якка борылдык. Бер-ике адым атлауга, артыбызга борылып карадык. Ни күрик, акчарлаклар, очуларыннан туктап, без утырган яр кырыена килеп кунганнар, мәхәббәттә аңлашкандай, томшыкларын томшыкка терәгәннәр. Моны күреп, икебез берьюлы елмаеп куйдык. Ирексездән, безнең дә иреннәр иренгә үрелде. Татлы үбешү ничә минутка сузылгандыр, белмим. Агыйдел ярына күз салганда, акчарлаклар парлашып очып киткәннәр иде инде.

**АДӘМ БАЛАЛАРЫ КЫРЫК КЫЛЛЫДЫР УЛ. БЕР ДӘ УЙЛАМАГАН КЕШЕЛӘР КӨТЕЛМӘГӘН МАТУР ЯКЛАРЫ БЕЛӘН АЧЫЛА ДА КУЯ.**

# АЛМАМ

Асия
ЮНЫСОВА

– Алмам, тор инде, тор. Тор, әйдә. Бригадир Нәҗип абыең печәнгә төшсен, диде. Тор, Алмам, тор, тор!

Гашига түтинең улын шулай назлап-көйләп уятканын үсмергә эшкә әйткән бригадир гына ишетсә ишеткәндер. Әмма шул иртәдән Наилнең исеме онытылды. Ул Алмам булып калды. Матур гына кушамат югыйсә. Әмма үсмер егет моңа үртәлә торган иде. Үртәлеп кенә калмагандыр, кимсенгәндер дә әле. Җиткән егет булганның соңында да Алмам булудан туктамады бит ул.

Инде менә Наил карт егет. Әмма һаман – Алмам! Өйләнә алмый калуында да шул кушамат гаепле түгел микән әле? Егетләр кушаматы андый булырга тиеш түгел бит инде!

Картаеп бара шул, Гашига апа да киленсез тилмерә. Үсмер Наилнең көндәмлеге ярсучанлык, кыдрачлык белән алышынды. Хәер, әүмәкләшкән, тукмашкан өернең уртасында электән дә гел ул була торган иде. Күбрәк үзенә эләгә. Ә Наил йодрыкларны күбрәк татыган саен, үзен егетнең шәбе кебек хис итә иде бугай.

Ә менә сыйныфташы Фирая аны гел кызгана. Әнисенең бердәнбер улының – Алмамның кыйналып кайтуын күрү аңа бер дә җиңел түгелдер, дип кызгана.

Шулай бервакыт Наилнең тагын өер уртасында калуын күреп, Фирая аны, аралап алып, тиргитирги өйләренә кадәр озата китте. Гап-гади бер гамәл Наил өчен вакыйгага булган, күрәсең. Моңарчы аны әнисеннән башка җәлләүче юк иде



бугай. Өйләренә кайтып җиткәндәрәк егет «өлгереп җиткән» иде инде:

– Фирая, чык миңа кияүгә, ә, алтынга төрермен үзеңне!

– И-и, кит әле моннан! Сине яклаган булам тагын, – дип, Фирая, үз алдына тузынып, Алмамны хыяллары белән ялгызын урам уртасында калдырып кайтты да китте. Хәерчегә ачык чырай күрсәтсәң, ямаулык сорый, дигәндәй булды инде бу.

Аннан соң күп еллар узды, Фирая да тормышлы булды. Балалары үсте.

Авылга бер кайтуында урам буйлатып үзләренә таба килүче Наилне күреп алды. Фираялар күршесендәге тол хатынга ияләшкән, дип ишеткән иде аны. Әле дә шул капкага төбәп килүе икән. Күчтәнәче дә бар – бер чиләк кызарып пешкән алмалар тоткан. Икесе дә уңайсызланып калды...

Арадагы кыенсынуны йомшартып, Фирая елмаеп куйды.

– Кая әле, алмаларың тәмле микән? – дигән булып, чиләктәге алмаларга күз төшерде..

Наил, сөенә-сөенә, сыйныфташына алма сузды.

Шуның белән шул булыр иде дә бит... Шул кичне, дәресрәге, төнгә каршы капкага кагылдылар. Әнисе, кем булыр икән дип, ашыгып, чыгып китте:

– Наил икән, алмалар китергән сиңа! – дип урап керде ул. – Фираяны сыйла, Фәния апа, дигән була. Менә, сыйланыгыз...

– «Алтынга төрермен» дигән вәгъдәсе бар иде шул... Алтын югында алма да ярый, дигәндер инде.

– Гел сине сораштырып тора ул. Классташ кайткалап йөриме, ди. Өйләнә алмады шул. Йомшак булганга санламадылар үзен. Менә без дә бит әле, кияүдән дә оялмыйча, Наилдән көлгән булабыз. Элек заман булса, аңа да тиңе табылыр иде. Кызлары да юк бит аның авылда. Алмага гына түгел, Сабантуй батырына да юк кызлар...


Әнисенең сүзләреннән соң Фираяга уңайсыз булып китте. Кайчандыр җәлләгән булып, хәзер көлеп утыру икейөзлеләнү кебек тоелды аңа. Бер ул гынамы, әнә, ире дә көнләшү галәмәте күрсәтмәде.

– Йөгез әле, мин дә татып карыйм әле күчтәнәч алманы, – диюдән узмады.

Ә Наил... Йә, нәрсәдә инде аның кимлеге? Нечкә күңелле, тырыш бер адәм. Шәһәрдә үссә, сәнгать йә музыка мәктәбендә укыса, бәлки аңардан иҗат кешесе чыккан булыр иде. Йә, кем бар тагын төн уртасында алма өләшеп йөрүче?!.

PRESSA.RU





*Кайтуыңны сагынырмын*

*Сау бул инде, дисең, сау бул инде,*
*Йөрәккәем кинәт туктап куйды.*
*Куллар инде кулдан аерылды,*
*Ике канат, гүя каерылды.*

*Ишеттеңме икән тавышымны?*
*Мин көтәрмен һәр көн кавышуны.*
*Бергә йөргән сукмакларга*
*табынырмын,*
*Сагынырмын, кайтуыңны*
*сагынырмын.*

*Салкын гына өздең араларны,*
*Нинди сүзем сине яралады?*
*Адымнарың йөрәк санап торды:*
*«Аерылдык, – диде, – аерылды...»*

*Ишеттеңме икән тавышымны?*
*Мин көтәрмен һәр көн кавышуны.*
*Бергә йөргән сукмакларга*
*табынырмын,*
*Сагынырмын, кайтуыңны*
*сагынырмын.*

Наил КАСЫЙМ

# ИШЕТТЕҢМЕ ИКӘН ТАВЫШЫМНЫ?

Күпләр миннән: «Бу шигырең кайчан, ничек язылды, бу җырыңны кемгә багышладың?» – дип сорыйлар. Минемчә, хис, тирән кичерешләр иҗат итәргә этәрә. Чыннан да шулай. Күп очракта ул хис көтмәгәндә-уйламаганда килә, аны чакырып китереп булмый. Шул хис бөтен барлыгыңны чолгап ала да һич тынгы бирми. Йөрәктән чыккан гына йөрәккә барып җитә, диләр бит: синең кичерешләр меңнәрнең күңел кылларын тибрәтә. Хис бит ул бер мизгел. Тормыштагы барлык мизгелләрне дә хәтердә тоту мөмкин түгел. Күп җырларымның язылу тарихын хәзер инде үзем дә хәтерләмим. Ләкин бер җырның язылу тарихы күңелемдә әле дә булса саклана менә.

Салкын гына өздең араларны,
Нинди сүзем сине яралады?
Адымнарың йөрәк санап торды:
«Аерылдык, – диде, –
аерылды...»

Бу сүзләр минем «Кайтуыңны сагынырмын» дигән җырдан. Ул җырның сүзләре узган гасырның 80 нче еллар ахырында язылды. Бүгенгедәй хәтеремдә, җәйнең бер матур кояшлы көнендә мин Нурания апамны Мәскәүгә озатырга тимер юл вокзалына килдем. Апам Мәскәү егетенә кияүгә чыгып, күптән шунда яши иде инде. Ә җәй көннәрендә авылыбыз Ашытбашны, безнең Тукай-Кырлай якларын сагынып кунакка кайтып килә. Аннары авыл кучтәнәчләре төяп, озатып җибәрәбез үзен. Шул чираттагы озату киче иде монысы да. Минем әле өйләнмәгән вакыт. «Татарстан» поездына утырта башлауларын көтеп, төрле кызыкларны искә төшереп, авыл хәлләрен сөйләшеп басып торабыз. Перронда халык. Кемнәрдер китә, озатырга килүчеләре дә шактый. Кыяфәтләренә, үз-үзләрен тотышына, киенү рәвешенә карап, «Болары Мәскәүнеке инде!» – дип куясың. Көяз кызлар, кәттә егетләр... Дипломат кына тоткан чиновниклар... Каникулда башкала күрергә баручы мәктәп балалары... Нindидер көтүле, ашкынулы рәхәт мизгелләр... Сәгать уклары китәр минутларга якынлаша. «Казаннан Мәскәүгә баручы поезд беренче юлда, китү вакыты 19 сәгать 20 минут» дигән белдерү яңгырый. Хәзер вагоннар җай гына селкенер дә, тәгәрмәчләр текелди башлар, Сәйдәшнең «Совет Армиясе» маршы яңгырар...

Апам вагонга кереп утырды, елмаеп, тәрәзәдән миңа карап тора. Менә-менә поезд кузгалырга тиеш... Шул ук тәрәзәдән бер егет тә карап, кемдер белән саубуллаша. Борылып карасам – чибәр генә бер кыз. Мин генә түгел, башкалар да игътибар итми калмагандыр аңа. Күпләр күзе төшәрдәй иде ул. Озын чәчле, төз гәүдәле. Ыспай киенгән. Нindидер затлылык, зыялылык бөркелә үзеннән. Юк, бу кыз авылныкы түгел инде. Аяк атлаулары килешле, хәрәкәтләре нәфис, сыгылмалы. Актриса кебек ул! Тукта, кайда күргәнем бар соң аны? Әһә, искә төште... Ирина Алфёровага охшаган икән бит ул! Советлар Союзындагы иң чибәр актрисага! Кинәт кенә күңелдә ул уйнаган рольләр, фильмнар йөгереп узды: «Д'Артаньян и три мушкетера», «Хождение по мукам», «С любимыми не расставайтесь»... Поезд әкрен генә кузгалды. Мин апамны кул болгап озатып калдым. Ә теге чибәр кыз поезд янәннан йөгерә-йөгерә бара, нидер кычкыра, ләкин вагон тәгәрмәчләре тавышы аша сүзләре миңа барып җитми.

Поезд тизләнгәнче ул шулай, егетенә нидер әйтергә теләп, вагон белән янәшә йөгерде. Их, мине шулай озатып калсалармы, дип уйлап куйдым. Теге егетнең тәкәббер йөзе бер дә ошамады инде. Мәскәүнекедер, мөгаен. Ул кадәр һаваланмас иде... Ялгыш та елмаймады бит шунда. Карашында боз салкынлыгы иде.

Поезд китеп күздән югалды. Мин уйланып басып торам. Карыйм, теге кыз минем яннан сулкылдый-сулкылдый узып бара. Мин дә нәрсә әйтергә белми, юатасы килеп, аның артыннан иярдем. Тик нәрсә әйтә алам соң? Мин кем аңа? Кыз күкрәген тотып бераз барды да чайкалып китте, егылмас өчен якындагы фонарь баганасын кочып алды. Гәүдәсе дер-дер килә, үзе бер тавыш чыгармый. Аның һәр күзәнәге елый иде. Бу хәл бик нык тетрәндерде. Әйтерсең, мин кино карадым. Ләкин ул чын кино, тормыш киносы иде. Чын вакыйгалар, чын геройлар, чын күз яшьләре... Өйгә кайткач та озак тынычлана алмый йөрдем, шул кыз күз алдымнан китмәде. Ул егете белән Казан урамнарында йөргәндер, мөгаен. Матур сүзләр дә сөйләшкәннәрдер. Бәлки, егет, яратам, дигәндер. Кыз аны озатырга вокзалга килеп тә йөрмәс иде. Тик нәрсәдер булган – арадан салкын җил узган. Кыз, саксыз сүз әйтеп, кәефен бозганмы? Үпкәләткәнме? Шуңа күрә, гафу сорап, поезд артыннан йөгерәме? Юк, саубуллашуны ул болай итеп күз алдына да китермәгәндер. Әйтеләсе сүзләре калгандыр. Әмма ул кыз һаман нидер өмет итә әле. Мәхәббәткә ышана. Ул гашыйк. Ул аңа табына. Көтә. Сагына... Мөгаен, ул кайтканда кабат бергә йөргән урамтыкрыклардан үткәндер... Күз яшьләре аша елмаеп, кадерле кешесенең һәр сүзен, кинокадрлар кебек бәгыренә уелган һәр мизгелне йөрәгендә яңарткандыр...

Шул кызның мәхәббәтенә сокланып, «Кайтуыңны сагынырмын» дигән шигырь туды. Вокзалдан кайту белән, кәгазь-ручка алып, ашыга-ашыга яза башладым. Күз алдында – һаман шул кыз. Күңелдә – хисләр өермәсе. Бераздан композитор Луиза Батыр-Болгари аңа бик матур көй язды. Ул җырны иң беренче башкаручы Хәмдүнә Тимергалиева булды. Аннан соң Венера Ганиева белән Зөфәр Билалов дуэт итеп җырладылар. Рамил Миндияр бу җырны гитара белән башкарырга ярата. Җыр озын гомерле булды. Ул әле дә эфирда, концертларда яңгырый.

Кызганыч, җыр тууга сәбәпче булган кыз гына бу турыда белми калды...

PRESSA.RU






# ҮЗЕҢНЕ ҮЗЕҢ ҖИҢЕП...

ЧАҢГЫ ТАЯКЛАРЫ БЕЛӘН КАРДАН ТҮГЕЛ, Ә КАРА ҖИР ӨСТЕННӘН БЕРЕНЧЕ ТАПКЫР КЕМ АТЛАП КИТҮЕН ТӘГАЕН ГЕНӘ БЕРӘҮ ДӘ БЕЛМИ ИНДЕ ХӘЗЕР. ФИН ЧАҢГЫЧЫЛАРЫДЫР, ДИЛӘР.



Гөлнур
САФИУЛЛИНА

Җәен күнегүләр җитмәүдән интегеп, фин чаңгычыларының кайсыдыр чаңгы таягы тотып, урамга йөрергә чыга. Бу күренеш читтән караганда шактый мәзәк кебек тоелса да, аңа иярүчеләр дә табыла. Соңрак, ярышлар вакытында исә, җәен дә күнегүләр ясаудан туктамаган – таяк белән йөргән (ул чакта аның исеме дә булмый әле) спортчыларның күрсәткечләре, аларга елмаеп кына караучыларныкыннан яхшырак булып чыга.

Сиксәненче-туксанынчы елларда Финляндиядә таяк белән йөрү бик популярлаша. Аннан ул башка илләргә дә тарала. Аны скандинав йөрүе (Nordic walking) дип атый башлыйлар. Скандинав йөрүе Халыкара ассоциациясе бүген егермедән артык илне берләштерә. Ел әйләнәсе чаңгы таягы белән урамда йөрүчеләр инде безнең авылларда да гадәти күренешкә әйләнеп килә. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы җитәкчесе Фәрит Мөхәммәтшин белән бер очрашуда Кайбыч районының Кошман авылы халкы скандинав таягы белән йөрер өчен махсус юл сораган иде. Борындык, Кошман, Олы Кайбыч, Бәрлебашы... Районның байтак авылларында үз иткәннәр спортның бу төрен. Минем туган авылым Кече Кайбычта да. Авылдашларым – Фирдинә апа Зиннәтуллина, Саимә апа Низамиева, Тәслимә Абдулхәерова, Гөлнур апа Мотыйгуллина, Әлфия апа Галиуллиналар белән бүген шул хакта сөйләшәбез.

### *Кеше ни әйтер?!*

**Фирдинә апа:** Күршем Венера аңарчы да: «Әйдә, кичләрен һавада йөреп керик әле», – дип әйткәли иде инде. Тик ялкаулыкны җиңү алай җиңел түгел бит ул... Былтыр көз исә «Манзара» тапшыруында таяк белән йөрүчеләрне күрсәттеләр. Нурлат районы кешеләре иде шикелле. Файдасы бик зур икәнен дә сөйләделәр. «Булмый бу, кичкә ничек тә безгә дә чыгарга кирәк», – дидем үземә. Чыга башладык шулай Венера белән икәү. Кешеләрдән кача-поса гына йөрибез. Авыл җирендә бер эшсез урамда йөрү күрелгән хәлме – каршыга очрасалар, ни диярләр?! Машина килсә дә, танымасыннар, дип, артыбыз белән борылып торабыз. Берсендә Илназларга туган көнгә кунаклар килгән, озатырга чыкканнар – һич таралышмыйлар. Китәләрме-юкмы, дип, Мәдинәләр капка төбендә бик озак басып тордык. Аптырап беттек. Венера: «Хәзер Мәдинә чыга, күрә инде», – ди. Тик авылда бернәрсәне дә озак яшерә алмыйсың. Сүз таралды. Ә аннан урамда йөргәндә каршыга таяклы хатыннар очрый башлады...

**Тәслимә:** Мин башта Равилә апа белән Резеда апаны очраттым. Сайлау вакытында гел клубка йөрергә туры килде. Алар шунда җылынырга кергәннәр иде. Кул туңа, калын бияләйләр киябез, дип сөйләшәләр. Кызыгып киттем, карале, әллә миңа да сезнең белән чыгасы инде, дим. Шул ук кичне аларга ияреп ферма урамыннан әйләнеп тә кайттым.

И-и, рәхәт булды... Бер көн йөрдек шулай, ике көн. Аннан Гөлфирә апаларга ашка бардык. Табын янында таяк белән урамда йөрү турында сүз чыкты. Икенче көнне безгә инде Гөлнур апа кушылды. Ул башта таяксыз чыкты әле.

**Гөлнур апа:** Авылда төрлечә кабул иттеләр инде. Эшсезләр, дип тә сөйләделәр. Урамда йөргәнче, намаз укысыннар, дип тә ишеттерделәр. Намазның үз вакыты бит аның... Барысына да өлгерәбез. Кызлар әнә эшлиләр дә. Кайтып сыер да савалар. Өйләре дә җыештырылган, балалары да каралган.

**Саимә апа:** Без күрше Әминә апа белән соң гына, кичке тугызларда гына чыгабыз. Әлеге дә баягы, кеше күзенә бик чалынмыйк дип инде. Беребезгә – 66, икенчебезгә – 76... (Бездән олыраклар да бар әле – Әлфия апа белән Гөлсинә апа. Алар гел икәү йөриләр.) Агач артына качып торган чаклар безнең дә булгалады.

*Скандинав таягы белән бүген җир шарында 20 миллионнан артык кеше йөри.*

### *Өйдәгеләр*

**Гөлнур апа:** Кичке сигез җитүгә, ирем Хәлим: «Бар, вакытың җитте бит», – ди. Әле ул минем кырысрак та кеше... Башта да сүз әйтмәде. Бәлки ябыгырсың диде. Минем кебек инде ялда булган авыл кешесе бусаганы атлап урамга сирәк чыга бит хәзер. Бигрәк тә кышын. Утын алып керәсе, су алып кайтасы, кер чайкыйсы, су түгәсе юк. Хәер, хәтта җәен дә кеше кешене бик күрми. Көтү кумыйбыз, көтү каршы алмыйбыз, адашкан сарык бәрәннәрен эзләп, авыл урамнарын әйләнмибез. Барысы да телевизор каршында. Ул сериалларны күпме карарга була инде? Аралашуга да сусалган шул. Кич утырулар, күршегә керүләр бетте. Йомышны телефон аша хәл итәбез. Кунакка өндәп йөрү дә онытылды, шалтыратып кына чакырабыз.

**Тәслимә:** Ә йөрергә чыгасы килеп кенә тора... Өлгерим, дип, ашыга-ашыга эштән кайтам. Тиз-тиз ашарга пешерәм. Шул арада дәресләр әзерлибез – өченче улым Данияр 8 яшьтә генә әле. Кайсы көнне ипи дә изәм. Ул кабарып менгәч, духовкага тыгып, иң сүрән утка куям да үзем урамга чыгам. Мин кайтып җиткәнче ипи кабарып пешә. Көя башлаган чаклары да була инде. «Шул ипине дә алмагансыз», – дип, өйдәгеләрне бик ачуланасы килә дә, дәшмим, «эш эшләп йөрмәдең әле», диярләр... Чыкмыйча калган көнне нәрсәдер җитми кебек. Үзем дә сизмичә, андый чакта тавышымны күтәрәм икән. «Әйдә, бар, чык кына», – диләр өйдәгеләр... Нибары бер сәгать бит ул!

**Әлфия апа:** Улым, киленем, оныгым белән торам. Юк, өйдә беркем сүз әйтми. Килен үзе дә чыккалады әле. Башка чакта күбрәк күрше Нурия белән йөрибез.

Фото: Раилә Хәялиева

PRESSA.RU



**Гөлнур апа:** Кыз кунакка кайткан чакларда әтисе: «Әллә бүген өйдә генә каласыңмы?» – ди. Энҗе: «Юк, юк, чыксын, файдасы тисә, йөрсен генә, мин куанып торам», – ди.

### *Файдасы турында*

**Саимә апа:** Йөргәндә, Алланың рәхмәте, аяк та авыртмый. Ә йокларга ничек рәхәт?! Күршем Әминә апа да бик файдасын күрде: урында ятып авырый иде – аяк өстендә хәзер.

**Гөлнур апа:** Кышын беребезгә дә салкын тимәде. Ялгыш бер йөткермәдек, төчкермәдек. Суык, дип, бер көн чыкмыйча калмадык! Керфекләр бәсләнә – барыбер йөрибез. Яңгыр явып тора – без урамда. Юешләнеп бетәбез, әмма кире борылмыйбыз. Үзебез көлешәбез: «Кем безне куып чыгарган инде?» – дибез. Кан басымы да күтәрелмәде. 200 гә кадәр менә иде бит... Алдагы елларны төнге сәгать икегә, өчкә кадәр, йоклый алмыйча, тәрәзәдән тәрәзәгә йөри идем. Ә быел таң атканны сизми дә калам...

**Тәслимә:** Башым сызлап тилмерә идем, быел әйтмәгәнем булсын. Әниләргә менгәндә тауга күтәрелү кыен иде – сулыш кысылмый менә хәзер.

**Гөлнур апа:** Хастаханәгә бардым да, үлчәнергә туры килде. Үлчәнсәм, 92 килога калганмын. Моңарчы 103 кило идем. Кинәт ябыга башлау да куркыта бит хәзер... Авырыймдыр дим. Яхшы гына ашап карыйм әле дим. Өч атнада тагын артып куйдым. Таяк белән йөреп кенә шулай ябыгып булганын белмәгән идем... Гәүдә зур бит, беренче мәлләрдә бик авыр йөрдем. Бөтенесеннән артта кала идем. Хәзер элдерәм генә. Иелеп нидер эшләргә дә җиңел. Менә велосипедта йөреп карарга да теләк бар әле.

**Фирдинә апа:** Саф һавадан аппетит ачылып кайта, билгеле. Әмма без, саубуллашканда, ашамаска сүз куешабыз!

*Махсус таяк әлегә беребездә дә юк, әмма быел алырга җыенабыз.*

### *Безнең авыл матур икән!*

**Гөлнур апа:** Берара шактый кеше җыелдык, юлга сыймый башладык. Түбән очтан Миләүшә белән Гүзәлия кушылды. Зөһрә апа бар әле безнең – Урта Азиядән күчеп кайттылар алар. Тагын Халидә апа чыгып карады, Гөлсирә апа... Хәсән абый килене Гөлгенә бер-ике тапкыр күренде. Әмма күпләр башлый да ташлый. Арыта, диләр. Беренче көнне без дә бик арып кайтып яттык. Бөтен сөяк-санак авырта, кыйналган кебек. Икенче көнне җиңелрәк, өченче көнне тагын да җиңелрәк. Аннары инде көйләнә... Һәр кич саен урам әйләнеп керү өчен дә ихтыяр көче кирәк. Кичке аш ашалган – тамак тук, өй җылы – газ эшләп тора, телевизор күрсәтә... Үзеңне үзең җиңеп, шул рәхәттән чыгып китү алай ук җиңел түгел.

**Фирдинә апа:** Көн саен 6-7 мең адым йөрибез – анысын телефон саный. Беренче күргәндәй, безнең авыл шундый матур икән, дибез. Башка вакыт кайчан күрәсең: өйдән эшкә барасың, эштән туры өйгә кайтасың. Ә монда иркенләп карап йөрибез: кем нәрсә үзгәрткән, кем нәрсә төзегән...

**Тәслимә:** Көздән, кар яңа төшкән вакытта, бик матур чаклар булды. Айның тулган мәле. Бөтен дөнья яп-якты – күрше авыллар күренеп тора. Багана башларында ут яна, юллар әйбәт. Урам тутырып үзебез генә йөреп торабыз шулай... Яшьләр дә юк бит хәзер авылда, булганы өйдә – интернетта утыра. Шимбә-якшәмбеләрдә генә күренәләр.

**Фирдинә апа:** Без урамнан узганда өлкәннәр тәрәзәләрдән карап кала. Рәмзия апаның Рәсимәсе әйтә: «Йөрегез, йөр, әни сезне көтеп тора, «теге хатыннар килмәде әле», «хатыннар кайтып китмәде әле», дип сөйли», – ди. Рәмзия апаның аяклары авырта, ул өй эчендә генә инде. Төнлә түгел, көндез дә урамнан бер кеше үтми бит хәзер. Мөршидә апа да карап кала икән, куанып. Ул да хәзер берүзе. Саныйлар икән, бүген ничәү чыкканнар, дип.

**Саимә апа:** Яңгыр явып, аяк асты бозга әйләнгән көннәр булды. Андый чакта авыл кырыендагы олы юлга менәбез. Казандагы кызым Гөлия борчыла: «Анда йөрмәгез, машиналар бәреп китмәсен», – ди.

**Фирдинә апа:** Олы юлга яктылыкны кайтара торган жилет киеп мендем. Иң алдан мин барам, калганнар, кыр казлары кебек, минем арттан... Безнең скандинав йөрүе белән шөгыльләнүебезне яшьләр Яңа елда клубта скетч итеп куйганнар. Гөлүзә кайтты да: «Әни, анда сезне сөйләделәр!» – ди.

### *Кызык яшибез!*

**Тәслимә:** 8 Март бәйрәменә клубта спектакль куйдык – репетицияләр вакытында мин йөрергә чыгудан туктап тордым. Фоат Садриевның «Сиңа гына әйтәм» дигән бер пәрдәлек пьесасын куйдык. Сиңа гына әйтәм дип, бер әбигә килен – кайнанадан, кайнана киленнән зарлана. Ә әби колакка каты: алар әйткәнне бөтенләй башкача аңлый һәм башкаларга сөйли. Мин кайнана булып уйнадым, килен сыерны савып бетерми, аның артыннан чыгып, имчәк төбен стаканга савып керәм, дип зарланам. Әби исә аны башкаларга: «Кечкенә балаларын ашатмыйлар икән, кайнанасы стакан белән сөт савып кереп, шул малайга эчерә икән», – дип сөйли. Гайбәт шулай туа... Кызык дип карадылар. Спектакльдә дүртәү уйнадык. Озынракны куя алмыйбыз – ир-ат рольләрен уйнарга кеше тапмыйбыз.

**Фирдинә апа:** Җылынырга дип, клубка кергәлибез. «Булсын иде шушында тренажер залы», – дип Резеда хыяллана инде. Хәер, без дә... Үзең генә гимнастика ясау кызык түгел, клубта булса йөрербез дигән идек –

тренер табылмады. Район үзәгендә – Олы Кайбычта бар да бит...

Мин үзем Олы Кайбычка бассейнга йөрим. Атнага ике тапкыр – шимбә һәм якшәмбе көннәрендә. Ай саен абонемент алам. Андагы рәхәтлек! Берәр сәгать йөзәбез. Баштарак Дамир мине алып төшә дә, машинада көтеп утыра иде. Аннан үзе дә керә башлады. «Чыкма, акчасын түләгән», – дип кенә кычкырам аңа. Рәхәт ару белән кайтабыз шуннан.

**Гөлнур апа:** Фирдинә мине дә чакыра бассейнга. Йөзә белмим, дим. Алай да су коену костюмы алып кайттым әле.

**Тәслимә:** Мин дә йөзәргә баргалыйм. Бездә хәзер эштә бәйрәмнәргә бассейнга абонемент бүләк итү гадәте бар.

**Саимә апа:** Ветераннар советы бассейнга экскурсия оештырды. Кызыгып калдым әле... Шул баруда Галия Кайбицкая музеен да күрсәттеләр, сәнгать мәктәбен дә. Икенче юлы Казанга, Камал театрына алып бардылар, «Җанкисәккәем»не карап кайттык. Балалар көлә: «Шәһәрдә дә өлкәннәр болай яшәми», – диләр...

Саимә апаның улы белән кызы дөрес әйтә: болай яшәми!



*Кичке сигез тулуга бер-беребезгә шалтырата башлыйбыз: «Чыгасыңмы?»*

## БЕЛМӘСӘҢ БЕЛ

■ Нинди таяк белән йөрергә? Гадәти чаңгы таяклары фитнесның бу төре өчен озынрак булып чыга. Әлеге дә баягы, шул ук финнар 1997 елны университет студентларын җыеп, бер тәҗрибә үткәрәләр: егет-кызларны төрле озынлыктагы таяклар белән йөртеп карыйлар. Һәм таякның иң җайлы тоелганын сайлап алалар. Ул чаңгы таягыннан 15 сантиметрга кыскарак булып чыга.

■ 1997 елны Exel Oyj фирмасы скандинав йөрүе белән шөгыльләнүчеләр өчен махсус таяклар эшли башлый. Финляндиянең барлык төбәкләрендә курслар оештырыла. Бу проектка 50 мең марка акча бүленә, әмма шөгыльләнергә теләүчеләрнең барысына да урын барыбер җитми. 2 меңгә якын укытучы-остаз гына әзерләнә.

■ Nordic walking өчен таяклар спорт кибетләрендә сатыла. Аларны төрле озынлыкта итеп көйләп була. Кайдан барсаң да – җирдә, комда, асфальт юлда – алар белән атларга бик җайлы. Таякны, гадәттә, ни дәрәҗәдә еш шөгыльләнергә теләүгә карап сайлыйлар. Көн саен йөрергә җыенасыз икән, әлбәттә, ныграгы кирәк булачак.

■ Туксанынчы еллар ахырында скандинав йөрүе спортның аерым бер төре булып санала башлый.

■ Таяк белән бөтен кеше дә йөри ала: бернинди чикләүләр юк. Өстәвенә, зур чыгымнар да кирәкми. Кайда телисең, кайчан телисең – йөрисең: таягың гына яныңда булсын. Аны «гел үзең белән булган спортзал» дип тә атыйлар.

■ Болай гына атлап йөрүдән, йөгерүдән яки велосипедта йөрүдән Nordic walking нәрсә белән аерыла соң? Скандинав йөрүе белән шөгыльләнгәндә мускулларның 90 (!) процентка якыны хәрәкәткә килә. Таяксыз йөрүгә караганда, бу очракта калорияләр 47 процентка күбрәк кими. Аның каруы, буыннарга көч азрак төшә, шуңа күрә табиблар йөгерү түгел, хәтта күп йөрүдән дә тыйган кешеләр дә Nordic walking таягы белән урамга йөрергә чыга ала. (Әмма буыннар авыртуы көчәйгән чакта, йөрәк-кан тамырлары системасы белән ниндидер проблемалар булганда, әлбәттә, башта табиб белән киңәшләшү кирәк.)

■ Скандинав йөрүенең тагын бер өстенлеге: аның белән ел әйләнәсе, теләсә кайсы фасылда, теләсә нинди һава шартларында шөгыльләнергә була. Кыш көне, теләсәң, чаңгыга да басарга мөмкин, әмма белгечләр, йөрү – кеше өчен табигый күренеш, ул аңа күбрәк туры килә, файдалырак, диләр.

■ Күренекле кешеләр арасында скандинав йөрүе белән дуслашучылар байтак хәзер. Шуларның берсе – «Тодес» шоу-балетының җитәкчесе Алла Духова. «Nordic walking белән шөгыльләнә башлагач, бер ел эчендә 15 килога ябыктым», – ди ул.

■ Каршыга очраучыларның: «Чаңгыңны югалттыңмы әллә?» – дип көлүеннән курыксагыз, Nordic walking таягы белән урамда йөрергә чыгарга берәр дустыгызны да күндерегез. Икәү күңеллерәк тә булачак.

PRESSA.RU





# КАЙТУ

Фото: Илдар Закиров



Эльмира ЗАКИРОВА

МИН АТНА БАШЫННАН УК ҖОМГАНЫ АШЫКТЫРАМ. АВЫЛГА КАЙТАСЫ БАР. АНДА – МЕҢ МӘШӘКАТЬЛЕ ТОРМЫШ, АНДА – БАР ДА ҮЗ, ЯКЫН КЕШЕЛӘР. БЕРАЗ БЕРКАТЛЫ, ҖОР ТЕЛЛЕ, ГАДИ, ЯРДӘМЧЕЛ ШУЛ АВЫЛДАШЛАР БЕЛӘН АРАЛАШКАЧ, РӘХӘТ БУЛЫП КИТӘ.

Редакциядә җиләк исе таралган. Өстәлдәге вазаларда купшы пионнар кукраеп утыра. Әһә, безнекеләр эшкә туп-туры бакчаларыннан гына килгән икән!

Мин дә ак ромашкаларны, зәңгәр кыңгырауларны, кылганнар белән аралаштырып, суга утыртам. Туган якның төсе итеп. Ялларда мин дә бер генә көнгә авылыма кайтып килдем (350 чакрым еракмы ул, якынмы?). Үзебезнең кое суы гына сусавымны басар төсле иде. Җиләк вакыты бер генә, диләр бит. Әллә анысы да күңелне кытыклады инде? Кузаклы борчактан авыз итәсе килдеме шунда, Сөндә су коенасымы?..

Юл буе, бер өзелеп, бер ялганып, уйларым бәрәңге бакчаларын, коймалары бердәй яшелгә буялган авылыбыз урамнарын, урман буйларын, басу юлларын

айкады. Беләм инде, быел да безнең аяк очындагы Сөн култыгына кыр үрдәкләре кайткан. Күлдә торналар, аккошлар бала чыгарган...

Кичләрен, кыйгачлап, өй түбәсенә тиярдәй булып төркем-төркем очучы каргаларның канат җилпүләренә кадәр ишетелә сыман. Һава үзгәрергә булса, гел шулай кубарыла алар.

Көтүгә кем чираты икән...

Печәнгә төшкәннәрдер инде...

Мишә, Нократ, Чулманнар инде еракта. Минзәләне дә артта калдырып, Ык күперен узабыз. Озакламый Сөн буе урманнары күренер. Тәрәзәдән кергән җил печән исен, чәчәкләр исен алып килә – туган як һавасын әллә каян танныла! Казан–Уфа трассасында утырган авылыбыз – юллар чатында: Актанышка – 30, Яркәйгә – 30, Бакалыга – 30 чакрым... Менә кайда ул җирнең кендеге! Мин инде өйгә кайтып кермичә дә өйдә сыман. Күңелем белән төне буе бакалар концертын, чикерткә сайравын тыңлап йокларга әзермен. Әрекмән, әрем, кычыткан, шайтан таягы, песи койрыгы, эт эчәгесе, алабута... Менә шуларның барысы бергә үскән җирне күргәнегез бармы? Ул – безнең өй арты. Андагы хуш ис!.. Башың әйләнмәле!

Капка төбендә, кайтуыбызны көтеп, әти утырадыр сыман...

Тавыклары белән нидер сөйләшеп, ишегалдында әни йөридер кебек...

Их, шулай булсачы!.. Эштән соң гына кузгалдык, «бөке»ләрдә утырып төнгә калдык, дип, күңелне алдамакчы, көтеп торучылар булмауны үземчә акламакчы булам. Ишегалдын басып киткән үлән, караңгы тәрәзәләр, бикле ишек кенә чынбарлыкка кайтара. Әти дә юк инде, әни дә...

...Шәһәрне кабул итә алмаган әни, кыш чыгарга шәһәргә килсә дә, кара көзгәчә авылда – Байсарда, үз өендә яшәде. Иртән көтү киткәнне карап кала. Чаңгы таякларына таянып (файдасы бар, дип, без өйрәткәч соң!..) ишегалларын урый. Алма-чияләр өлгергәнгә куана. Һәм... көтә. Безнең телефоннан шалтыратуларны, атна ахырында кайтып килүләребезне... Тагын бер бик якын кешесе бар әле: үзен карарга килүче социаль хезмәткәрРитаның килүен иртәдән көтә башлый. Ул килеп керсә, сабый бала кебек шатлана...

Үткән көз авылдан и китәсе килмәде инде. «Берүзеңне генә калдырмыйбыз», дигәч, «Нишләп берүзем булыйм?! Рита бар, күршеләр бар!..» – дип и тартышты, и түкте күз яшьләрен. Туган авылын сагынып елап утырулары, әйберләрен бер алып, бер салып барлаулары, «бүген кайтып китәбезме әллә?» дип, «әйе» сүзен ишетергә теләп, бала-чага кебек арттан ияреп йөрүләре... Ат белән, юк, җәяүләп тә кайтырга риза иде, ахрысы, әни. Андый чакларда, сагынуын басмакчы булып, авылдашларның, күршеләрнең телефонын җыеп, әнигә тоттырам, юансын, ичмасам. Уңъяк күршеләр Луиза белән Эдуард, Фирдәвес хатыны Рәйсә, Рәүхәт абый кызлары, яраткан Ритасы, югары очтан Разияттәйләр... Хәл-әхвәл сорашуларын ишетүгә үк йөзләрен күргәндәй булам. Кара, аларның һәркайсы үзе бер образ, әдәби әсәр прототибы булырлык персонажлар лабаса!

Кайттык... Һәм ул әни белән соңгы кайтуыбыз булган икән.

Үз өендә, үз бүлмәсендә җаны тынычлап калды, «и тәмләп йокладым инде» дип сөенде. Чайкалачайкала, бәләкәй гәүдәсен чак сөйрәп, без кочаклаган хәлдә, ул сары тузганаклар сибелгән ямь-яшел ишегалдыннан атлады. Кошлар сайравыннан, кәккүк кычкыруыннан, кояш җылысыннан йөзенә канәгатьлек кунган иде. Егылып китмәс өчен, үзе утырган имән бүкәнгә арык куллары белән ныклап тотынды. «Тормышның койрыгына ничек тә ябышып калырга тырышырмын», – дигән була. Сорап алып, бер чүмеч үзебезнең кое суын эчте, «Тәмле!» – ди. Шунда күрше кызы кечкенә Зилә йөгереп керде. И сөенүләре әнинең! Авылына кайтуын аңлады. Берәмтекләп күршеләрне, кардәш-ыруны барлап чыкты. Инде өзелгәндә, соңгы сулышын алганда да алар янында булдылар.

*Их, озаграк тоткарланасы иде туган җирдә!..*

### *Күршеләр*

Эльза, Клара, Рита, Эльвира, Светлана, Риммалар... Шул исемнәр безнең Актаныш якларны сата да җибәрә инде! Безнең өчен иң якыны – Илфак абый белән Халидә апа малае Эдуард, аның хатыны Луиза, әлбәттә. Алар яшьләр әле. Ә ничек шәп итеп дөнья көтәләр! Кулларыннан килмәгән эш юк! Безнең өйгә дә күз-колак алар. Әни каян эшен табып торадыр, көнгә кырыкмаса-кырык йомыш белән Эдуардка эндәшә. Әле телевизоры күрсәтми икән, әле йозакның ачкычы борылмый, ди. «Чалгы белән кычытканнарны чабып чыкчәле, үскәнем», «Яңгыр суын җыярга мичкәне җайлап куймассың микән?», «Он капчыгын келәткә кертәсе иде»...

Бер карусыз үти бит йомышларын Эдуард: «ярар», «хәзер» дип кенә тора...

Хатыны Луиза исә безнең финанс-икътисад операцияләрен башкара: газга, электрга, телефонга түләп бара. Кара чәчле чибәр һәм горур Луиза кыяфәте белән итальян хатын-кызлары кебек. Үзе сабырсалмак. Тавышына бераз гаҗәпләнү чыгарып, акрын гына, сузып кына сөйләргә ярата.

– Мунча ягып тора күрмәгез, безнеке инде әзер. Беренче булып сез барыгыз әле. Мәтрүшкәле пиннек тә пешереп куйдым, – дип, ул кунакка чакыра.

Кышкы кичтә төнгә каршы озын ерак юлдан кайтып керүгә – капка төпләре көрәлгән, өебез җылытылган, алай гынамы, яран гөлләр шау чәчәктә утыра! Ул да булмый, телефон шалтырый: Луиза! «Юлдан кайткан төшкә чәй эчеп чыкмаска әллә!» – дип, табынга дәшә.

PRESSA.RU



Икенче як күршебез – зәңгәр күзле, сары чәчле, бантик иренле, җырчы Валерияга охшаган Лилия – Луизаның капма-каршысы: тиз-тиз сөйли. Салпы якка салам кыстырып, мактау сүзләрен дә җәлләп тормый. Бер баласын күтәреп, икенчесен җитәкләп урамнан узышлый сәлам бирергә туктала:

– И сагындык! Кичтән Рөстәм утыгызны күреп, сөенеп кергән, кайтканнар, ди... Чәй эчәргә керегез, яме, кич утырырга... – дип тезә генә...

*Шәһәргә килгәч тә җанына урын табалмый бәргәләнде.*

### Министр Әлфиясе

Без – бер очтан, Югары очлар. Әлфия дә, абыйсы, эне-сеңелләре дә авыл халкы өчен – министр балалары. Әниләрнең: «Министр балалары «биш»кә генә укый!», «Министрныкылар эшкә булган!» дигән мактау сүзләрен ишетеп, алардан бераз көнләшеп тә куябыз. Кич кинога чыгармасалар, «Министр Әлфиясе дә төшә клубка» дип, әти-әнине йомшартабыз... Берчак эштә, Түбән Камадан классташың Әлфия шалтыратты, диләр. «Ә-әә, министр кызы Әлфия булган инде ул», – дип әйтүем булды, күзләре маңгайга менде: «Ничек? Нинди министр? Сезнең авылда министр да бар идемени?» – диләр. Авылда өч Миркасыйм булып, һәркайсының үз кушаматы барын аңлатып бирдем инде. Хәзер дә «министрлар тыкрыгындагы колонкага суга бардым», «министр малайлары кайткан, машиналары тора», – дип сөйләшәләр. Бездә инде ул кушаматлар! «Алка әби җеннәре» дисеңме, «Тәтәй чебеннәр»ме, «Төлке Өлфәт», «Чыт-чыт Кәримә», «Бүре Рафак»лар тагын...

Ә министр Әлфиясе, әнинең хәлен сорашып, әле авылдан, әле Түбән Камасыннан шалтырата. Бөтен яңалыкны ул белә, бөтен хәбәрне ул җиткерә. Мин... авыл хәлләрен сорашып, Түбән Каманы җыям. Париж аша Мамадышка кебегрәк килеп чыга инде, ягъни мәсәлән. Кем бәрәңге бакчасын әйбәтрәк сөрә? Колорадо коңгызын ничек бетерергә? Уфа–Казан автобусы сәгать ничәдә китә? Әлем ипиен кайчан китерәләр дә, Яркәйнекен кайчан? Чып-чын белешмәләр бюросы, билләһи! Кемнең сыеры югалган, кемгә читтән кунаклар кайткан, иртәгә һава торышы ничек була – барысын да белә Әлфия. Авылга кайткан чагына эләксәң, бәхет баса! Аптыраулы хәлләрдән чыгарырга «Скорая помощь» – Әлфия килеп җитә.

### Ипле бала

Ританы белмәгән кеше юк бездә! Гаиләсе белән Башкортстаннан күчеп килделәр дә, авылдашка әйләнде дә куйды. Карт-корының телендә гел шул гына: бигрәк җайлы, ипле бала, диләр. Рита аз гына тоткарланса да, пошаманга төшәләр, көяләнә башлыйлар. Ул аларга һава кебек, су кебек кирәк. Көйләп, йомшак кына әйткән сүзләре иркәләгән кебек яңгырый аның. Рита үзләре диалектында сөйләшә шулай. «Утырың, ятың, керең, ашаң», дип. Кара, безнеңчә, «утыр, ят, кер, аша», дисә, боерык кебек катырак яңгырар иде әле! Ә болайРитаның сөйләме җырлап тора! Ялгыз әби-бабайларның идәннәрен дә юа, ашарга да әзерли, дарулар да алып кайта, кибеттән кирәк-ярагын да алып керә, кышын карлар көрәп, сукмагын да сала... Тәрәзә пәрдәләрен өенә алып кайтып машинасында әйләндереп ала да, элеп тә китә, диләр. Көне сәгатьләп кенә түгел, минутлап бүленгән. Югары очтан Түбән очка, Ындыр артыннан Урта җыен урамына, Ахун очына... Көн саен велосипедта уза торган маршруты шундый аның. Капка бикле булса – койма аша сикерә, хәлләре авыраеп китсә, тәвәккәлләп, үзе беренче медицина ярдәмен күрсәтә...

### Выжт кына Рәйсә килә...

Әнигә көн саен шалтыратып торабыз. Ә бер көнне... юк, алмый телефонны! Күңелгә шом керә. Бәрәңге рәтләре арасында егылып ятмасын тагын! Берәр җиргә киткәннәрме – күршеләрнең телефоны да җавап бирми. Кем килеп китә алыр? Ә-ә, менә Рәйсәнең телефонын язып куйганбыз икән.

– Хәзер сәпит белән выжт кына урап кайтам! – ди Рәйсәбез.

Ун минут та үтмәгәндер, үзе безне җыя. «Капкагыз бикле, күршеләр ихатасы аша кердем... – еш-еш сулавыннан ашыгып атлавын чамалау кыен түгел. – Ишек тә бикле, шакыйм – ачучы юк... – ян капка шыгырдаганы ишетелә. – Тәрәзәгә килдем, диванда ятканы күренә». Тәрәзәне нык итеп шакырга кушып, үзебез өй телефонына шалтыратуга күчәбез. Чөнки телефон әни яткан бүлмәдә. Карап торсаң, кызык тамашадыр инде бу. Ләкин безгә бер дә көлке түгел. Рәйсәнең, «Роза апау-у!» дип кычкыра-кычкыра, тәрәзә пыяласын зеңгелдәткәне ишетелә, өйдәге телефон сигналы бөтен өйгә яңгырап тора. «Селкенми дә...» – дип, Рәйсә сөрән сала. Без пошаманда. «Ныграк бәр, колакка каты ул», – дибез дә бит, ләкин ул дөбердәтүләр болай да Казанга тикле ишетелә! Ниһаять!..

«Булды! Уянды! Аяк-куллары кыймылдый!» – дип кычкырып җибәрә Рәйсә.

### Сәлимә апа

Спортчылар кебек зифа буй-сынлы, үзе джинсыдан, кроссовкадан... Велосипедына атланган булыр. Монысы – Сәлимә апа, минем укытучым. (Яңа институт тәмамлап килгән кызны заманында безнең унынчы «А»га класс җитәкчесе итеп билгеләгәннәр иде. Математика укытучыбыз матайда да чаба, гармунда да сыздыра, фотога да төшерә, волейбол да уйный, походларга да алып чыгып китә...) Ул һаман яшь, тиктормас, әллә нәрсәләр оештыра, уйлап чыгара, бөтенесен авызына каратып тора. Кышын – чаңгыда, җәен – җәяүләп йә йөгереп, оча гына! Чаңгы, йөзү ярышларында ул район чемпионы булган кеше. Авыл үзешчәннәре куйган спектакльләрдә гел баш рольләрдә. Сәлимә апа –

дөнья кешесе: Мисыр, Төркия, Болгария, Югославия, Германиялəрдəн төшереп кайткан фотоларын күрсəң!.. Əнə, велосипедына атланып килеп керде. (Кара, монда барысы да велосипедта!) Ноутбугын да алган, үзе пешергəн балан бəлешен дə төреп тыккан, догалыкларын да онытмаган... Əнинең хəлен белергə керүе. Бер уңайдан, мəктəптə үткəн «Укытучылар бəйрəме»н видеодан күрсəтмəкче. «Анда Роза апа да бар иде бит», ди. Аның артыннан ук Римма килеп керде (ул да ялга чыккан укытучы). Анысы чəкчəк күтəреп килгəн. Туйларга Римма пешерə чəкчəкне дип ишеткəнем бар иде шул. Бераз сөйлəшеп, чəйлəп утыргач, «Озакламый көтү кайта, сыер савасым бар», – дип, Римма алданрак кузгалды. Миңа аларның сөйлəшүе кызык тоелды. «Ярар, клубта күрешкəнчегə кадəр» дип саубуллаштылар. Җиңү бəйрəменə концерт куячаклар икəн, кич репетициягə җыелалар, ди.

Əнинең хəле авыраеп бара. Сəлимə апа... «Йəсин» сүрəсен укый. Ул авыруга җиңеллек китерə, ди. Тернəклəнеп китəсе булсаң да, соңгы сулышыңны алганда да...

### *Бəхиллəшү*

Берничə көннəн əни бизгəк тоткан кебек дер-дер калтырый башлады. Əлфиянең авылда чагы иде, аны чакырдым. Больницадан ул арада Филүзə килеп җитте. «Түз, Роза апа, түз, хəзер авыртуы узар», – дип, йомшак кына сөеп-сыйпап, укол ясады. Үтеп китте кебек тə... Филүзə, əнə, ни булса да əзер булып торыгыз, ди бит əле. Сагая калдык. Ул-бу була калса, дип, Əлфия белəн шыпырт кына кəфенлеген əзерлəп куйдык. Үзебез бертуктаусыз «лə иләһə иллə Аллаһу» дип кабатлыйбыз...

Күршелəр керə-чыга, авылдашлар килə. Əни хəл эчендə ята. Шунда могҗиза булдымыни! Əбилəрен карап кайтышлый, хəл белергə кергəн Ританы күреп, сөенечтəн əнинең күзлəренə җан керде, зəгыйфь кенə елмайгандай итте. «Ашаң, эчең» дия-дия, Рита җайлап кына шулпасын да, чəен дə эчерде. (Ул чагында соңгы капкан ризыгы Рита кулыннан буласын кем белгəн?)

Икенче көнне əни үлем исереклеге белəн йоклый иде инде. Кулларын сыйпауга, чытырдатып, бар көченə кулымны кысып тотты! Тормышның койрыгына ябышуы шушымы əллə? Чак ычкындырып, мендəрен җайлыйм. Сулыш алулары ук əллə ничек, авыр... Инде кызлары, оныклары, сеңлесе кайтып өлгерде, туганнары күреп чыкты. Эшлəнəсе эшлəр дə бетте кебек: бəрəңгелəр утыртылды, тəрəзəлəр юылды, дөнья чистарып калды. Ишегалдына бер рəт итеп кызыл лалəлəр утыртып киткəннəр. Май бəйрəмнəренə кайткач кына абайладык шуны. Кемнəр утырткан икəн? Луизамы, Лилияме? Əллə Рəйсəме? Əлфия түгелдер бит? Мөгаен, Ритадыр əле... Юк, берсе дə булып чыкмады. Иясе табылмады. «Изге кешенең күңелен күрергə телəгəн игелекле җаннардыр», – диделəр...

Əни дə канəгатьтер, ул да тынычлап калгандыр... Тик күзлəрен генə һаман ачмый... Хушлашырга керүчелəрнең бүген инде соңгыларын озатып, ишегалдына чыгабыз.

Җылы җомга киче. Сеңлем йолдызлы күктəге тулган айга карап, гаҗəпкə калган: кара əле, ай бик сəер, уртадан өзелгəн кебек, ди. Йөрəк жу итте: əни өзелергəме? Уйларымны кычкырып əйтмəдем.

Өйдə əни ята. Чү, сулыш алуы сирəгəя, тоныклана түгелме?.. Бер генə мизгелгə күзлəрен ачып ала – ике күзеннəн ике тамчы яшь бөртеге тəгəрəп төшə дə, əни тынып кала... Ə урамда коеп, бар дөньясын күмəрдəй булып, яңгыр ява. Табигать тə елый икəн.

*Соңгы сулышын алганда да авылдашлары янында булды.*

...Тагын тизрəк кайтырга дип, кояш баер алдыннан гына юлга җыенам. Чү! Ə Сөн? Аның əрəмəлəре?.. Күрмичə китү гөнаһ булыр! Ашыга-ашыга фотога төшерəбез. Əнə – тишкəлəнеп беткəн яр, карлыгач оялары, түгəрəк күл, сары төнбоеклары... Менə – Сөн буе камышлары... Берəр чит илгə барып чыксаң, шундый җирлəрне ушыбыз китеп карап йөрер идек əле. Кайткач, авыз суларыбызны корытып сөйлəр идек... Аларда – чип-чиста һава, дип... Анда – аккошлар, торналар оя корган, дип... Бакалар экологик чиста җирдə генə яши, дип...

Кузгалдык. Кызганыч, Кызыл ярлар, Чəүкə таулары кадрга элəкмəде. Тегермəн колагы да, Тимер тырнак əрəмəсе дə... Тагын кайтмый булмый инде!

...Машина салонына җилəк, мəтрүшкə исе таралган. Мин, туган як һавасы исен төяп, авылымнан китеп барам. Кабат кайтырга дип китеп барам...





Бохарадагы иң биек Калән манарасын Бако исемле оста төзегән, аның исеме диварга уелып язылган...

# БОХАРАНЫ КҮРЕРГӘ ҺӘМ...



Рәмзия КАШАПОВА

## БОХАРА – ҮЗӘК АЗИЯНЕҢ ИСКИТКЕЧ ГҮЗӘЛ БОРЫНГЫ ШӘҺӘРЛӘРЕННӘН БЕРСЕ.

**Җир йөзендә инде ул өч мең елга якын яши. Үз дәверендә күчмә басып алучыларның атлы гаскәре ташкынын да, шәрык ренессансының моңарчы күрелмәгән чайпалышын да кичергән. Һәр чор, династия һәм идарәче бу борынгы җирдә үз эзен калдырган.**

Борынгы заманнарда Бохара (үзбәкчә Buxoro) Урта Азиянең бер өлкәсе – Согда составына кергән. Александр Македонский чорында анда шәһәр төзелеше алга киткән. Исеменең килеп чыгышын төрлечә аңлаталар. Берәүләр фикеренчә, «Бохара» – «монастырь» мәгънәсендә; икенчеләр «белем-мәгърифәт урыны» дип тәрҗемә итә. «Парижны күрергә һәм үләргә...» дигән мәгълүм гыйбарәне мин, «Бохараны күрергә һәм дөньяга күзләреңне ачарга...» дип, бераз үзгәртер идем.

Бохарада дустым Нурия белән мине милләттәшебез, сөйкемле егет Равил Исхаков каршы алды. Ул Ташкент дәүләт университетының халыкара мөнәсәбәтләр факультетын тәмамлаган, быелдан Бохарада яшәүче татарларның иҗтимагый оешмасын җитәкли. Кунакханәгә озата барганда, Равил безгә гид булырга ризалыгын белдерде. Шәһәрнең тарихи үзәгендә, Ляби-хауз архитектур ансамбле янындагы кунакханәгә урнаштык, ул тирәләр Бохарада бүгенге көнгәчә сакланган буалар (хаузлар) исеме белән шулай йөртелә. Сүз уңаеннан, Бохарада һәм Сәмәркандта кунакханәләр кыйммәт түгел, ә менә Ташкентта 10-30 процентка кыйбатрак.

Хаузлар тарихын да Равил сөйләде. XIX йөз ахырына кадәр Бохарада күлләр бик күп булган, алар шәһәр халкы өчен су чыганагы хезмәтен үтәгән. Акмый торган сулыкларда микроблар һәм паразитлар мыжлап торган, буаның яманаты да таралган: ул чир чыганагына әйләнгән. Шуңа күрә хаузларны әкренләп киптерә башлаганнар. Ляби-хауз XVI–XVII гасырларның гаҗәеп архитектура ансамбле үзәге буларак сакланып калган һәм шул көннәрдән бирле үзгәрмәгән дә. Урта гасырларда җирле халык, цирюльникларга (алар дәвачылар да булган) мөрәҗәгать итеп, паразит-

*Бөек ефәк юлы Бохара аша үткән. Андагы 60 лап кәрван-сарайга Һиндстан, Кытай, Иран һәм башка илләрнең сәүдәгәрләре урнашкан.*



PRESSA.RU





■ Кышкы сарайны Фрунзе җитәкчелегендә солдатлар пушкалардан утка тоткан. Аркның 80 процент кышкы резиденциясе юкка чыгарылган.

■ Борынгы Бохараның базарлары затлы мал – келәмнәр, керамик савыт-саба, җиз табаклар, бизәкле комганнар муллыгы белән генә түгел, бәлки бу тауарлар белән сәүдә итүчеләрнең һәр туристка аның үз телендә (!) мөрәҗәгать итүләре белән дә хәйран калдыра.



лардан арынган. Ул дәвалаучылар кортларны тире астыннан нечкә таякчыклар ярдәмендә эләктереп алган. Кортлар кеше организмында күпчелек аяк тиресе астында күпләп үрчегән. Алардан арындыру берничә сәгатьтән алып тәүлек буена кадәр дәвам иткән. Бу эшне бик сак башкарганнар, юкса корт өзелеп, кан зарарланудан кеше үлеп киткән очраклар да булган. XIX гасырда суны тикшергәннән соң, акмый торган сулыклардан файдалануны тыйганнар, хакимияттәгеләр ашыгыч рәвештә күлләрне күмдерә башлаган, бердәнбер Ляби-хауз гына калган. Чишмә, елга суларын эчүгә күчкәннәр.

*Бохараның илаһи манаралары каршында хәтта бөек Чыңгызхан башын игән...*

Монголлар басып алуы турында Равил сөйләгәннәрне тыңлый-тыңлый, шәһәр белән танышып йөргәннән соң, кунакханәгә әйләнеп кайттык: Бохарада яшәүче милләттәшләребез белән очрашасыбыз бар иде. Кызы Әлфия белән Дания ханым Янбулатова, Рузалия Алимова килгәннәр. Чәй эчә-эчә, аларның язмышы, безнең халыкка хас сыйфатлар турында рәхәтләнеп сөйләштек.

Иртән тагын әкияти Бохара белән танышуыбызны дәвам иттек. 603–658 елларда ул Көнбатыш төрки каганатына буйсынган Согда биләмәләренең берсе булган. Шул заманда ук инде борынгы болгар бабаларыбыз Бохара ханлыгы белән сәүдә иткән. Бохара, Хива ханлыклары соңрак Казан ханлыгы белән сәүдә мөнәсәбәтләре урнаштырган.

Бохара Әмирлеге 1785 елдан 1920 елга кадәр яшәгән, аннары аны Кызыл Армия гаскәрләре басып алган. Үзбәкстан хөкүмәте бүгенге көнгә кадәр сарай комплексын чистарту, мәетләрне казып алу эшенә тотынмаган әле, хәрабәләр күңелне борчый.

Бохараның үзәге – ачык һавадагы музей комплексы ул. Анда йөргәндә шактый кызыклы мәгълүматлар ачыкланды. Әйтик, 1220 елда Бохараны Чыңгызхан гаскәрләре басып алган. Ул, атка атланып, шәһәрнең Җәмигъ мәчетенә килеп кергән. Риваятьләр буенча, Бохараны яулап алганнан соң, Чыңгызхан Калән манарасына килгән (биеклеге 47 метр), башын шундый итеп артка чөйгән: сугышчан шлемы төшеп киткән хәтта! Җир йөзеннән бик күп шәһәрләрне себереп түгеп, дөньяны дер селкеткән Чыңгызхан, көтмәгәндә, такыр башын күрсәтергә мәҗбүр иткән манарага тимәскә дигән әмер биргән гаскәренә.

Калән манарасы атаклы Мири-Араб мәдрәсәсенә якын гына. Безнең мөфтиләр Тәлгать Таҗетдин, Равил Гайнетдиннәр дә шушы югары уку йортында белем алганнар. Аның эченә кертмиләр, дәресләр барганда бигрәк тә. Меңнәрчә чакрым ара үтеп, шундый атаклы һәм изге урыннарны күрмичә ничек китәсең инде! Минем үҗәтлекне күреп, бер хәзрәт Шәех Абдулла Йәмән мәдрәсәсенә нигез салучының мавзолеена чакырды һәм Коръән укыды, үземә шундый игътибар күрсәтелүенә бик рәхмәтле булып калдым. Хәеремне бирдем, догаларыбыз кабул булсын. Амин.

Риваятьләр буенча, төзелеш икенче талпынышта гына килеп чыга: беренче архитекторны хан ашыктырып эшләтә, ашык-пошык күтәрелгән манара 1121 елда җимерелә, моның өчен архитекторның башын кисәләр. Ә Бако хәйләкәррәк булып чыга, кирәк чакта (мәсәлән, измәне катырганда) билгесез тарафларда югалып тора. Гомумән, Калән турындагы риваятьләр берсеннән-берсе куркынычрак: аны Үлем манарасы дип тә йөртәләр; янәсе, халыкка гыйбрәт булсын өчен, Бохарада җәза бирелгән җинаятьчеләрне манарадан халыкның аяк астына ыргытканнар. Манараның гөмбәзе авыр таҗлы хан башын хәтерләтә...



Бохара укалы чигүләре белән дан тоткан. Кулдан чигелгән бу күлмәкнең инде 200 елдан артык тарихы бар...



Икенче көнне Бохара читенә Баһаветдин Нәкышбәнди мавзолеена бардык. Баһаветдин 1318 елда Бохара янындагы Касри-Хиндуван авылында туа. Суфичылык белән кызыксыну аңа бабасыннан күчкән. Инде дин әһеле булып киткәч, Нәкышбәнди үз вәгазьләрендә гадилекне, тыйнаклыкны хуплаган, дәгъвачыл булмаска чакырган, әмма ялгызлыкны, үз дөньяңа бикләнүне кире каккан. Баһаветдин дәрвишләрнең яшәү рәвешен кабул итми, хәер эстәп, теләнеп йөрүләр аңа ят була, ул башаяк белән тормыш чынбарлыгында яши. Бик оста итеп «камха» ефәк тукымасын тукый, металлдан кисеп, бизәкләр ясый (Нәкышбәнди исеме дә шуннан килеп чыккан). Аның тәгълиматы буенча, чын суфи сөннәтне үтәргә, шәригать кануннары буенча яшәргә тиеш. Мавзолейда чакта мин татар галимнәре Мәрҗани, Барудиларның да аның тарафдарлары булуын белдем.

Баһаветдин Нәкышбәндинең мавзолее ун гектар мәйданны били. Әмма халык аның күбрәк бер урынында – тут агачы тирәсендә кайнаша. Риваятьләр буенча, Нәкышбәнди хаҗга таянып барган таягын, кире әйләнеп кайткач, җиргә кадый һәм шул урында тут агачы үсеп чыга... Ул агач күптән инде җиргә ауган, әмма аның шифасы бүгенгәчә бар дип санала: һәркем үзе белән аның бер кисәген алып китәргә тырыша. Шулай итеп, бәхетле булмакчылар... Әлеге риваять: «Агачны бары тик кулың белән сындырып алырга гына ярый», – дип тә кисәтә. Әмма моны эшләү генә мөмкин түгел – дәверләр кичкән тут агачы күптән инде ташка әйләнгән.

Бохарага килгән туристлар мавзолей эчендәге Изге чишмә янында да тукталырга тырыша. Мин дә ул чишмәдән әнием белән кызыма дип изге су алып кайттым. Бохара әле тагын бер атаклы персонаж, урта гасырларның мәгълүм сатиригы Хуҗа Насретдин исеме белән дә танылган. Ляби-хауз янында аңа бронзадан һәйкәл куйганнар. Бохара – Хуҗа Насретдинның ватаны, биредә аны бик яраталар.

*Җирле халык кына түгел, бөтен мөселман дөньясы Нәкышбәнди мавзолеен изге урын саный.*

Укалап чигү осталары һәм зәркәнчеләре белән дә мактана ала Бохара. Һәр тарафта – муенсалар, алкалар, беләзекләр, саклагыч бөтиләр... «Панча», ягъни биш бармакны хәтерләткән Бохара алкалары бик популяр. Ул вак ташлар белән мулдан бизәлгән, башның һәр хәрәкәте саен ниндидер саңгырау нәфис тавыш чыгарып, явыз көчләрне куа, чиста уйлар белән күңелне яктырта.



Нәкышбәндинең таягы төрткән урында үсеп чыккан тут агачына бу гомер эчендә кемнәр генә баш имгән: ханнар, шәехләр, дәрвишләр, юлчылар...

PRESSA.RU





Хуҗа Насретдин ишәгенең койрыгын сыйпасаң, бар теләкләрең тормышка ашачак, син кабат шушы әкияти музей-шәһәргә әйләнеп кайтачаксың, диләр.



Хаммам тәннәребезне генә түгел, җаннарыбызны да сафландырды.

*Хаммам-мунчалар Урта Азиядә аеруча киң таралган. Алар шәһәр үзәгендәге сарай комплекслары һәм җәмәгать биналары эчендә төзелә.*

Алтын базарында без Мәъмүр Рахмоновның «шибирма» стилендә эшләнеп, энҗеләр белән әйләндерелгән якут алкаларын сатып алдык – чыпчын Бохара зәркән мәктәбе үрнәге! Ташкентта исә безнең алкаларга карап, шундук кемнеке икәнен, ягъни авторын атадылар. Менә бит чын останың кулын ничек таныйлар!

Сәяхәтебез ахырында Нурия белән XVI гасыр мунчасына барырга булдык. «Великолепный век» фильмын күпләрегез карагандыр. Хәтерләсәгез, фильмда еш кына солтан хатыны Хөррәмнең мунча – хаммам керүләрен күрсәтәләр иде. Без дә үзебезне солтан хатыннары кебек хис иттек. Фильмдагы декорацияләр фонында калып, урта гасырларга килеп эләккәндәй булдык...



Телебез, гореф-гадәтләребез сагында торучы татарларыбыз белән Шәрыкның борынгы шәһәрендә аралашу бик күңелле иде!

X гасырда Бохарада берничә мунча булган, арада «Хаммам хан» («Хан мунчасы») дигәне – иң билгелесе. Ул бүгенгәчә сакланып калган хаммамнарның берсе. Башка Урта Азия мунчалары кебек үк гөмбәз түбәле бер катлы бинада урнашкан. Ул вестибюльдән, чишенү, юыну бүлмәләреннән тора. Хаммамның алгы бүлмәсенә керүгә үк үткән заманнарга күчәсең...

Сөрмәле күзләрен сирпеп, зифа буйлы шәрык сылулары каршы ала сине. Фарсыча сөйләшәләр, сәламлиләр, хуш исле тәмле үлән чәе тәкъдим итәләр.

Без анда чакта мунчага әниле-кызлы берәүләр килде. Әни кеше күптән түгел генә бала тудырган. Бәби табып, 40 көн узгач, хатыннар, организмны савыктыру өчен, хаммамга килә икән. Барлык процедураларны узганнан соң, бәби тапкан хатынга җиде төрле үләннән пешерелгән чәй эчерәләр. Бала таба алмый интеккән хатыннар өчен дә мунчада аерым процедуралар бар икән... Көнчыгыш мунчасының төп аермасы – ул тоташ таштан һәм мәрмәрдән салынган.

Үзбәкстанда кешеләр ачык, кунакчыл, аралашырга бик ярата. Кунакханәләрдә хезмәт күрсәтүчеләр, сатучылар, берничә телдә сөйләшүче официантлар шаккаттырды.

Бохарадагы милләттәшләребез безне озатып калды. Яшермим: ниндидер буталчык хисләр белән кайтып киттек. Урта Азия, борынгы Шәрык белән элемтәләр өзелүгә эчтән янсак, әмирләр, ханнар, дәрвишләр һәм суфыйлар рухы сакланган Бохарага килеп, мәңгелек тарих белән очраша алуыбызга без чиксез шат идек.



РӘХМӘТУЛЛИНА Нәсимә

Самара дәүләт техник университеты (1983)

Ике ул әнисе.

Хуҗабикә.

Тормыш шигаре: Беркайчан да күңел төшенкелегенә бирелмим, һәрвакыт киләчәккә өмет белән карыйм.

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

### Сөенеч: артабыз!

Ике улыбыз да башлы-күзле булып, үз гаиләләре белән яши башлады. Ирем Арслан белән безнең икебезне бәхетле әби-бабай итеп, бер-бер артлы оныкларыбыз туды. Олы улыбыз Русланның – Кәрим белән Ислам исемле, кече улыбыз Марсельнең Әким исемле малайлары бар.
Ә шушы көннәрдә исә Марсель белән киленебез Динара тагын бер балалары туачагын әйтеп шатландырды.
Тагын бер онык! Безнең өчен моннан да зуррак сөенеч була аламы?! Бәхет шушы инде ул...


### Ураза – тиңе булмаган гыйбадәт


Быел Рамазан ае җәйгә – иң озын көннәргә туры килсә дә, мөселманнар өчен Ходай җиңеллеген бирде: кояш артык кыздырмады, яңгырлар яуды. Казанда да бик күпләр шушы изге айда ураза тотты, бергә-бергә ифтарларга йөрде. Шөкер, ураза тотучылар дус-танышлар арасында да елдан-ел арта бара. Шуңа да Ураза гаетен дә бик күңелле итеп каршы алдык, бик матур итеп үткәреп җибәрдек. Бергә-бергә бәйрәм итүнең рәхәте дә күбрәк була икән. Күңелләр сафланып, рухлар чистарынып калды.

### Спорт яшәү рәвешенә әйләнә

Бу көннәрдә Казан буйлап күп йөрергә туры килде. Казан чиста, матур итеп бизәлгән. Конфедерация кубогы уеннарын карарга килүчеләр дә моңа игътибар иткәндер, аларга да ошагандыр калабыз. Иң мөһиме: шәһәр белән бергә үзебез дә үзгәрәбез. Купшы сүзләр генә түгел бу: элек паркларга чыксак, анда сыра эчеп, теләсә ничек кәеф-сафа корып утыручыларны очратмый калмый идек. Хәзер исә андагы халык бар да спорт белән шөгыльләнә, велосипедта, роликларда йөри, гимнастика ясый.

сөендерде





көендерде



сөендерде






көендерде



сөендерде





көендерде



### Оныклар туган телдә сөйләшмиләр

Оныклар кечкенә чакта алар белән бары тик туган телдә генә сөйләшергә тырыштык. Өйрәнделәр – телләре татарча ачылды. Әмма бусаганы атлап чыгуга, рус телен шулкадәр тиз арада үзләштерделәр, шаккатарсың. Өстәвенә, балалар бакчасында татар төркеменә дә эләгә алмадык. Хәзер өйгә кайткач, татарча сораган сорауга да русча җавап кайтаралар. Гомумән, татар телендә көннән-көн азрак сөйләшәләр. Алар туган телне онытмасын өчен ничек берәр әмәлен табарга, белмим.

### Бәйрәм көткәндә...

Көтеп алган җәйдә күңелләр сагынышып очрашуларга корып куелган мәлдә, бәйрәмнәрнең ямьле, аллы-гөлле сөлгеле, җыр-биюле фонына кинәт килгән, көтелмәгән кайгылар килеп керде. Илнең әле бер төбәгендә, әле икенчесендә машина һәлакәтләре яки гарасатлар булып тора. Мәскәү давылы тынарга да өлгермәде, Зәй янындагы автобус һәлакәте турындагы хәбәр аяктан екты. Сабантуй мәйданнары мәтам тынлыгында калды. Күрергә язмасын. Күргәннәргә күркәм сабырлык бирсен.

### Онытырга хакыбыз бармы соң?!

Польшада совет сугышчыларына куелган һәйкәлләрне сүтү турында карар чыккан икән. Дөнья халкы өчен Икенче Бөтендөнья сугышы дип аталса да, безнең өчен Бөек Ватан сугышы бит ул! Бик күп корбаннарны үзенә алган, канкойгыч сугышлар булганын беләбез. Бик күпләребезнең ата-бабалары яу кырында ятып калган. Кайбер илләрнең кыска хәтерле булуы, сугыш сабакларын бик тиз онытуы борчый, сискәндерә, сагайта...

PRESSA.RU



16+

# ХАТЫН-КЫЗГА ҮПКӘЛӘРГӘ КИРӘКМИ...



Илдус ГАБДРАХМАНОВ,
Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты;
Татарстанның халык артисты;
гаилә стажы – 18 ел.

**Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...**
**Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.**

**1 Иң элек хатын-кызның Сез нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...**

– Миңа калса, барлык ир-атлар да иң элек хатын-кызга: «О-о, моның фигурасы шәп!» – дип карый. Үзем дә башта күбрәк буй-сынына игътибар итәм. Аннан соң гына күзләрен, чәчләрен күрәм.

**2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?**

– Үземнең хатынны күз алдында тотып җавап бирәм инде... Тик аның бер кимчелеген күрмим! Хатыннар телефоннан күп сөйләшә дияргә мөмкин кемдер. Телефон сөйләшер өчен инде ул. Менә мин үзем уйныйм да әле... Минем хатын телефоннан эш буенча гына сөйләшә. Яңа бию хәрәкәте кирәк булса, Ютубтан биюләр карый еш кына.

**3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?**

– Хыянәт... Ул минем тормышта бер булган иде. Арага өченче берәү керү белән бәйле түгел иде ул. Гайбәткә ышану, кеше сүзен тыңлап, шуны миңа җиткерүне дә хыянәт дип кабул иттем. Шуңа да юлларыбыз ул кеше белән аерылды... Ә Сәлимә белән мондый нәрсә булмас – ышанып әйтә алам! Җүләр атын мактый, татар хатынын мактый, диләр. Тик дөресе шул!

**4 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?**

– Әлбәттә, була ала. Нигә булмасын?! Кайчак шаяртам: мин хатынымның ире дә, сөяркәсе дә, шәхси шоферы да, дим. Без башыннан ук дуслар идек инде. Өйләнешкәнче 7 ел очрашып йөрдек. Бер-беребезне белергә, төрле яктан сынарга өлгердек. Берәр җиргә китсәм, ярты сәгатьтән шалтырата башлый Сәлимә. Үзем дә шулай. Озаграк хәбәре булмаса, ничек хәлләр, дип белешеп алам.

**5 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме?**

– Сәлимә безнең театрга 1992 елда килде. Фәрит Рифкатович аны үзенең курсына бию хәрәкәтләрен өйрәтергә дип чакырды. «Боз астында дулкын» спектаклен куйдык. Эскәмия өстендә бии торган бер бию бар анда һәм аны героиня белән мин биергә тиеш идем. Эскәмия исә бик тар – биюебез килеп чыкмый. Ахырда Сәлимә: «Син үзең генә бие», – диде. Шулай танышып киттек. Аннан «Тагын Казан егетләре», «Биюче»не куярга чакырдылар аны. Бүгенгедәй истә, берсендә театрдан чыктык та, урам буйлап барабыз. Минем туган көн – 27 май алдыннан бу. 25 яшь тула иде. «Театрда гөрләтеп бәйрәм итәбез, килегез», – дим. «Ул көнне минем имтихан», – ди Сәлимә. «Ничек инде минем туган көндә имтихан? Онытыгыз андый нәрсәне!» – дим. Безнең бит бөтен нәрсә эш вакытында бара: гашыйк булганны сизми дә калдым. Уртак эш кавыштырды бугай безне. Загска өч тапкыр гариза бирдек! Беренчесендә гастрольләр комачаулады – Төркиягә чыгып киттек. Икенчесендә тагын нидер килеп чыкты. Өченчесендә генә, ниһаять, язылыша алдык. Мин әлегәчә көләм: «Синең өчен хөкүмәткә күпме калым түләдем!» – дим. Башта ул 3 сум 60 тиен иде бугай, ялгышмасам. Аннан күпкә артты. Сорарга дип Башкортстанга махсус барулар булмады. Без бит совет заманында туган балалар – барып, әти-әнисеннән кыз сорау дигән нәрсәне белми идем дә. Әнисе килгән иде кунакка. Тулай торакта утырдык кичен, шунда сөйләштек инде. Никах та безнең гастроль вакытында Уфада булды. 1999 елның 16 апрелендә. Яз көне, боз киткән чак. Әти-әни урынында Шамил Зиннурович белән Марсель Хәкимович утырдылар. Туйны Казанда үткәрдек. Бөтен театр белән бергә! Сезон ябылган көннәр иде – бәйрәм итәргә сәбәп тә бар. Июнь. Эссе! Табында су бетте... Билгеләп узабыз бу көнне. Онытылган чак та булды бугай. Бер генә тапкыр...

**6 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?**

– Тыныч тотарга тиеш. Мин монда бернинди проблема күрмим. Хатынның күбрәк эшләргә мөмкинлеге бар икән, эшләсен. Минем кебек акыллы ир булса, Аллага шөкер, дип кенә торачак... Бу сорау безгә кагылмый. Үземнән күбрәк алган хатын белән яшәгән юк әле. Ә уен-көлкене

читкә куеп әйткәндә, мөнәсәбәтләр акчага гына бәйле булса, ул гаиләнең гомере озын түгелдер.

**7 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?**

– Әйбәт карыйм. Театрда яшь артистларга тамашачы туташларның хатлар язу гадәте бар инде ул. Өйләнгәнче миңа да язалар иде. Әмма безнең җанатарлар мәскәүләрдән шактый аерыла. Каршыңа чыгып, бәйләнүләр, телефоннан үзеңә, хатыныңа шалтыратулар – боларның берсе дә юк безнең театрда. Артист башлы-күзле булуга хат язудан туктыйлар. Синең гаиләң матур булганга шатланалар да бугай әле.

**8 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?**

– Кемне нәрсәдер... Үземнең хатыннан чыгып әйтә алам: кайчак ул кино артистларына гашыйк була, аларның да чибәрләренә. Дмитрий Дюжев кебекләр ошый аңа. Бу сорауны хатын-кызларның үзләренә бирергә кирәк, әллә театр коридорына чыгып, студент кызларның берәрсен туктатабызмы?

**9 Хатын-кызларның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүен көтәсез?**

– Ә минем начар якларым юк! «Мин матур, мин чибәр, миңа карап туймыйлар», диләрме әле? Әлбәттә, ир-атка үзен формада тотарга кирәк, ә моның өчен гел хәрәкәттә булырга... Эшеңне яратып эшлисең икән, шул вакытта сине яратачаклар, сиңа игътибар итәчәкләр. Миңа карасыннар, күрсеннәр әле дип йөрү, борын күтәрү, үзеңне әллә кем дип санау – йолдызлык чире. Юк, болар миңа хас түгел.

**10 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.**

– Мин акча тота белмим, ә хатыным белә! «Шәхси бухгалтерым», дип атыйм мин аны. Бурычка акча сораучы булса: «Әнә бухгалтерга мөрәҗәгать итегез», – дим... Кайчак кибеткә нидер эзләп чыгабыз шулай. Табабыз кирәк әйберне. «Әйдә, алабыз», – дим мин. «Тукта, өлгерербез, тагын карыйк әле», – ди Сәлимә. Йөреп-йөреп, кире әйләнеп киләбез, ә безнең күз төшкән теге әйберне инде алып киткән булалар... «Нәрсә әйттем мин сиңа, теге вакытта алган булсак, ак сакаллы карт була идек», – дим. Шулай арзанрагын эзләп йөреп, ике тапкыр кыйммәтрәккә дә алган бар. Хәер, аңламаган очрак дип сөйләдем дә, ялгышмасам, бөтен хатын-кызга хас сыйфат бугай бу.

**11 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный.**

– Гадәттә, мин юл куям. Соңрак әйтәм аннары, шулай иде бит дип. Бу вакытта ул инде үзе дә аңлаган була, авызы пешкәч... Хатын-кызга, гомумән, каршы килергә ярамый. Үзе теләгәнчә эшләсен, ялгышканын соңрак барыбер төшенәчәк – акыллы бит ул... Без Сәлимә белән гел киңәшләшеп эшлибез, бер-беребезне аңларга тырышабыз. Ул мине тыңлый, мин – аны. Яңа кавышкан чакларда төрле хәлләр булгалагандыр инде: яшь чакта бит һәркемнең үзен өстен чыгарасы килә. Хәзер инде моңа исебез китми. Кайчакларда мин дә хаксыз булып чыгам – фәрештә түгел бит. Аңлыйм да, гаебемне таныйм. «Әйе, син дөрес әйткәнсең», – димен.

**12 Шундый очракны күзаллыйк әле: ачыгып, арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән...**

– Без бит бергә эшлибез, аның эше нинди җаваплы, катлаулы икәнен аңлыйм. Шуңа күрә ишекне ачып керүгә: «Кайттым! Кайда ашарга?» – дип сорамыйм инде. Өйдә булса, ул барыбер нидер әзерләп куя. Ничек кенә арыган булса да. Пешермәсә дә исем китми, үзем дә булдырам. Күкәй кыздырырга гына кечкенә чакта ук өйрәндек анысы. Ботка пешерә алам тагын. Хәзер бит боткаларны пешерергә бик җайлы: ярмалы пакетны кайнап торган суга салып кына аласы. Ит пешерү дә минем өчен проблема түгел: кирәк икән, кыздырам, кирәк икән, томалап пешерәм. Ризыкка мин, гомумән, талымлы түгел: Сәлимә нәрсә пешерә, алдыма ни куя, шуны ашыйм. Иртәнә ботка, эремчек, йогурт белән башларга мине ул өйрәтте. Өйләнгәнче, иртән торып, өч көн элек пешкән ашны да бик рәхәтләнеп ашый ала идем. Хатын тәртипкә салды... Камыр ризыклары ашамаска тырышабыз – безнең яшьтә алар инде зыянга гына. Тәмәкене ташлагач, 10 килога тазарган идем. Әле «Бию пәрие»н куяр алдыннан өч ай диетага утырып, гел биеп, 6-7 килога кабат ябыктым.

**13 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан...**

– Әйе шул!.. Дулап чыгып китмимм, әмма: «Бегом...» – дип әйткәлим. Башка ир-атлар кебек мин дә: «Менә шул вакытта чыкмасаң, китәм», – дип, алданрак кисәтеп куям. Чаптыртам инде... Машинага чыгып көтеп утырган чаклар да бар. Өлгерми инде, эше күп бит. Ашарга да пешерә, мине дә карый, үзенә дә бизәнергә кирәк.

**14 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә...**

– Сәлимә һәрвакыт миңа кирәкле һәм затлы бүләк кенә ала ул. Ә мин... 8 Март идеме, әллә туган көнеме, анысын хәтерләмим. Яшь чакта, Сәлимә сеңлесе белән тулай торакта яшәгән вакытта әле бу. Шәмәхә төсле атлас йокы күлмәге бүләк иттем мин моңа. Үземә ошады инде... Рәхмәт дип кабул итеп алды, сөенгән дә кебек булды, һәрхәлдә, берни сиздермәде. Соңыннан, инде өйләнешкәч: «И-и, сеңлем белән көлдек шул чакта бүләгеңнән», – дип сөйләде. Хәзер дә еш кына искә төшергәли. «Алай булса, миннән башка бүләк көтмә, менә сиңа акча, үзең ни телисең, шуны ал», – дидем. Сайлый белмим шул... Чит илгә чыккач, вак-төяк алгалыйм, анысы. Оста егетләр бар безнең монда, алар белән киңәшләшәм. Кайчак: «Ал», – диләр, ә кайвакыт: «Интекмә, акчалата гына бир», – диләр. Мин, гадәттә, чәчәкләр алам – ак розалар... Сәбәпсез биргәләргә кирәк тә бит чәчәкләрне. Юк шул, тормыш куабыз, кирәксенмибез, өлгермибез, онытабыз...



Тулысынча сайтыбыздан укыгыз: www.syuyumbike.ru

PRESSA.RU



# МАҢГАЙ ТИРЕ ТҮГЕЛ ӘЛЕ

**«Тирләп пештем! Тирем елга булып ага», – дип зарланганнарын ишетеп йөрисездер. Кайбер кешеләрнең чәч бөртекләренә кадәр тирдән чыланган була. Маңгай тирен әйтеп тә торасы юк инде. Арка буйлап агып төшкән тир, култык төпләрен каралткан юешлек кемнең дә кәефен җибәрер. Гел тирләп йөрүеңнән кыенсынган саен, тир күбрәк бәреп чыга.**



Фото интернеттан алынды

**Тирләү күңелле күренеш түгел... Ничектер бер җаен табарга иде бит... Берәр чарасы бардыр бит инде аның?**

– Тирләүдән арынырга кирәкми дә. Тирләү сулыш алу яки йөрәк тибеше кебек үк табигый процесс. 1-3 мм тирәнлектәге 3 миллионлаган тир бизе организмны артык кызып китүдән саклау өчен көн-төн дым бүлеп тора. Тир, башлыча, маңгайда, биттә, уч төпләрендә, аяк табанында, култык асларында бәреп чыга. Тир белән бергә төрле тозлар да чыга. Мунчага тирләп чистарыну өчен йөрибез түгелме соң инде? Яңадан туган кебек кайтабыз бит мунчадан. Яңарубыз организмдагы чүп-чардан арынганга күрә. Эссе көнне яки физик эштән соң тирләп чыгу да файдалы гына.

**Нигә соң кайбер кешеләр салкынча көнне дә, берninди физик эш эшләмәгән килеш тә тирлиләр?**

Алай да тирләп чыгуның механизмы мәгълүм. Бөтен хикмәт вегетатив нерв системасында. Кеше йөгереп китсә, йөрәге ешрак тибә башлый, адымын акрынайттымы – йөрәк ритмы да басыла төшә. Тир бизләре дә шундый ук принцип белән эшли. Гипергидроз булганда әлеге система эшләми. Нерв үзәкләреннән килә торган импульслар температура белән бәйле булмаган нәрсәләргә, әйтик, курку, борчылу кебек факторларга сизгер була.

**Чамасыз тирләүчән булу кадәресе инде медицина өйрәнә торган проблема. Бу авыру гипергидроз дип атала. Аның чын сәбәпләре хәзергәчә билгесез.**

**Тирләүчәнлек башка берәр авыруның да билгесе булырга мөмкин түгелме?**

– Әлбәттә. Бик җитди чирләр сәбәпче булырга мөмкин. Эчке секреция бизләрендәге тайпылышлар нык тирләүгә китерә.

**Әгәр кеше, нык тирләү өстенә, гел сусап торуга, төнлә ашыйсы килүгә зарлана икән, аны эндокринологка күрсәтергә кирәк.**

Диабет авыруы булуы ихтимал. Күңел болгану, йөрәк тирәсе авыртып тору белән бер үк вакытта кеше тирләп тә чыга икән, аңарда стенокардия яки инфаркт алды халәте дип шикләнергә нигез бар.

Кычынулы дерматозлар вакытында да тир бүленеп чыгу арта. Әгәренки гипергидроз белән бергә йөрәк тә кага башлый, калтырата, күкрәк читлегенең сул ягы авырта икән, невропатолог яки психиатр сагаерга тиеш.

**Сәламәтлеге бер дигән кешеләр дә тирләүдән зарлана бит.**

– Андый очракта сәбәпне тышкы факторлардан эзләргә кирәк. Ихтимал моңа кайбер дарулар сәбәпчедер.

**Баллы һәм газлы сулар урынына гади минераль сулар эчәргә кирәк. Кофе тир бүленеп чыгуны көчәйтә. Шуңа күрә аннан баш тартырга кирәктер.**

Кайбер витаминнар, мәсәлән, Е витамины тирнең исен бетерә, әмма тирләүне киметми.

**Ис дигәннән... Ни өчен уч төбе тирләгәндә берninди ис сизелми, ә менә култык асты тире исле була?**

– Кешедә ике төрле тир бизләре бар. Энкрин бизләр бөтен тән буйлап сибелгән. Алар култык асларында, уч төпләрендә күбрәк. Бу бизләрнең төп бурычы һәртөрле температур үзгәрешләргә сизгерлек күрсәтү.

Апокрин бизләр «эмоциональ климатка» – стрессларга, шатлыкка, авыртуга яки җенси дәрткә сизгер була. Аларны әле тагын «ис бизләре» дип тә йөртәләр.

Чөнки югарыда саналган шартлар туганда, алар махсус матдәләр – исе озакка бара торган феромоннар бүлеп чыгаралар.

**Тир 99 процентка судан тора. Калган 1 процентында натрий, калий, кальций тозлары, сульфатлар, фосфатлар, җиз, марганец, тимер, аминокислоталар, холестерин, стероидлы гормоннар бар.**

Яңа гына тибеп чыккан тирнең исе юк дәрәҗәсендә. Әгәр тиргә каршы чара күрмәсәң, ис озак саклана. Чөнки берничә минут үтүгә безнең тир бизләрендә яши торган сапрофит бактерияләр эшкә керешә. Шушы бактерияләр тирне эшкәртү белән мәшгульләр. Безнең ис сизү әгъзаларын аларның эшкәртү калдыклары һәм изовалериана кислотасы ярсыта.

**Чамасыз тирләүнең кәсәфәтеннән ничек арынырга була соң?**

– Иң гади һәм иң борынгы ысул белән: су һәм сабын ярдәмендә. Тик юыныр өчен җай булмаска мөмкин, аннары юыну нәтиҗәсе дә озакка бармый. Төрле антиперспирантлар отышлырак булыр. Аларның нәтиҗәсе бер-ике сәгатьтән бер атнага кадәр җитә. Аларны куллану да ансат, күбесе зыянлы да түгел.

**Гипергидрозны дәвалауда транквилизаторлар булыша. Алар нерв системасын тынычландыра, ләкин аларны өзлексез эчеп торырга кирәк. Моның организмга зыяны да бар.**

Кайвакыт табиблар култык асларына, аяк табаннарына сөртә торган формалин эремәсен, алюминийның спиртлы эремәсен, танин эремәсен кулланырга тәкъдим итәләр.
Тик болар да тирләүдән вакытлыча гына коткара. Өстәвенә, бу препаратларны даими куллана торгач, аллергия килеп чыгарга да мөмкин.

**Терапия чаралары булышмаганда тирләүчәнлекне хирургия ысулы һәм төрле уколлар ярдәмендә дә дәвалыйлар.**

Гадәттә, гипергидрозны дәвалау өчен эндоскопик операция ысулын кулланалар. Бу иң хәвефсез чара. Соңгы вакытта иң отышлы чара буларак, махсус уколлар тәкъдим ителә. Мондый уколның нәтиҗәсе 4-9 айга җитә.

PRESSA.RU



**Гөлнара САФИНАның үзе белән танышканчы, ул пешергән бәлешләрдән авыз итү насыйп булган иде безгә. Авызда эреп китә торган, искиткеч тәмле иде алар. Болай тәмле итеп пешерергә өйрәнгәнче, Гөлнара бик күп рецептлар сынап караган. «Интернеттагы рецептларга ышанырга ярамый да, күп очракта алар анда нәрсәнедер әйтеп җиткермәгән була. Мин моңа бер генә инанмадым инде», – ди ул үзе. Әнисенең бәлеше пешеп чыкканны бәләкәй Самат чак көтеп җиткерде, чөнки белә ул мичтә нинди тәмле әйбер пешкәнен. Искиткеч тәмле каймак бәлеше пешерү серен Гөлнара журнал укучыларыбызга да бик теләп ача. Аныңча итеп сез дә пешереп карагыз әле, якыннарыгыз аннары гел шуны гына сорап торачак.**



# ЧӘЙ ЯНЫНА – КАЙМАК БӘЛЕШЕ

*Кирәк:*

**камыр өчен**
- 1 йомырка;
- 0,5 стакан шикәр комы;
- 200 г атланмай;
- 2 стакан он (300 грамм);
- 1,5 чәй кашыгы камыр күперткеч (разрыхлитель).

**Эчлек өчен:**
- 500 грамм кибет каймагы (без 20 процентлысын алдык. 15 процентлысы да ярый);
- 4 йомырка;
- 1 чәй кашыгы ванильле шикәр яки бер чеметем ванилин;
- 5 аш кашыгы шикәр комы.





*Әш барышы:*

■ Майны алдан ук суыткычтан алып, бүлмә температурасында йомшартабыз.
■ Разрыхлитель белән онны бергә кушып куябыз.
■ Тирән эчле савытка 1 йомырка сытып, шикәр комын салабыз да эрегәнче болгатабыз.
■ Аннары йомшарган майны кушабыз. Онны азлап-азлап куша-куша, камыр басабыз. Ул йомшак – кул белән җәярлек хәлдә булырга тиеш. Төбе майланган табага камырны бушатып, кул белән баскалап кына таба төбенә җәябез. Камырны таба читен капларлык итеп күтәртеп куябыз.

*Эчлек:*

■ Тирән эчле савытка дүрт йомырка сытып, шикәр комы белән болгатабыз. Аннары каймак кушабыз,





ванилин сибәбез дә, бик яхшылап туглап, камыр өстенә агызабыз.

***Бизәү:***

■ Эчлектән соң таба читенә чыгып калган камырны үткен пычак белән 1см калынлыгындагы тасмаларга теләбез. Аннары беренче тасманы бармак очы белән генә эләктереп, эчлек өстенә кайтарып бөгеп куябыз. Икенче тасмага кагылмыйбыз, өченчесен тагын бөгәбез. Тасмаларны шул рәвешле чиратлаштырып кайтарып салып, бәлешебезнең чит-читен бизибез.

■ Каймак бәлеше 180 градустагы мичтә 40 минут пешә. Мичтән алгач, бераз суынганын көтәбез дә, өлешләргә бүлеп, чәй табынына чыгарабыз. Бәлеш өстен бөтнек яки мелисса яфрагы белән бизәргә була.



# ФУНЧОЗАЛЫ САЛАТ

**Бу салатның авторы да – Гөлнара САФИНА.**
**Җәй челләсендә кайнар, туклыклы ризыкларны бик ашыйсы килми. Әмма организмыбыз челләдә дә витаминнарга, минералларга мохтаҗ. Фунчозалы салат шул яклары белән кыйммәтле: бердән, ул бик тәмле, күңелне ачып, аппетитны кузгата торган; икенчедән – бик туклыклы; өченчедән – гәүдәне калынайтмый, калорияләре аз.**






***Кирәк:***

- 100 г фунчоза;
- 200 г пешкән тавык түше;
- 1 данә кызыл борыч;
- 1 данә кыяр;
- 1 данә кишер;
- 1 тырнак сарымсак;
- петрушка, яшел суган кыягы;
- 1 аш кашыгы соя соусы;
- 1 кап «Корейский соус» дигән тәмләткеч («Баллы чили соусы» да ярый);
- үсемлек мае;
- төменчә тоз-борыч.

***Эш барышы:***

■ Фунчозаны 10 минутка кайнар суга салып куябыз.

■ Кишерне махсус угычтан токмачлап уабыз.

■ Кыяр белән борычны саламлап турыйбыз.

■ Пешкән тавык түшен шулай ук озынча итеп турарга кирәк.

■ Сарымсакны чистартып, ваклыйбыз.

■ Фунчозаны тишекле чүмечкә салып, суын саркытабыз. Ул артык озын булганга, ашавы кыенрак. Шуңа күрә аны кайчы яки пычак белән кыскарак өлешләргә кисәбез.

■ Зур салат савытына яшелчәләрне, ит, фунчозаны салабыз, сарымсакны өстибез.

■ Салатка соя соусы белән Корея соусын һәм үсемлек маен салабыз. Тәменчә генә тоз белән борыч өстибез. Барысын бергә болгатабыз да яшел салат яфраклары түшәлгән зур тәлинкә уртасына өеп, өстен яшел үләннәр белән бизәп, табынга чыгарабыз.

PRESSA.RU





Яр буеннан матур ташлар җыю гадәте күп кешедә бардыр ул. Менә монысын гына, менә анысы бигрәк шома инде, бусының төсе кызык икән... дип, берәм-берәм җыя торгач, ялдан әйләнеп кайтканчы ташлар хәзинәсе шактый гына баеган була. Җәйге ялыгызның күңелле хатирәсе булган ул ташлардан бик матур картиналар ясарга мөмкин. Картинага ук тотынмыйча, бизәп, үтә күренмәле вазага гына тутырсагыз да матур булачак. Ә бу эшкә безне Алинә БАССАРИЕВА өйрәтәчәк.



# ТАШЛАРНЫ БИЗӘР ЧАК



***Кирәк:***

• түгәрәк һәм җәлпәк диңгез ташлары (озынлыгы якынча – 5-6 см, иңе – 4 см);

• төрле төстәге акрил буяулар. Акрил урынына, гуашь та ярый. Әмма акрил белән буялган ташлар матуррак;

• нечкә генә кылкаләм;

• төссез лак.

***Эш барышы:***

■ Эшкә керешкәнче, ташларны җылы суда сабынлап юып, киптерәләр. Бизәр өчен тавык йомыркасы зурлыгындагы җәлпәк, шома ташлар кулай.

■ Вак-вак тишекле ташларны ПВА җилеме белән каплап, җирлек әзерләргә кирәк. Кытыршы урыннарын наждак кәгазе белән ышкып шомарталар.

■ Ташка бизәк төшерү ысуллары күп төрле. Без, мәсәлән, акрил буяулар белән ябалаклар ясадык. Бериш ташларны тулысынча буяп, рәсемне төсле җирлеккә ясасак, беришләрен буямыйча, үз төсендә калдырдык.

■ Ташларны тулысынча буяу өчен губка куллансаң яхшырак. Кылкаләмнән буй-буй эз калырга мөмкин. Губка исә эз калдырмый.

■ Төрле түгәрәкләр, кыяр бизәкләр, шакмаклар, бөҗралар белән бизәлгән ташлар да бик матур.

■ Икенче бер киң таралган ысул: декупаж ысулы. Бу ысул кулына кылкаләм тотып карамаган кеше өчен дә отышлы. Кәгазь салфеткадан үзегезгә ошаган бизәкне кисеп аласыз да (күп катлы салфетканы катларга аерып, рәсемлесен генә кулланасы), шул ук ПВА җилеме ярдәмендә ташка ябыштырасыз. Кипкәч, төссез лак белән буйыйсы гына кала.

■ Тагын бер кызыклы ысул: кылкаләмне берьюлы ике төсле буяуга манып ясау. Бу ысул белән чәчәкләр, яфраклар, үсемлек орнаментлары бик матур килеп чыга. Сары белән яшел, кызыл белән алсу, зәңгәр белән ак төсләр үзара килешле. Хәер, кемгәдер башка төсләр ошарга мөмкин.

■ Өченче ысул: рәсемне трафарет ысулы белән төшерү. Интернеттан төрле-төрле бизәкләрне эзләп табып, теләсә нинди трафарет ясарга була.

■ Акрил буяуларның бик тиз кибүен онытмагыз, эшли торган кылкаләм дә гел сулы стаканда торсын. Киемгә тигән буяуны бетерүе кыен, балалар белән бергәләп шөгыльләнергә булсагыз, киемнең буялса да кызганыч булмый торганын кидерегез.

■ Тәҗрибә туплагач, зуррак ташларны бизәп карарсыз. Алары бакчаны бизәү өчен матур була. Кыскасы, бездән – идея, сездән – гамәл.


***Кучкар.*** Вакыйгалар үзәгендә булырсыз. Игътибар юклыктан да зарлана алмыйсыз. Ай дәвамында янәшәгездә яхшы кешеләр генә йөрер, күңелегез тулы шатлык-сөенеч булыр. Таулар күчерердәй энергия ташкыны якынлаша.


***Үгезбозау.*** Тормышыгызда җете бизәкләр, күңел күтәренкелеге, зур хисләр көтелә. Үзегезне аллы-гөлле куласага утыргандай тоярсыз, бер күңелле вакыйга икенчесен алыштырып кына торачак. Яңа сәләтләр ачыла торган ай.


***Игезәкләр.*** Хисләр ташкыны бөтереп алыр. Үз-үзегезне ныклы контрольдә тотарга туры килмәгәе, ул хисләргә артык ирек бирмәгез. Тормышны төптән үзгәртер вакыт түгел, әлегә сабыр итегез. Азрак сөйләп, күбрәк тыңлагыз.


***Кысла.*** Иртәгәсе көн өчен борчылмасагыз да була, бик тыныч, рәхәт чорга керәсез. Ниһаять, ашыкмый-кабаланмый, үз көегезгә генә яшәү мөмкинлеге туар. Күптән хыялланып йөргән теләгегезгә ирешерсез.


***Арыслан.*** Ыгы-зыгылырак, әмма күңелле вакыйгаларга, мажараларга бай ай көтелә. Нәрсәгә генә тотынсагыз да, күңелегез рухи канәгатьлек кичерер. Гәрчә йолдызлар сезгә күбрәк ял итәргә, көчне артык туздырмаска киңәш итә.


***Сөмбелә.*** Организмны киеренкелектән арындыру өчен яхшы вакыт. Бу айда барысы да ничектер үзеннән-үзе генә хәл ителә сыман тоелыр. Дуслык җепләре күптән өзелгән дип йөргән кешегезне очратырсыз.


***Бизмән.*** Кәефегез шәп булыр. Марс планетасының тәэсире бу. Һәр эштә уңышка ирешә торган вакыт. Күптән башыгызда йөрткән планнарыгызны тормышка ашыруга, көтелмәгәнчә шөһрәт казанырсыз.


***Чаян.*** Үзгәрешләр ае. Яшәү рәвешен, гадәтләрне, хәтта яшәү урынын да алыштырасыгыз килер. Мөһим карарлар кабул иткәндә күңелегезне тыңлагыз, эчке сизгерлегегез бик яхшы.


***Укчы.*** Тормыш девизыгыз: «Бүгенге эшне иртәгә калдырма!» булсын. Бүгенге көнегезнең тәмен тоеп яшәргә тырышыгыз. Август урталарыннан җаныгызга нидер җитмәгән кебек тоелыр. Йолдызлар сезгә яңа шөгыль табарга киңәш итә.


***Кәҗәмөгез.*** Энергиягезнең болай ташып торганын тагын кайчан тойдыгыз икән?! Башкаларны тоя, ишетә белү сәләтегез артачак. Кешеләр үзләре дә сезгә тартылачак. Кайчандыр бозылган араларны – җайлау, өзелгән җепләрне ялгар вакыт.


***Сукояр.*** Уңышлы һәм эш күрсәтә торган вакыт. Эштә дә, гаиләдә дә мөнәсәбәтләр бик яхшы. Имеш-мимеш, хорафатларга игътибар итүдән туктагыз. Тормышыгызга яңалыклар кертүдән курыкмагыз.


***Балык.*** Тормыш кыйммәтләрен башкачарак бәяләрсез, өстенлекне башка нәрсәләргә бирергә кирәген аңларсыз. Яңача яши башлау теләге көчле. Гомерегездә беренче тапкыр диярлек, шәхси мәнфәгатегезне алгы планга куярга туры килер.

*ИЮЛЬ дә кабынган йолдызлар*

*Татарстан*



**Дилә БУЛГАКОВА** (11.07.1937) – **татар һәм башкорт язучысы.**

Башкортстанның Бозаяс (хәзерге Кырмыскалы) районы, Бозаяс авылында туа. Уфа медицина училищесын тәмамлап, 40 ел гомерен медицинага багышлый. «Язучылык өлкәсенә кереп китүемә алты ел тоткыннар арасында эшләү, төрле аянычлы язмышларны якыннан күреп аралашу сәбәп булгандыр, мөгаен», – ди ул. «Үрмәкүч» җыентыгы шунда ишеткән, күргәннәренә нигезләнеп язылган хикәяләрдән тупланган. Төрмә тормышын чагылдырган хатын-кыз язучыларның беренчесе ул. Әлеге җыентык рус һәм татар телләрендә басылып чыга. Шагыйрәнең халык арасында киң таралган җырлары һәм шигырьләре тупланган «Көмешләнгән урман», «Туктама, җыр, өзелмә, моң!», «Сер», «Скрипка моңы» дип аталган хикәяләр, парчалар җыентыклары дөнья күргән.

*Россия*



**Эдита Пьеха** (31.07.1937) – **җырчы, СССРның халык артисты.**

Франциядә туа. 1946 елда әнисе белән Польшага кайта. 1955 елда СССРда укырга юллама алып, Ленинград дәүләт университетына укырга керә, консерватория студентлары ансамбленә йөри. 1956 елны каршылаган төндә ул консерваториядә «Красный автобус» җырын башкара. Икенче көнне студентлар коллективының даны бөтен шәһәргә тарала. Шушы көннән аны ансамбльнең солисты итеп билгелиләр, ә ансамбль үзе «Дружба» исемен ала. 20 ел әлеге ансамбльдә җырлаганнан соң, аннан китеп, үз коллективын туплый. 2015 елда җырчының тормыш һәм иҗат юлына нигезләнеп, «Рожденная звездой» дип аталган нәфис фильм дөнья күрә.

*Чит илләр*




**Памела АНДЕРСОН** (1.07.1967) – **актриса.**

Канаданың Ледисмит шәһәрчегендә туа. Әнисе ягыннан әбисе – Россия эмигранты. Балачактан ике яраткан шөгыле була – саксофонда уйнау һәм спорт. 1985 елда мәктәпне тәмамлагач та физкультура укытучысы булып эшли башлый. Җирле футбол матчы вакытында очраклы рәвештә генә камерага эләккән чибәр кызны пиво кайнатучы компания менеджеры күреп алып, рекламада төшәргә тәкъдим итә. 1992 елда беренче мәртәбә үзен кинода сынап карый – «Замужем» дигән фильмда кечкенә генә роль башкара. Аннары «Спасатели Малибу» сериалында уйнап, кино йолдызы булып таныла. «Взятие Беверли Хиллз», «Двое полицейских», «Знак дракона», «Майк Хаммер» фильмнары да актрисага уңыш китергән фильмнар.

PRESSA.RU







# ҮЗЕ БЕР МОГҖИЗА

ЮНЕСКО каршындагы Халыкара сынлы сәнгать ассоциациясе әгъзасы, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның халык, Россиянең атказанган рәссамы, Тукай исемендәге, Фәезханов исемендәге премияләр лауреаты Владимир Александрович Попов турында сөйләгәндә иң элек аның киң кырлы рәссам булуына басым ясарга кирәктер. 70 еллык иҗат гомерендә сынлы сәнгатьтән кала, сәнгатьнең рәссам кулы тиярлек бөтен төрендә үзен сынап караган кеше ул чөнки. Ә дөньякүләм мәйданга гарәп каллиграфиясе чыгара аны.

Мөселман дөньясындагы бердәнбер рус каллиграфы буларак килеп керә ул бу өлкәгә. Гарәп графикасы белән виртуозларча эш итүче рәссамның әлеге алфавитны 70 яшендә (!) генә үзләштерә башлавы – үзе бер могҗиза. 94 нче яшь белән баручы ветеран-рәссамның әле дә иҗат белән яшәве сокландыра. Соңгы 10-15 ел эчендә шәхси күргәзмәләре белән Яңа Зеландия, Марокко, Төркия кебек күп кенә илләрдә халыкара күргәзмәләр белән йөреп кайтты ул. 2000 елда Иранда узган Коръән һәм каллиграфия форумында куелган экспозициядә катнашып, көмеш медальгә лаек булганнан бирле Шәрык дөньясына юллары ачык хаттатның. 2006 елда Ливан, Сүрия, Мисыр дәүләтләренең җиде шәһәрендә шәхси күргәзмәләре узып, дөньяның күп кенә илләреннән чакыру ала рәссам һәм «Каллиграфия тынычлык сагында» дигән шигарь астында еллар дәвамында үз сүзен үтемле итеп җиткерә килә. 18 яшеннән сугышка китеп, Владикавказны, Кубаньны, Кырым, Украина һәм Көнбатыш Пруссияне азат итүдә катнашып, контузияләр ала-ала, Берлингача барып җиткән солдат әле бүген дә тынычлык хакына көрәшен әнә шул рәвешле дәвам итә. «Без бу җирдә барыбыз да кардәшләр, шулай булгач, нигә сугышырга, кан коярга?! Тынычлыкта, татулыкта, бергә-бергә аңлашып яшәүгә ни җитә!» Очрашулар вакытында һәрчак әнә шуңа басым ясый ул.

«Попов – тынычлык һәм бәхет илчесе», «Илаһи балкыш», «Рухи көч» – рәссамның күргәзмәләрендә булучылар үзләре дә аңа менә шундый канатлы сүзләр яудыра. Шунысы кыйммәт: Владимир Поповның иҗаты гап-гади кешеләрнең җанында да, гали затлар күңелендә дә тирән яклау таба, катлаулы һәм каршылыклы дөньябызны рухи матурлыкка күмеп, тиешле бәясен ала килә. «Сез гаҗәеп мөһим эшне бик матур итеп башкарасыз – мөселман каллиграфиясе традицияләренә яңа цивилизация-ара аспект бирәсез. Аллаһ сезне ярдәменнән ташламасын!» – дип язган иде аңа моннан элек танылган сәнгать белгече, шәрыкчы, Дәүләт Эрмитажы директоры Михаил Пиотровский да. Ә менә фәлсәфәче, ислам белгече Гөлнара Балтанова Владимир Поповның дөнья мәдәниятенә керткән өлешен Көнбатыш белән Шәрыкны берләштерә алган Лев Гумилев һәм Николай Рерих кебек шәхесләр яссылыгында карап, Евразия күләмендә алар белән янәшә куярлык фигура булып үсеп килүен ассызыклый.

Рәссамның каллиграфияләрен өйрәнүчеләр аның, әлеге юнәлешнең нигезләрен өйрәнеп кенә калмыйча, каллиграфияне яңа техник, интеллектуаль баскычка, хәтта ки галәми биеклеккә күтәрүен билгеләп узалар. Һәм бу чыннан да шулай.

Расиха ФАИЗОВА










**ВЛАДИМИР ПОПОВ**

PRESSA.RU

# 1 июльдән 2018 елның беренче яртыеллыгы өчен газета-журналларга язылу башланды



«Почта России»ның «Подписные издания» (ПАП) рәсми каталогы буенча
ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ ИНДЕКСЫ П2204



## Татарстаннан читтә яшәүчеләр әлегә «Роспечать» каталогындагы элеккеге индекс буенча языла алалар: 73002

## ЯРТЫЕЛЛЫККА ЯЗЫЛЫРГА ӨЛГЕРМИ КАЛУЧЫЛАР ҺӘР АЙНЫҢ 15 НӘ КАДӘР ЯЗЫЛЫП, ЖУРНАЛНЫ КИЛӘСЕ АЙДАН АЛДЫРА АЛА!

Журналыбызга онлайн режимда :
http://podpiska.pochta.ru сайтында (регистрация узып)
язылырга мөмкин



Электрон версиягә язылган очракта, яңа санны компьютерда, планшетларда, барлык мобиль җайланмаларда PDF форматта укырга була.
iPad һәм iPhone кулланучылар «Сөембикә» журналының электрон версиясен App Storeдагы «Pressa.ru» киоскына кереп, хатын-кызлар өчен журналлар арасыннан таба ала.
Электрон версиягә язылу турында тулырак мәгълүматны «Сөембикә» журналының сайтында «Язылу» бүлегендә табып була (www.syuyumbike.ru).

16+